Рәмзия Мөхетдинова

Укытучым, кадерлем...



2010 ел

Китапны нәшер итүдә матди ярдәм күрсәткән шәфкатьле затлар:

Миронов Николай Павел улы, Исмәгыйлев Рәшит Фәйзерахман улы, Гыйльмадиев Мөнәвир Хәмәт улы, Кәлимуллин Рәшит Хажинур улы, Кашафетдинов Илгиз Раиф улы, Тажиев Дамир Мулланур улы, Нәҗметдинова Мөнирә Зәки кызы, Бәшаров Фәрит Рәшит улы һәм гаиләм.

Сезгә ихлас күңелдән
зур рәхмәт!





2010 ел – үзенчәлекле ел. Быел әниемнең тууына – 100, Бөек Җиңүгә – 65 ел тула. Китабым да нәкъ менә быел – Укытучы елында дөнья күрә. 2010 ел һәммәбез өчен дә хәерле ел булсын!

Автордан...

Әгәр кемдер үзе турында бер елга җылы истәлек калдырасы килсә – яшелчә, ун елга исәп тотса – җиләк-җимеш үстерсен, йөз елга исәпләсә – йорт салсын, агач утыртсын, бала үстерсен, халык күңелендә мәңгегә каласы килсә – китап язсын.

Борынгы бабаларыбыздан мирас булып калган әлеге фәлсәфи гыйбарәне искә төшереп, мин һич кенә дә үз исемемне мәңгеләштерергә җыенмыйм. Киресенчә, рухи Мәккәбез – Бәзәкә мәктәбен тәмамлаган дистәләгән буын яшьләрне олы тормыш юлына әзерләп чыгарган Бәзәкә мәгарифе күгендәге беренче карлыгачларга – укытучыларыбызга олы рәхмәтемне җиткерү йөзеннән, шушы истәлек-ядкаремне кадерле Мөгаллим-остазларыбызга багышлыйм.

Бу эшкә тотыну теләге миндә 2006 елның җәендә, сыйныфташлар белән 40 елдан соң очрашу бәйрәмендә туды. Нәкъ шул елда икенче туган йортыбызның – 1926 елда төзелгән мәктәбебезнең юбилее – 80 еллыгы иде. Ләкин, ни кызганыч, хәзерге мәктәп администрациясе әллә онытты, әллә кирәксенмәде, бәйрәм булмый калды. Югыйсә, бүгенге көндә әле исән дистәгә якын укытучы абый-апаларыбыз һәм мәктәпне төрле елларда тәмамлаган укучылар белән очрашу-күрешү тантанасы мәктәп өчен генә түгел, ә бөтен авыл өчен дә бик күңелле һәм шатлыклы тамаша буласы иде дә бит...

Һәр мәктәпнең горурлыгы – укучылары, һәр мәктәпнең мактанычы – укытучылары. Бәзәкә мәктәбенең дә горурланырдай укучылары аз түгел. Академик, профессор, доцент, фән-техника, мәгариф, медицина, авыл хуҗалыгы, нефть сәнәгате һәм башка өлкәләрдәге атказанган һәм алдынгы кешеләребез, зыялыларыбыз никадәрле! Ә бит алар безнең кадерле мөгаллимнәребезнең хезмәт һәм иҗат җимешләре! Бу "татлы җимешләр"не санау һәм барлау эшенә инде күптән керешергә кирәк иде. Мактанычыбыз булган укытучыларыбыз әлегә, шөкер, арабызда чакта кирәк бу гамәл. Була алмый калган юбилей аларга халык каршында, үсеп килүче яшь буын алдында рәхмәт әйтү, хөрмәт күрсәтү өчен иң кулай мөмкинлек иде.

Үзебезнең очрашу бәйрәмендә мин сыйныфташларым белән башыма килгән уйны уртаклаштым: "Укытучыларыбыз турында истәлек-китап язсам, ни әйтерсез?" Классташлар бу теләкне бердәм хупладылар.

Һәм менә, кадерле укытучыларыбыз, сезгә багышланган китап – сезнең алда, сезнең кулда...

***

Искәрмә: китапта укытучыларның укыта башлаган яшьлек чоры, берәр сыйныфы белән яки өлкән яшьтә төшкән фотосурәтләре бирелде.


А
Мәктәп
Я

Рәмзия Мөхетдинова

Мәктәп

Сабыйларның канатланыр вакты
Мәктәпләрдә укыр чак булыр.
Г.Тукай

Мәктәп. Кыңгыраулы мәктәп еллары... Кабатланмас балачак һәм гүзәл яшьлегебез бөреләнгән шул чор, күпме гомер узса да, җиз кыңгырау тавышлары, матур хатирәләре, хыял һәм өметләре, якты истәлекләре белән күңелләрдә яшәвен дәвам итә.

Еллар үткән саен, мәктәп, сине укыткан, олы тормыш юлына әзерләгән укытучыларың ныграк сагындыра, ешрак искә төшә икән. Бу шулай булмый мөмкин дә түгелдер. Чөнки мәктәп еллары – кеше гомеренең иң гүзәл, рәхәт, онытылмас мизгелләргә бай чоры, хыял-өметләрнең канат ярган чагы бит ул...

Мин Бондюг районының Бәзәкә урта мәктәбендә белем алдым. 1954 елның 1 сентябрендә тәүге мәртәбә мәктәп бусагасын атлап кердем. Шул көннән башлап, мәктәп минем өчен зур белем дөньясына үзенең ишекләрен ачты.

Мәктәбебез тау башында, авылны икегә ярып ага торган инешнең аръягында, авылдан читтә салынган. Аның шунда салынуы – үзе бер тарих. Революциядән соң авылларда беренче мәктәпләр барлыкка килгән вакытта, балаларны байлардан, мулла-мәзиннәрдән тартып алынган йортларда укытканнар. Ә менә чын совет мәктәбе төзү зарурлыгы килеп тугач, моның өчен мөмкинлекләр ачылгач, яңа мәктәпне кайда, нинди урында төзү мәсьәләсе буенча халык арасында бәхәсләр килеп чыккан. Берәүләр мәктәпнең авыл уртасында булуын хупласа, икенчеләре, бигрәк тә дин әһелләре, киресенчә, аның читтәрәк булуын таләп иткәннәр. Чөнки мәктәпне алар "шайтан сабагы" урыны дип исәпләгәннәр. Шулай итеп, безнең авыл мәктәбе тау башына салына.

Бу 1926 елда була. Элек төрле кеше өйләрендә укып йөргән укучылар хәзер яңа мәктәптә укый башлыйлар.



Авыл ягыннан караганда тау башына салынган мәктәп күренеше

Мәктәпнең тау башында булуы бер яктан – безгә ераграк тоелса да, икенче яктан, ул безнең өчен – Белем тавы иде, нәкъ Олимп тавы кебек. Икесенә дә менү өчен тырышырга, омтылырга, югары күтәрелергә, көч куярга кирәк.

Тауга күтәрелү өчен матур да, уңайлы да итеп эшләнгән баскычларыннан ничә мең мәртәбәләр менеп төшелде икән?! Башта йөгерә-сикерә күпләгән баскычлардан менәсең, аннары, бераз арытылса – утырып ял итеп аласың. (Ун аралык баскычтан соң ял итү өчен махсус эскәмияләр эшләнгән иде). Аннары тагын биш аралык үтәсең. Ниһаять, синең алда Белем йорты – Мәктәп!

Мәктәпнең беренче директоры Әгъләмов Солтан була.



Мәктәп бинасының ал ягы. 1926 елда салынган



Фәизов абый уртада. Кечкенә Габделхәй Гыйльфанов беренче рәттә, уңнан өченче. 1932 ел

1927 елда мәктәптә пионер оешмасы төзелә. Казан дәүләт педагогия институты студенты Гыймранов Зиннур Мәскәүдә, Казанда төзелгән балалар оешмасы, пионерлар турында сөйли, оешманың эше, бурычлары турында аңлата. Балалар бу яңалыкны уңай кабул итәләр һәм пионер сафларына керә башлыйлар. 1928-29 еллардан башлап, һәр елны диярлек, мәктәптә берәр сыйныф ачылып барган. 1930-33 елларда мәктәптә директор булып Фәизов Мәгъсүм эшләгән.

Тормыш ифрат дәрәҗәдә авыр, хәерчелек, фәкыйрьлек көчле булса да, кешеләр үз балаларын укытырга тырышканнар. Күп балалар мәктәпкә чабата, тула оектан йөргәннәр.



Укытучы Әхмәтшин Харис абый укучылар белән. 1933 ел

Шушы елларда мәктәпкә яшь кенә кыз – татар теле һәм әдәбияты укытучысы Вәлиәхмәтова Оркыя килә. Ул, укыту белән беррәттән, балалар оешмасы эшен тагын да үстереп, җанландырып җибәрә. Пионерлар яңа оешкан колхозга төрле эшләрдә зур ярдәм күрсәтәләр: алар кырларны ашлау өчен көл туплыйлар, утау эшенә йөриләр, башак җыялар, фермада бозаулар карарга булышалар.



1933-34 елларда Бәзәкә мәктәбе җидееллыкка әйләнә. Бу вакытта башка авыл балалары да килеп укый башлыйлар. Укытучылар булып Гөлсем Һәм Гата Садыйковлар, Оркыя Вәлиәхмәтова, Хәйрия Шакирова, Габденур Ганиев, Зәйтүнә Ганиева, Кашиф Фәезов һәм башкалар эшләгәннәр (өстәге фото).

1937-38 елларда, 8 нче сыйныф ачылу белән, мәктәп урта мәктәп булып исәпләнә башлый. Директор итеп Мәрдәнов Габдрахман билгеләнә.

Соңрак алдагы елларда эшләгән коллективка яшь укытучылар өстәлә. Болар – Сергей Белов, Александр Егоров, Арыслангали Әюпов, Гөлсем Гайнуллина һәм башкалар.



Мәрдәнов Габдрахман хатыны – укытучы Вәлидова Тәскирә белән. 1938 ел



1939-40 ел

1940 елның июнендә Бәзәкә урта мәктәбе үзенең беренче 10 нчы сыйныфын чыгара. Бу зур бәйрәм була. Аттестат алу тантанасына бик күп кунаклар һәм авылдашлар киләләр. Истәлеккә фотога (аста) төшәләр.



Шушы елның көзендә мәктәпкә тагын яңа укытучылар килә. Алабуга педтехникумын бетергән Бәзәкә егете Габделхәй Гыйльфанов математикадан укыта башлый. Яшь

белгеч зур теләк һәм ташып торган дәрт белән укучыларга математика серләрен төшендерә, бу фәнгә карата балаларда мәхәббәт һәм кызыксыну уята.



Артта уңнан беренче: Әминә Бәдертдинова, икенче Габделхәй Гыйльфанов, бишенче – Гайнуллина Гөлсем, алтынчы – Көләчева Мәрьям. 1940-1941 уку елы

Гомумән, бу елларда мәктәптә ир-егет укытучылар бик күп була.

1941 ел. Бөек Ватан сугышы илебез өстенә зур афәт



Бу ир-егетләрнең күбесе яу кырыннан мәктәпкә кире әйләнеп кайтмаячак...


булып ябырыла. Бик күп авылдашлар фронтка китә. Шул исәптән Бәзәкә мәктәбеннән дә яу кырына берәм-берәм укытучы ир-егетләр китә башлый. Төгәлрәк әйтсәк, сугыш еллары дәвамында мәктәптән барлыгы 25 ләп кеше озатыла. Шуларның унбише Ватан өчен башларын салганнар.



Гайнан Әхмәтов җитәкләгән укытучылар коллективы. 1948 ел

Сугыш беткәч, исән калган, солдат шинельләрен әле салырга да өлгермәгән ир-ат укытучылар кабат мәктәпкә кайталар. Мәктәп директоры Гайнан Әхмәтов була. 46-56 нчы елларда мәктәптә укытучылар коллективы тагын да үсә, яшәрә. Югары белемле белгечләр саны арта.

1956 елдан мәктәп директоры булып Муллаян Гыймадиев, 1958 елдан Муллаян Галиев, 1959-65 елларда Камил Гыйльмуллин эшләгәннәр. 1967 елның көзендә Бәзәкә мәктәбенең хәзерге бинасы ачыла.


А
Могаллим
Я

Илаһи Зат – Мөгаллим

Нинди изге дә, гади дә, матур да, ягымлы да, җылы да сүз!

Илаһи зат, бөек шәхес үзе,
Ә карасаң, тыйнак бер кеше.
Һәр көн даим мәктәбенә бару
Һәм дәресләр бирү – төп эше.

Укытучы!

Син бәхетле, нәни күңелләргә
Бәрәкәтле орлык сибәсең.
Сабыйларның кайгы-шатлыкларын,
Хыялларын шундук сизәсең.

Эш коралың гади – акбур гына,
Бик катлаулы, ләкин тирәлек:
Утыз бала – димәк, утыз пар күз
Җавап көтә сиңа төбәлеп.

Сорау тулы күзләр сиңа карый:
Бер сораумы, йөзме, меңәүме
“Белмим” сүзен, берүк, әйтә күрмә!
Кичермиләр алар белмәүне.

Син белергә тиеш, укытучы,
Ни сорыйлар – шуны белергә.
Укытучы булу – бу шундый эш –
Белгәнеңне кирәк бирергә.

Син бер гади укытучы булып
Тырыш хезмәт иттең тормышта.
Һәр укучың – язылмаган роман,
Һәр дәресең – маяк тормышка.



Ислам дөньясында балаларга да, өлкәннәргә дә үтә файдалы үгет-нәсыйхәтләр, тирән мәгънәле хәдисләр күп. “Бишегеңнән алып ләхетеңә кадәр белем эстә” – шундыйларның берсе.

Хәзерге заманда да кулланыла торган: “Кытайга барып булса да гыйлем ал” дигән әйтем дә, беренчесе кебек үк, аң-белем алуның ни дәрәҗәдә кирәкле, кыйммәтле гамәл икәнен ассызыклап тора.

Әйе, белем – иң зур байлык: янмый да, югалмый да.

Без, Бәзәкә мәктәбе укучылары, Шанхайга да бармадык, Кытайда да белем алмадык. Шушы бәһасез байлыкны безгә гап-гади авыл мәктәбендә, гап-гади укытучы абый-апаларыбыз бирде. Укытучыларыбыз безне – авыл балаларын, белемле, зәвыклы, һәрьяктан камил шәхес итеп тәбияләргә тырыштылар, безнең икенче әти-әниебез дә, сердәшчебез, киңәшчебез дә булдылар.

Авылыбызның горурлыгы, мәктәбебезнең даны-җаны иде алар. Безнең өчен зур шәхес, талант ияләре булдылар. Әмма без аларны беркайчан да кайбер мәктәпләрдәге кебек Рәшит Усманович, Әдия Сәлимовна дип йөртмәдек, ә якын итеп, үз туганыңа дәшкән кебек гади генә Фоат абый, Мәсгудә апа дия идек.

Остазларыбыз, төпле белем бирү белән берряттән, сыйныф җитәкчеләре буларак, безне авырлыкларны җиңәргә, укуның, хезмәтнең, яшәүнең тәмен-ямен, куанычын тоеп, алга куйган максатка ирешү өчен омтылып яшәргә өйрәттеләр. Җиһанга оптимистик караш, яшәргә дәрт биргән киңәшләре белән безнең иңнәргә канатлар куйдылар. Мөгаллимнәребез гадел, намуслы, үз эшенең чын фанатлары иделәр. Күпләренең мактаулы һәм дәрәҗәле исемнәре дә юк иде. Алар акча җыймадылар, мал-мөлкәт, байлык тупламадылар, исем-дәрәҗә дип кызыкмадылар. Аларның күңелләре, рухлары бай иде. Данлы шөһрәткә өмет итмичә, уфтанмыйча, бөтен гомерләрен балалар тәрбияләүгә, илгә белемле яшьләр үстерүгә багышлаган кешеләр алар, безнең кадерле укытучыларыбыз. Алар өчен иң зур байлык, куаныч, горурлык

– укучыларының Кеше булулары, иң мөһиме – ил-күз алдында абруйлы затлар булуында. Әйе, бик күп, бик күп шәкертләре нәкъ шундыйлар булдылар да, укытучыларыбызның өмет-хыялларын акладылар, сынатмадылар.

Мөгаллимнәребез, укыту белән беррәтән, авыл, колхоз, җәмәгатьчелек тормышына да иң зур өлеш кертүчеләр. 35-40 ел укытучы булып эшләү дәверендә нинди генә эшләрдә катнашырга туры килми аларга!

Уку елы башлануга ук көзге яңгыр, кар астында колхоз басуында бәрәңге алуда эшләү, колхоз базында кырдан кайткан бәрәңгене аралау, балалар белән фермада бозау караучы апаларга булышу, терлекчеләр йортында лекцияләр уку, савымчылар, механизаторлар алдында концертлар кую, контроль саву вакытында катнашу да укытучы өстендә.

50-60 нчы елларда авыл буйлап өй саен керә-керә заем өләшү, сөт, йон, йомырка заданиеләрен тапшыруны таләп итеп йөрүләр укытучы өчен кимсетелүле дә, күңел әрнетүле дә вазыйфаларның берсе була. Классында укыган балаларның соңгы телем ризыгын авызларыннан тартып алуга тиң бу гамәл укытучының бәгърен телгәли. Әмма заманы шундый: кушканны эшләргә кирәк, өстән шулай таләп ителә...

Болар өстенә, укытучыларның һәрберсе агитатор, лектор, пропагандист. Һәр укытучыга ун йорт бүленеп бирелә. Менә шул йортларда атна саен газета-журналлардан материаллар җыеп, партия идеяләрен халыкка җиткерәсе, аңлатасы. Әле мәктәпнең үзендә политукулар аерым үткәрелә, анда да укытучылар, ныклап әзерләнеп, чыгышлар ясыйлар, фикер алышалар. Бу политукуларны районнан райком, горком инструкторлары килеп тикшереп торалар: төрле отчет, информацияләр таләп итәләр.

Язын тагын бәрәңге базында эш, кырда салам янды-ру, тирес тарату, кар каты вакытта кулдан ашлама чәчү, агач утырту. Боларның нәтиҗәсе, билгеле, аяныч: бик күп дәресләр калдырыла. Ул калган дәресләрне ничек булдырасың – шулай укыт, планыңның астын-өскә китерсәң-ки-

тер, әмма башта программаны куып җит һәм уку елында әллә ничә мәртәбә төп эшләре – укудан бүленгән балаларны имтиханнарга әзерлә, тулы өлгереш бир, сыйфат та (“4”ле, “5”леләр) югары булсын.

Укытучы халкына җәй буе да юньле ял юк: әле колхозга яшел масса әзерләргә, борчак чабарга, явымнарда чыланган теземнәрне әйләндерергә чыгарга. Тагын мәктәп атына, куяннарга печән әзерләргә болынга барасы.

Укытучы Әминә апа Бәдертдинова сөйли: “Печән вакытында һәр көнне 6-7 кеше (1-2 техничка да була) болынга ат җигеп барабыз. Ирләр печән чаба, без ышыклык өчен куышлар көйлибез, аш пешерәбез, чәй кайнатабыз. 2-3 көн үткәч, печәнне әйләндерәбез, җыябыз. Иң авыры – кибән кую. Өскә мине менгерәләр. Ирләр төрле яклап бертуктаусыз печән ата. Алып та өлгерергә, аны тигезләп һәм тыгызлап сала да белергә кирәк. Тырыша идек, йөзгә кызыллык китерәсе килми иде. Әһлиев Зәйнак, әле ул вакытта яшь укытучы, кибәннәр өелеп беткәч, мине мактап: “Әминә апа, бер генә кибәнеңнең дә муены кәкрәймәгән, молодец!” – дия иде.

Печән эше бетүгә, колхозның ындыр табагында ашлык сугару, чистарту башлана. Монда да иң беренчеләр – укытучылар. Исемлек төзелә, өчәр смена эшлисе. Ниндидер сәбәп белән үзең чыга алмасаң, туганыңны, балаңны чыгарасың, графикны өзәргә ярамый. Эш, хезмәттә катнашу дигәннән, мәктәбебез тарихында булган бер хикмәтле вакыйга турында язмасам, бу тарихның бер бите буш калыр сыман.

50 нче еллар азагы-60 нчы еллар башы иде ул, ялгышмасам. Мәктәпкә май азакларында әллә 3, әллә 5 мең (!) чеби кайтардылар. Укучылар шушы чебиләрне үстереп, симертеп, көзгә дәүләткә иткә тапшырасылар икән. Хуш... Укулар бетте, “чеби бригадасы”ның исемлеге төзелде, һәркем үз чиратында дежурга килә башлады. Чебиләрне мәктәпнең инеш буендагы тәҗрибә участогында урнашкан спорт залына җибәрделәр. Ул бинада тагын мастерской бар иде, аны да чебиләр өчен бирделәр.

Менә классташым Тажиев Камил белән минем дә чи-

рат җитте. Кичке 6 дан иртәнге 8 гә кадәр бер кыз, бер егет – өлкәннәр, 1 кыз, 1 малай – урта сыйныфтан дежур торасы. Бер техничка кунарга килә. Әмма безнеке авырып торганлыктан, “өлкәннәр” аны кайтарып җибәрделәр.

Спортзалдагы чеби “халкы”ның күплеген күреп, исакылларыбыз китте, бер мәлгә авызны йомарга онытып тордык, биллəhи. Андагы эсселек, бөркү hава, чебиләр “хоры”, пешкән йомырка исе...

Чебиләрне кичтән бер мәртәбә ашатасы (100 йомырка көндез пешереп калдырыла), кичке уннарда үзләрен бер “болгатып” аласы, “пешмәсеннәр”, ягъни мәсәлән. Сәгать 8ләр туларга берничә минут кала, безнең егет белән кыз (ялгышмасам, Нәбиуллин Мансур абый белән Ибәтуллина Шәмсия апа иделәр бугай), тегеләй итегез, болай эшләгез дип өйрәтеп, клубка чыгып чаптылар. Анда кино, соңыннан – танцы. Камил белән башта китап укып утырдык, берничә куркыныч хәл турында сөйләштек. Аннары йомырка ашарга керештек. Камилгә – 5, миңа – 5 йомырка. Каты пешкән йомырканы күп ашап та, hич кенә йотып та булмый икән аны: тыгылдык, тончыктык, күзләр тонды. Ярый әле шешә белән чәй алып килгән идек, шуны эчеп, бераз хәл алдык. Сәгать 10 җитте (тәрәзә төбендә будильник тора). “Сары халык”ны “болгатырга”, араларга керештек. Алар идәндә такталар белән бүлгәләнгән “ояларда”да кырмыскалар кебек кайнашалар, “чи” киләләр. Шулай болгаткалап йөргәндә, берничә тактаны аудардык, өсләренә дә баскаладык бугай. Шул арада, Ходайның хикмәте, җан тәслим кылган 5-6 чеби пәйда булды. Инде нишләргә? Алдагы дежурлардан ишеткән идек, алар үлгән чебиләрне чиләккә тутырып, участок кырындагы бәрәңге бакчаларының читән буена күмеп куялар икән. Яшьләр кайтканчы, без дә шулай эшләргә булдык. Участок көрәген эләктереп, чиләккә чебиләрне тутырдык та, бер чокыр казып, “мәрхүмкәйләрне” шунда җирләдек. Инде эш бетеп, кузгалдык дигәндә генә, билгесез берәүнең: “Кем бар анда? Нишлисез?” – дигән калын, иләмсез тавышы ишетелмәсенме. Я, Хода! Безнең кот ботка



төште. Шул арада ул шыксыз зат өстебезгә ябырылып килгәндәй булды. Җитмәсә, бүре кадәр бер жанвар безгә таба ыргылды. Тавыш мәктәп тавы арасыннан гына түгел, күкләрдән иңгән күкрәү кебек яңгырады.

Без, “а-а-а” дип акырып, көрәк-чиләгебезне ташлап, бу шомлы урыннан күтәрелеп чаптык. Инеш аркылы салынган озын такта басмадан дөбер-шатыр үтүебезне, авылга менә торган таудан абына-егыла йөгерүебезне генә чамалыйм. Урамга кереп, берничә өй үткәч, шып туктадык та, бер-беребезгә карап каттык. Шунда Камил, аңына килеп: “Соң, без “чеби өен” үтеп киткәнбез бит”, – диде. “Әгәр зурлар кайтып, безне үз урыныбызда тапмасалар, бетерәләр”, – дидем мин дә. Чытырдатып кулларны тотыштык та, кире югарыга чаптык. Мүкәләнә-мүкәләнә көрәк-чиләгебезне эзләп таптык, чебиләребез янына кердек. “Аллага шөкер, болары исән-имин икән”, – дип сөендек. Утны сүндердек тә, стенага терәлеп утырдык. Сәгать ничә булгандыр, егет белән кызыбыз кайтып, безне урынга (йоклар өчен әзерләнгән матрацлар бар иде) салганнар, анысын инде сизмәдек.

Иртә белән кемнеңдер тәрәзә кагуына уянып киттек. Укытучы Аликин абый кизүгә сәгать 7 гә үк килеп җиткән икән. Шәмсия апа безгә азык салырга кушып, үзләре чебиләрне тагын бер мәртәбә аралап, ерып чыктылар. Тагын 7-8 үлгән чеби таптылар. Аликин абый алардан тиз генә котылырга кушты, чөнки тиздән мәктәпкә директор һәм укытучылар килергә мөмкин. Мансур абый көрәккә тотынган иде, Нурулла абый: “Юк, юк, кирәк түгел, болай да инде читән буйларында “батырлар каберлекләре” артык күбәйгән. Әнә, яр арасына бар да, тау битенә ат, каргалар алып китәрләр”, – диде. Шулай эшләделәр бугай. Безнең беренче кизү тору шулай тәмамланды. Икенчесендә инде чебиләр үсә төшкәннәр иде, бу кадәр матавыклар булмады. “Чеби үстерү”нең бер төнендә без шундый мажараларга тап булганны, җәй буена башкалар белән нинди хәлләр-тамашалар булып бетте икән, анысын белмәдек. Чеби-тавыклар да көзен ничәгә калып, дәүләткә күпме

центнер ит тапшырылды – анысы да безгә нәмәгълүм. Балалыгыбыз белән ул турыда кызыксынмаганбыз да инде. Алай да вожатый Әдия апабызның, матур гына саннар әйтеп, сборларда, районда пионерларны мактап сөйләгәннәре хәтердә. “Чеби үстерү” тарихы хәтердә менә шулай сакланып калган. Бик кызык кинокомедия кебек...

Ә теге иләмсез авазлы кешене соңыннан белдек: ул безнең урамның бер абзые булып, малае, көчеге белән ике көн кайтмаган танасын эзләп йөргән икән.

Көзен, уңыш бәйрәмендә укучыларны җыелган яшелчәләрдән пешерелгән аш, бәрәңге боткасы, бераз куян ите белән сыйлыйлар иде. Өйдән үзең белән бер җамыяк, калак һәм кружка алып киләсең. Ул вакытта әле мәктәптә ашханә юк иде.

Ярый, укытучыларыбызга кире кайтыйк. Менә шушындый эш-мәшәкатьләр белән 1 сентябрьнең кабат килеп җитүен, үзләренең әле 20 көн дә тынычлап, онытылып ял итә алмыйча, өр-яңа уку елына тагын килеп керүен сизми дә кала укытучыларыбыз. Ә мәктәп тавык та чүпләп бетерә алмаслык борчу-мәшәкатьләре, ыгы-зыгылары белән укытучыны кабат үз дөньясына бөтереп алып кереп китә...

Ә монда инде көн саен икешәр сменада дәресләр укыту, шау-шулы тәнәфесләр, линейкалар, кичке якта педсовет, дүртәр сәгатькә сузылган профсоюз җыелышлары, интернатта дежур тору, кичке якта балаларны клубка йөртмәү максатыннан сакка чыгу (әйтерсең, моның өчен үз әтиәниләре юк), ата-аналар җыелышлары, аларга әзерләнү, ягъни педагогик темага берәр лекция уку, һәр баланың шушы чиректә алган билгеләрен туплау, шушы җыелышта ук концерт күрсәтү, ял кичәләрендә тәртип булдыру, укучыларыңның кайда, ничек, кем белән йөрүләрен күзәтү, түгәрәк эшләрен оештыру, бәйрәмнәргә репетицияләр үткәрү, колхоз радиоузелыннан чыгышлар ясау, тимурчылык эше, берсе артыннан икенчесе килергә атлыгып торган комиссияләрне каршы алу, аларга ачык дәресләр бирү, төрледән-төрле тикшерүләр һәм башкалар, һәм башкалар.

Әле тагын ел саен Алабуга пединституты безнең мәк-




тәпкә дистәдән артык студент-практикантлар җибәрә иде. Укытучыларыбыз аларга иренмичә, авырыксынмыйча планнар төзү һәм дәрес бирү серләрен өйрәттеләр. Ничек өлгергәннәр дә, ничек җитешкәннәр, ничек миләре кайнап чыкмаган укытучы абый-апаларыбызның. Хәер, соңыннан, 35 ел укыткан дәвердә, бу эшләрнең күбесен үзем дә татыдым. Укытучы чын-чынлап башкарырга тиешле үз эшенә – планнар төзүгә, дәфтәр тикшерүгә, ниһаять, кичке сәгать 10 да гына бушый. Дәфтәрләр дә күп түгел: 25-35 данә генә! 5-6 биттән торган бер иншаны тикшерү өчен генә күпме вакыт китә дә, әле шуны 30-35кә (ягъни балалар санына) тапкырласаң, нәрсә килеп чыга? Тел укытучыларының хәлен шуннан чамалавы авыр түгел.

Аллаһы Тәгалә дә: «Берәр кешегә җәза бирәсе булса, мин аны мөгаллим итәрмен», – дигән бит. Менә шундый ул – укытучы хезмәте! Укытучы, остаз өйрәтмәсә, укытмаса, тырышмаса, бүтән һөнәрләр дә булмас иде. Дөньядагы иң мөһим һөнәрләрнең иң мөһиме – укытучы һөнәре!

Ә укытучыларыбыз, авыр дип тормаганнар, гомерләрен шушы хезмәткә багышлаганнар һәм берсе дә җайлырак, тынычрак, акчасы да мулрак икенче һөнәр сайлау турындагы уйны башларына да китермәгән. Югыйсә, 1956 елдан авылдан ярты гына чакрымда нефтьчеләр промыселы эшли башлый. Эшчеләргә азык-төлек продуктлары өләшенә, акчасы укытучыларныкыннан күпкә югары, соңрак Алабугадан квартиралар бирә башлыйлар. Юк, укытучыларыбызның берсе дә авылын калдырмый, мәктәбен ташламый. Менә кайда ул чын фидакарьлек, чын күңел байлыгы үрнәге! Афәрин, укытучыларым!

Ә халыкка күрсәткән культура-масса эшләрен кем җитәкләгән, оештырган, үз иңнәрендә алып барган? Укытучы, билгеле. Бәзәкә мәктәбе укытучыларының да ел саен халык алдында куйган концерт-кичәләрен санасаң, барысы күпме булыр иде икән? Ә алар күрсәткән спектакль-тамашалар үзләре ни тора иде! Бу турыда бары тик матур сүзләр, җылы хисләр белән генә сөйләргә мөмкин. Чөнки остазларыбыз сәхнәдә дә нәкъ артистларча, үз ролен оста

башкару өчен, образларга кереп, шундый тормышчан да, сәхнәчә дә чын сәнгать әсәрләре тудырдылар. Алар иң катлаулы, зур күләмле әсәрләрне куярга да курыкмадылар. Мәсәлән: “Зәңгәр шәл”, “Ташкыннар”, “Шомлы көннәр”, “Тормыш җыры”, “Галиябану”, “Шәмсекамәр”, “Миркәй белән Айсылу”, “Соңгы әманәт”, “Күзләр”, “Казан сөлгесе” һәм башка драма әсәрләре шундыйлардан. “Зифа” спектаклендә сыйныфташым Мирзаһит Гимашев (инде мәрхүм) белән үзем дә уйнаганым истә. Без ул вакытта 5 нче сыйныфта укый идек. Баш герой Зифаның балалары Идел белән Гөлли булып уйнадык.



"Төнге шәүләләр" спектакленнән күренеш. Уңда:Фәйзелхак абый һәм Зәйтүнә апа. 1978 ел

Әйе, үзләренә бик авырга, тыгызга туры килсә дә, мәктәп коллективы, халыкка культура-масса хезмәтен күрсәтүне традициягә әверелдерде, аны дистә еллар буе саклады, ел саен зур чыгыш ясап, авыл халкына чын бәйрәм бүләк итте, аны сөендерде, үзе дә рәхмәтләр, мактаулар ишетте. Бу спектакльләр барган кичләрдә клубта алма төшәрлек тә урын булмый иде. Урын тапмаган тамашачылар идәндә утыралар, тәрәзә төпләренә “кунаклыйлар”, андый урыннарга эләкмәгәннәр – сыңар аякта басып торалар. Бу сиңа “Әлепле артистлары” уйнавы гына түгел, ә чып-чын бәзәкәле “камалчылар” чыгышы була иде...

Рәхмәт сезгә, сәхнә җанлы укытучыларыбыз!



Көләчевлар династиясе

Сугыштан соңгы еллардан башлап 90 нчы елларга кадәр Бәзәкә мәктәбендә биш туган Көләчевларның эшләве – авыл һәм мәктәп тарихында күркәм һәм шатлыклы күренеш була: Көләчева Мәрьям, Гатауллина (Көләчева) Мәэлүфә, Көләчев Фоат, аның хатыны Тажетдинова (Көләчева) Мәүлия, Көләчев Тәгъзим – мәгариф өлкәсендә бишесе дә бер үк елларда диярлек эшләп, төрлесе төрле фәннәр укыттылар. Әтиләре Гатаулла абзыйның бертуганы Габдулланың уллары һәм киленнәре Әхәт, Мәсгүдә, кызлары Рәфия, Зиннур абый, Сабира апаларны да кушсаң – династия бер дистәгә тула!

Барысының да мәктәптә хезмәт итү елларын бергә исәпләсәң, күпме булыр иде икән? Әйдәгез, санап карыйк: 250 елдан да артып китә!

Бу династиянең өч хатын-кызы башлангыч мәктәп укытучылары иделәр. Шуларның берсе – минем беренче укытучым булды.

Укытучым минем. Иң беренчем...

Сабыйлыктан яңа чыгып килүче бала, беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергәч, аны башлангыч сыйныф укытучысы каршы ала. Бу онытылмаслык мизгелдән баланың мәктәпкә үз карашы барлыкка килә, мөлаем йөзле апаларын, сабыр холыклы абыйларын гомере буе онытмый ул.

Бала күңеле – нәфис ак кәгазь,
Әле бит ул каләм күрмәгән.
Әле беркем аның күңелендә
Тылсымлы эз салып йөрмәгән.

Дөнья аңа яңа яуган ак кар –
Тели бала барын аңларга.
Тәүге юлны бала күңеленә
Ата-ана һәм беренче
Укытучы тиеш язарга...



Авылның түбән очында, иске мәчет бинасында урнашкан мәктәпнең бусагасын 1954 елның 1 сентябрендә тәүге мәртәбә атлап керү, кулга тоткан буйлы дәфтәр һәм каләм, беренче китабым “Әлифба”, җылы карашлы, йомшак күңелле беренче укытучым Гатауллина-Көләчева Мәэлүфә Гатаулла кызы күңелемдә мәңге жуелмас якты эз булып калдылар.

Гап-гади бүлмәне “класс” дип атау, өстәлгә охшамаган парталар артына утыру, акбур дигән хикмәтле әйбернең тактада эз калдыруы, аннары чүпрәк белән сөрткәч эзнең юкка чыгуы, укытучы апаның дәреслек дип аталган китаптан бик тиз һәм җайлы итеп укуы – болар барысы да минем өчен, ягъни кичә генә балалар бакчасында йөреп, бүген мәктәпкә килгән авыл баласы өчен, хикмәтле могҗизага яки космос ачуга тиң иде. Менә шушы “белем” дигән тылсымлы могҗизалар иленә безне тәүге укытучыбыз Мәэлүфә апа алып кереп китте.

Мәэлүфә Гатауллина-Көләчева Бәзәкә авылында крестьян гаиләсендә туа. 1930 елда беренче сыйныфка укырга керә. Беренче укытучысы Касыйм абыйсын гомере буе хәтерли, аны мактап сөйли.

Мәктәпне тәмамлагач, яшь кызга сугыш елларында төрле эшләр башкарырга туры килә. Ул сельпо бухгалтериясендә хисапчы, авыл советында секретарь булып эшли.

Сугыштан соң, 1946 елда, Мәэлүфә Бәзәкә мәктәбендә башлангыч сыйныфларда укыта башлый. Алабуга педучилищесында экстерн имтиханнар тапшырып, кулына документ ала. Укытучы Мәэлүфә Гатауллина озак еллар укыту дәверендә күпме балага хәреф артыннан хәреф өйрәтә, матур язу күнекмәләрен булдыра (ул елларда без перолы ручка белән яза идек. 11 нче номерлы перо белән апабыз

безгә дөрес басым белән матур язарга өйрәтте). Хисапсыз шигырьләр ятлата, кечкенә хикәяләр укыта, шулар нәтиҗәсендә балаларның сөйләм телен үстерә, аларга ныклы һәм тирән белем бирә. Ул даими рәвештә үз белемен күтәрә, алдынгы тәҗрибәне өйрәнә һәм үз эшендә файдалана. Эш алымнарын төрләндереп, дәресләрнең эчтәлеген баета, дидактик, күрсәтмә материалларны урынлы һәм киң кулланып уңышка ирешә. Апа безгә кул бармакларының буыннары буенча ай көннәрен, ягъни 30 данмы, 31 дәнме килүен санарга өйрәтте. Әле бүген дә шул ысулны кулланам.

Укытучыбыз класс коллективын тату һәм бердәм туплауга нык игътибар бирә иде. Шушы уңайдан ул безгә бихисап уеннар, җырлар, биюләр өйрәтте. Үзе дә, сабый бала кебек, безнең белән уйнады, көлде. Кышын бергәләп тауда чана шуа идек. Апабызны һәркем үз чанасына утыртып таудан төшү – безнең өчен зур бәхет! Күп вакытта апа белән бергә чанадан мәтәлеп төшеп тә кала идек. Карга батып-чумып кире мәктәпкә кайткач, апа безнең, без апабызның өс-башын себерке белән себерәбез. Һәрберебез апаны себереп калырга тырыша. Ә ул, безгә карап, шатланып, елмаеп-көлеп тора.



Безнең сыйныф. Укытучылар Мәэлүфә апа Гатауллина, Сабира апа Хәсәнова һәм вожатый Зөлхәбирә апа

Табигатькә бик еш экскурсияләр оештырып, укытучыбыз туган якның матурлыгын күрергә өйрәтте, самими күңелләребездә тирә-юньгә мәхәббәт, кешеләргә карата мәрхәмәтлелек, миһербанлылык, намуслылык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләде. Беренче булып ул безгә чигү чигәргә, сәдәф тагарга, май ае чәчәкләреннән тәкыялар үрергә өйрәтте.

...Әле кайчан гына нәни кыз-малайлар, чәчәк бәйләмнәре тотып, беренче мәртәбә мәктәпкә килгән иде. Тырышатырыша хәрефләр танырга, укырга-язарга, санарга, тирәюнь белән танышырга өйрәнә башлауга да 4 ел узып киткән. Менә бүген аларны 5 нче сыйныфка, яңа сыйныф җитәкчесенә, өр-яңа укытучылар кулына тапшырасы. Ничек укырлар, үзләрен ничек тотарлар? Хәерле юл, шәкертләрем. Сез минем йөземә кызыллык китермәссез дип ышанам!

Мөгаллимә Мәэлүфә Гатаулла кызы менә шундый уйтеләкләр белән үзе укыткан балаларны дүрт ел саен озаткан да, яңаларын кабул иткән.

Ел артыннан еллар узган. Ул укыткан меңләгән укучылар ил буенча таралганнар, төрле һөнәр ияләре булганнар, тормышта үз урыннарын тапканнар. Мәсәлән, укучысы Рәмзия Гыймазетдинова (Мөхетдинова) – Бәзәкә мәктәбендә 35 ел укыткан, I категорияле укытучы-методист, Россия Федерациясе мәгарифенең почетлы хезмәткәре; Тажиев Камил – табиб-эпидемиолог, 30 елдан артык Питрәч районының баш санитар врачы булды. Хуҗиәхмәтова Гөлшат – юрист, прокурор һәм Рәшит Исмәгыйлов – подполковник, Чаллыда эчке эшләр бүлегендә хезмәт куялар, Кәлимуллин Рәшит – "КамАЗ"ның автосервис челтәре генераль директоры, "Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе" дигән югары исемгә лаек зат.

Санасаң-исәпләсәң, укытучының андый шәкертләре байтак. Алар беренче укытучылары Мәэлүфә апа Гатауллина-Көләчеваның йөзенә кызыллык китермәгәннәр, киресенчә, аны зурлаганнар, данлаганнар.

Олуг рәхмәт Сезгә, кадерле тәүге Укытучым! (Китабым язылган көннәрдә беренче укытучым мәңгелеккә күчте. Урыныгыз җәннәттә булсын, Апа!)

Көләчева Мәрьям — ветеран укытучы



1920 елда Бәзәкә авылында крестьян гаиләсендә туа. Әтисе Төхвәтуллин Гатаулла абзый, мәгарифкә уңай карашлы кеше булараk, балаларына урта һәм югары белем бирергә тырыша һәм моңа ирешә дә: биш баласының дүртесе укытучы була.

Олы кызы Мәрьям 40 нчы елны урта мәктәпне тәмамлый, бер ел колхозда эшли. Бөек Ватан сугышы башлангач, Мәрьям Көләчева туган илебезне фашистлардан азат итү теләге белән фронтка китә. Япь-яшь кенә кызларны берникадәр вакыт Мәскәүдә укыталар. Шул ук вакытта алар үзләре яшәр өчен землянкалар һәм дошманны Мәскәүгә кертмәс өчен окоплар казыйлар. Мәрьям һәм аның дуслары хәрби-һава гаскәрләрендә хезмәт итәләр. Бер төркем кызлар радиолокаторлар ярдәмендә немец самолетларының нинди төрдә һәм нинди биеклектә очканлыгын танып, тиешле урынга хәбәр итеп торганнар. Алар биргән координатлар ярдәмендә, зенитчылар, дошман самолетлары һөҗүмен кире какканар, юк иткәннәр. Шулай итеп, сугышчы кызлар Мәскәүне саклауда үзләреннән зур өлеш керткәннәр.

Сугыштан Мәрьям Гатаулла кызы 1945 елда исән-имин әйләнеп кайта һәм башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли башлый, экстерн имтиханнар бирә. Үз һөнәрен ярatып башкаручы, тырыш, сабыр һәм киң күңелле укытучы була ул. Мәктәп бусагасын яңа гына атлап кергән балаларның якын дустына, киңәшчесенә әверелә.

30 ел эшләү дәверендә ничә мең күнегү-мисаллар эшләткән, аларны көн саен тикшергән, контроль эшләр үткәргән мөгаллимә. Яхшы нәтиҗәләргә сөенгән, начар-



лары өчен көенгән, кабат-кабат аңлаткан, өстәмә дәресләр уздырып, авыр үзләштерүче балаларны өендә дә укыткан. Аның тырышлыклары, еллар узгач, куанычлы нәтиҗәләр биргән. Күп кенә шәкертләре, югары уку йортларын бетереп, зур кешеләр булганнар. Мәсәлән, Гыйльфанов Мехәмәтнур Нуриәхмәт улы – Татарстанның атказанган агрономы, Ленин һәм Хезмәт Кызыл байрагы орденнары кавалеры, Дәүләт Югары Советының 3 чакырылыш депутаты булган шәхес.

Татарстанның атказанган табибы, профессор, онкология һәм хирургия кафедрасы мөдире, Санкт-Петербург фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Тажиев Рифкать Минһаж улы – шулай ук аның укучысы.

Бу шәкертләре мөгаллимәнең йөз аклыгы, күңел шатлыгы, горурлыгы.

Мәрьям апа 1975 елда пенсиягә чыкты. Бөек Ватан сугышы ветераны Мәрьям апа Көләчева балалар арасында еш булды. Үзенең сугышта күргәннәрен сөйләгәндә, еш кына дус кызларын сагынуын әйтә иде: “Төшләремдә полкташ кызларның исән булуларын күрәм. Бергәләшеп сөйләшәбез, көлешәбез, чәчәкләр җыябыз икән. Без бит япь-яшь, чибәр кызлар идек, киләчәктә матур тормыш, гаилә кору турында хыялландык. Юк шул, болар күпләребез өчен насыйп булмады. Уянып китәм дә, “ah!” итәм. Кызларым-дусларым төштә генә минем белән, чынлыкта алар, яшәүнең тәмен-ямен дә татымыйча, якты дөнья белән күптән хушлаштылар бит!”...

Ветеран апабыз шул урында бик озак сүзсез кала...

Мәрьям апа Көләчева бүген безнең арабызда юк инде. Ул 2000 елда вафат булды. Тыныч йоклагыз, кадерле Укытучы.



Тажетдинова-Көлҽева Мәүлия

Мәүлия Тажетдинованың мәктәп еллары авыр чорга туры килә. Ул 4 нче сыйныфны тәмамлагач, Бөек Ватан сугышы башлана. Ике абыйсы да туган илне сакларга яуга китәләр. Тиздән Мәүлия җидееллык мәктәпне тәмамлый. Бу вакытта аңа 16 яшь була (1924 елгы).

Гаиләләренә авыр була. Йортта баш бала булып Мәүлия кала. Авылда җидееллык мәктәп кенә. Ул Бондюг мәктәбенә сигезенче класска укырга китә. Укыган өчен дә, квартирада торган өчен дә түләргә кирәк. Ә акча юк. Кыз кире авылга кайтырга мәҗбүр була. Яшьтәш кызлар белән бергә колхозда эшли башлый. Алар чүп-үләннәре утыйлар, печән җыялар, урак уралар.

1947 елда Алабуга китапханә техникумына укырга керә. Техникумны яхшы гына тәмамлап, туган авылы мәктәбенә китапханәче булып эшкә кайта. Ул балалар белән уртак телне бик тиз таба, укучыларны китапханәгә күпләп җәлеп итә. Яшь белгеч яңа кайткан китаплардан күргәзмәләр булдыра, китап укучылар конференцияләре үткәрә, язучыларга, шагыйрьләргә багышланган бюллетеньнәр чыгара, балалар көче белән эчтәлекле, кызыклы әдәби кичәләр оештыра. Аңа мәктәптә пионервожатый булып эшләргә дә, авыл яшьләре мәктәбендә укытырга да туры килә.

1952 елда Мәүлия Тажетдинова Алабуга укытучылар институтына читтән торып укырга керә һәм аны 1956 елда тәмамлый, педагогик эшен дәвам итә. Бик күп еллар башлангыч сыйныфларда укыта. Балаларга башлангыч белем бирү күп көч куюны, балалар дөньясы белән яшәүне таләп итә торган эш. Педагог Тажетдинова бөтен көчен-энергиясен, тырышлыгын, сабырлыгын укучыларына бирә. Дәресләрен балалар кызыксынырлык, актив катнашырлык итеп үткәрә, төрле уңай һәм нәтиҗәле алымнарны оста куллана, тирән белем бирә. Укучылары белемле, тәрбияле, инсафлы булсыннар өчен армый-талмый эшли, вакытын һәм көчен кызганмый, алны-ялны белми.



Һәрвакыт тулы өлгерешкә ирешә, мактаулы укытучы исемен йөртә. Мөгаллимә Мәүлия Тажетдинова авыл халкы арасында да зур хөрмәт казана. Җәмәгать эшләрендә актив катнаша, радиотапшырулар җитәкчесе була, балалар белән чыгышлар ясый. Үзе матур җырлый, оста бии.

Халыкка культура хезмәте күрсәтүгә зур игътибар биргән Мәүлия апа башлап йөрүчеләрдән була. Ул сәхнәдә бик күп образлар иҗат иткән үзешчән артист та. Мәсәлән, "Күзләр" спектаклендә баш герой Рәйсә ролен шулкадәр ихласлык белән, тормышчан итеп уйный, сагышлы-моңлы итеп җырлый – залдагы бөтен халык елый.

"Яшьрәк чакларда спектакльләргә катнашкан вакытларда кыенга да туры килде, – дип искә ала иде "артист" апабыз. – Өйдә өч бала, дәрес-планнарны иртәрәк әзерләп, кичен клубка йөгерәм. Ирем Фоат та шунда, ул да уйный, сәхнәдә ут, тавыш, декорация көйләү буенча җаваплылык аның өстендә. Икәүләшеп көн дә чыгып югалганга, каенатам белән каенанам риза да түгелләр иде. Без әле педсовет, әле профсоюз җыелышы дип алдашырга мәҗбүр була идек. Шулай бервакыт Н.Исәнбәтнең "Зифа" спектаклен куябыз. Минем сәхнәдә им-том белән мавыгучы Кәләмзә булып, нәкъ "сихер" ясап маташкан вакыт. Берзаман зал буйлап, таягын болгый-болгый, берәү сәхнәгә ябырылды: "Ах, имансызлар, менә нишләп ятасыз икән сез монда", – дип, сәхнә уртасына ук килеп тә менде. Таныдым – каенатам Гатаулла!

Мин бер мәлгә югалып калдым. Ә ул сугарга дип өстемә килә. Шул мизгелдә, сәхнә артындагылар тиз генә чыгып, картның таягын тартып алып, сәхнәдән чишенү бүлмәсенә алып китмәсәләр, нәрсә булып бетәр иде бу көтелмәгән тамаша, белмим. Аны тынычландырып, өйгә

үк озатып куйганнар. Ә мин, һушымны җыеп, яңадан үз ролемне дәвам иттем. Менә шундый хәлләр дә була иде безнең белән,” – дип, көлә-көлә сөйли иде Мәүлия апа ул вакытлар турында.

Мөгаллимә Таҗетдинованың хезмәт уңышлары укучыларының алдагы тормышында күренә. Шулар арасыннан Нәҗметдинов Сәетнур – Татарстанның атказанган табибы булды, Закиров Фәйзелхан, Таҗиева Рүзилә – медицина институтын, Габдрахманов Рәшит – төзелеш, Хуҗина Әлфирә – Чаллы политехника, Сабитова Лилиана – икътисад, Исмәгыйлова Ризәлә, Гимазова Гөлнар, Хәбибуллина Гүзәлия – педагогия институтларын тәмамладылар.



Мәүлия апа һәрчак балалар арасында. 1980 ел

Аның укучылары теләсә кайсы тармакта йөзгә кызыллык китермичә эшлиләр, аларның уңышларында, һичшиксез, Мәүлия апаның өлеше зур.

Мәүлия апа ире Көләчев Фоат белән өч бала тәрбияләп үстерә. Балалары үзләре сайлаган һөнәрләре буенча эшлиләр, үз гаиләләре белән яшиләр.

Мәүлия апа мәктәптә 35 ел эшләп, лаеклы ялга чыга. Әмма каты чир 1991 елда Мәүлия Таҗетдинова-Көләчеваны безнең арабыздан мәңгелеккә алып китте.

Тыныч йоклагыз, кадерле Укытучы.

Күңеле дөрес аның

– Әнием, җаным, тукта, тагын бераз гына торыйк инде.

– Юк, кызым, җитте, күрүләре бар.

– Әнием, сагынам, бик сагынам мин сине.

– Мин дә, кызым, сагынам, юксынам үзеңне.

– Ал инде, әни, мине үз яныңа, сөйләш тагын бер мәртәбә.

– Кызым, булмагач булмый инде. Абзаң риза түгел. Тәкъдиребез шундыйдыр, бәгырькәем. Түзәргә кирәк. Киләчәктә, бәлки, тормышыбыз берәр ничек җайланыр.

– Кайчан соң ул, әнием?

– Бар, кызым, бар, кайт инде. Мин дә китим. Югалтулары бар. Кеше күзенә бик чалынырга тырышма, яме.

– Әни, әнекәем, сау бул, мин тагын килермен, яме.

Ике кешене бер итеп кысып кочаклаган куллар бераз бушап, ниһаять, бер-берсеннән аерылалар да тагын берничә минут сузылып торалар. Аннары ана белән кыз, икесе дә кинәт борылып, ашыгып китеп баралар: берсе – югарыга, икенчесе – түбән очка.

Югарыга таба йөгергән кыз – биш яшьлек Әминә Бәдертдинова була. Ул 1923 елда Бәзәкә авылында дөньяга килә. Кызга ике яшь тулганда, әнисе икенче баласын көткәндә, әтиләре кинәт үлеп китә. Ике бала белән калган әнисенә озакламый ире йортында урын калмый. Тиздән, өч бала белән тол калган яхшы тормышлы бер ир, кече кызы белән әнисен үзенә хатынлыкка ала. Ә Әминәне сыйдырмый. Ятим кызны әтисенең абыйсы – Кәшби абзый тәрбиягә ала.

Әнә шунлыктан, ана белән кыз, бер-берсен күрер өчен, аулак тыкрыкларда, кеше күп йөрми торган урыннарда очраша башлыйлар. Һәр очрашкан саен киләчәктә язмыш үзләренә карата мәрхәмәтле булыр дип өмет итәләр.

Әмма, язмышлардан узмыш юк дип, тикмәгә әйтмәгәннәр шул. 1930 елда әнисе кече кызы һәм яңа гаилә-

се белән Уралга кулак итеп сөрелә. Шулай итеп, Әминә бөтенләй ятим кала.

1930 елның көзендә ул 1 нче сыйныфка укырга керә. Класста 25 бала, шуларның өчесе – ятимнәр. Аларны мәктәп хисабына ашаталар, киендерәләр. Җиде сыйныфны тәмамлагач, кемнәр Бондюгка ФЗӨгә, кемнәр Камайга ШКМга (школа колхозной молодежи) укырга китәләр. Ә Әминә авылда кала, карт бабасын ташламый. Шул елларда авылда, бөтен илдәге кебек, ликбез (ликвидация безграмотности) оештырыла. Ягъни, белемсезләрне аерым өйләргә җыеп укыту була ул. Әминә дә, мәктәп кушуы буенча, 20 кешене әлифба укырга, язарга өйрәтә. Соңыннан районнан килгән комиссия имтихан ала. Әминә укыткан 20 кешегә "Аз белемле" (малограмотный) дигән исем бирелә. Ә укытучы кыз Әминәгә зур бүләк: бер капчык он бирәләр.



1938 елда Әминә инде 8 нче сыйныфта укый башлый. Беркөнне Әминәне директор янына чакыралар. Кыз, гажәпләнү катыш, чын-чынлап борчуга кала. "Ни булды икән? Әллә бер-бер гаебем бармы? Мәктәптә сигез ел укып, директор бүлмәсе ишегенең кайсы якка ачылганын да белмим ич мин". Шундый борчулы уйлар белән ул кабинет ишеген шакый.

– Габдрахман абый, мине чакырган идегезме?

– Әйе, Әминә, үт әйдә, утыр. Сиңа бик җитди сүзем бар.

Кызның күңеленнән кабат бер мәртәбә курку хисе йөгереп уза. Ул урындыкка утыра.

– Әминә, менә нәрсә, сеңлем. Син мәктәпнең уку алдынгысы. Үзең бик акыллы, инсафлы, оештыру сәләтенә ия, һәр эштә актив кыз. Безнең бүгенге көндә пионервожатыебыз юк. Моңарчы бу эшне алып барган апабызның

дәресләре күп, ул җитешә алмый. Без, коллектив белән киңәшләштек тә, бу вазыйфаны синнән дә оста башкаручы кеше булмас, дигән нәтиҗәгә килдек. Бу фикерне сиңа җиткерергә дип, менә үзеңне чакырдым. Әмма башта сиңа комсомолга керергә кирәк булыр. Я, ни әйтерсең?

– Абый, мин, минем... – дип сүз башлаган кыз төртелеп кала.

– Беләм, бабаң мулла, бик диндар кеше. Шуңа күрә, бүген кайткач, бабаң белән сөйләшегез, уйлашыгыз. Җавабың белән иртәгә минем янга керерсең.

... Кәшби карт, бу хәбәрне ишеткәч, байтак кына сүзсез тора. Кыз куркып кына җавап көтә. Менә бабасы сүз башлый.

– Ярар, кызым, нишләмәк кирәк. Булмаса, син алын бу эшкә. Алай акча да түләгәч, үзеңә өс-баш алырга иш янына куш булыр.

Әминә үз колакларына үзе ышанмый. Ә Кәшби карт, тагын бер кабат кызга карап, өстәп куя.

– Күлмәгең урыс булса да, күңелең дөрес булсын. Онытма шуны, кызым.

Шулай итеп, 8 нче сыйныф укучысы Әминә Бәдертдинова Бәзәкә мәктәбендә уку белән беррәттән, пионервожатый булып эшли башлый.

1940 елда мәктәпнең беренче чыгарылыш укучысы буларак, Әминә кулына аттестат ала. Ә көзен инде директор Мәрдәнов абыйсы аңа приказ алып кайта һәм башлангыч класска укытучы итеп билгели. Яшь кыз, бар тырышлыгын куеп, кечкенәләрне укыта башлый. Алабуга педучилищесында экстерн рәвештә башлангычларны укыту методикасыннан имтиханнар бирә, кулына документ ала. Шул көннәрдән башлап 38 ел гомерен яраткан эшенә багышлый.

...Сыйныф бүлмәсендә тынлык. Нәни кызлар-малайлар, тырышып-тырышып, ак дәфтәр битләренә тәүге хәрефләр язалар. Әй, кыен да икән бу хәреф дигәннәрен язуы! Укытучы апа аларны тактада ничек тиз дә, матур да яза соң? Мин дә шулай булдыра алырмынмы икән?

Мөгаллимә Әминә Бәдертдинова укыткан балалар

күңелендә шундый уй-сораулар тумый калмагандыр, билгеле. Чөнки ул үз үрнәгендә күпме укучыларны матур язарга, тыныч, ягымлы тавышы белән хәрефләрдән, сүзләрдән җөмләләр укырга өйрәткән.

1941-42 елларда һәр класста 42 шәр бала укый. Башлангычта дүрт параллель: “а”, “б”, “в”, “г” класслары була

– 38 ел укыткан чорымда күчми калучы укучым булмады, – дип горурланып сөйли Әминә апа, фотосурәтләрдән укучыларын барлап. – Иң истә калган укучым, горурлыгым – Мәхмүтова Альта булды. Ул бик тырыш, күп укый торган кыз иде. Тормышта да югары дәрәҗәгә иреште: галимә булды, фәнни эшләр, китаплар язды. Икенче укучым – Сәлимуллина Миңнур шулай ук бик тәртипле, әдәпле кыз иде. Максатка ирешү өчен бөтен көчен, сәләтен биреп тырыша иде. Шунлыктан алдагы көндә танылган хирург, олы табибә булды.



Сугыш чоры балаларын укыткан мөгаллимә Әминә Бәдертдинова (аның сул ягында Альта Мәхмүтова). 1946 ел

Әйе, хезмәт юлын сугыш елларында башласа да, Әминә Бәдертдинова йөзләренә сугыш күләгәсе ягылган сабыйлар күңеленә өмет чаткылары, шатлык нуры өреп, аларга ныклы белем бирергә тырышкан. Сугыш чорында

Әминә апа үзе дә 4 хатын-кыз белән Белоус урманында бер ай 200 кубометр утын әзерли. Директор Гөлсем апа үзләренә ипи китереп тора, шуны кура җиләге, хуҗалардан алган сөт белән ашыйлар. Аш юк, ит юк. Әмма ничек булса да түзәләр, тапшырылган эшне башкарып чыгалар, мәктәп эшләүдән туктамый. Шул ук афәтле елларда укытучы кызлар (ир-егетләр сугышта) авыл халкының күңелен күтәрүдә, мораль яклауда зур тырышлык күрсәтәләр. Һәр атна азагында алар концерт-спектакльләр куялар. Колхозда эштә вакытта, ял иткән арада репетицияләр ясыйлар. Кесәдә рольләр язылган кәгазьләр йөртәләр, шуны ятлый-ятлый эшлиләр. "Әгәр бер атна клубта концерт яки спектакль куймасак, кешеләр өйгә киләләр иде. Үзем гел төп рольләрне башкардым: Мәйсәрә, Галиябану, Шәмсекамәр булдым. Әле бервакыт, "Асылъяр"да, егет роленә ир-ат тапмагач, Шәрәф булып үзем уйнадым. Күкрәгемне кысып бәйләдем, чәчәләремне фуражка астына җыйдым. Бик чибәр егет булдым. Халык яратып карады. Гомумән, халык безне ярата иде, "юанычыбыз" дип атыйлар иде", – дип сагынып, елмаеп искә ала ул елларны ветеран укытучы.



Әминә чынлап та чибәр кыз була. Озын чәч толымнары, кыйгач кашлары, карлыгандай күзләре, зифа буй-сыны белән ул әллә кайлардан яктырып, балкып тора. Аңа карап һәркем соклана, елмая. Үзе бер дигән җырчы, менә дигән биюче. Сугыш башланган җәйне алар Казанда үткәрелгән сәнгать олимпиадасында (ул вакытта сәнгать концертлары, фестиваль-бәйгеләр "олимпиада" дип аталганнар) катнашалар. Әминә анда оста итеп бию башкара, бәзәкәлеләр Казаннан бүләкләр алып кайталар.

Әминә апа Бәдертдинова турында язмамны тәмамлаганда, җыйнап шуны әйтәсем килә: мәктәптә дә, җәмә-



гать эшләрендә, гаиләдә, халык арасында да гомере буе ул йөзе якты, сүзе туры, күңеле дөрес кеше булды.

Фидакарь хезмәтләре өчен мөгаллимә Әминә Бәдертдинова күп Мактау кәгазьләре, медальләр белән бүләкләнә. 1969 елда аңа "Халык мәгарифе отличнигы" дигән мактаулы исем бирелә. 1975 елдан ул лаеклы ялда. Олы рәхмәт, саулык-байлык, бәрәкәтле-сәгадәтле гомер Сезгә, кадерле Олуг Укытучы.

Олы йөрәкле кечкенә мөгаллимә

Гайнуллина Гөлсем Гатиатулла кызы 1917 елда Чаллы районының Чыршылы авылында туа. Шул ук елны аларның гаиләсе Белоус авылына күчеп килә. Әмма бик тиздән әнисе үлеп китә, кызның 3 яшьлек вакытында кисәк авырудан әтисе дә вафат була. Берсеннән-берсе кечкенә алты баланы Бондюг балалар йортына җибәрәләр.

Гөлсем Гайнуллина Бондюг поселогының рус мәктәбендә 7 сыйныф тәмамлый. Аннан соң ФЗӨ мәктәбендә лаборанткага укып чыга. Ләкин бу һөнәре буенча эшләми, укытучы булу теләге белән Алабуга педучилищесына керә. Аны 1934 елны тәмамлый һәм хезмәт юлын Алабуга районының Бөрешле мәктәбендә башлый. Биредә ул бер ел эшли. 1935 елның көзендә, бер очрашу вакытында, кыз белән Бәзәкә авыл советы рәисе Гыйльфан Гыймазетдинов сөйләшә: "Әйдә, бездә укыт", – дип, авылына чакыра.

Шулай итеп, яшь белгеч Бәзәкә мәктәбендә башлангыч сыйныфларда укыта башлый. Кечкенә генә буйлы, бик җитез, кыю кыз Гөлсем, җиң сызганып, авыл балаларына белем бирергә керешә. Авыр еллар. Ашарга да, киенергә дә юк белән бар арасы. Уку әсбаплары җитешми. Дәрес калдырулар еш күренеш. Шулай да мөгаллимә Гөлсем, башка укытучылар белән берлектә, өйдән-өйгә йөри, балаларны җыя, ата-аналар белән сөйләшә, уку процессын өзәргә юл куймый. Чиктән ашкан авырлыкларны җиңә-җиңә, балаларга белем нигезләрен бирүгә, аларны зыялы, миһербанлы итеп тәрбияләүгә зур көч куя.



Дәһшәтле сугыш елларында Гөлсем Гайнуллина сугышка киткән җитәкченең эшен – директорлык вазыйфасын үз өстенә ала. Шушы кечкенә дә – төш кенә хатын, башлангыч сыйныф укытучысы, ул елларда ирләр өчен дә авыр, катлаулы эш-гамәлләрне үз вакытында, тиешле тәртиптә намус белән башкарып чыга. Мәктәпне җылыту өчен хатын-кыз укытучылар һәм өлкән сыйныф укучылары белән Белоус урманында (шунда ук кунып калып) унбишәр көн агач кисүне, аны ат, сыерлар белән Кама бозы өстеннән мәктәпкә ташуны оештыра, мәктәп бинасында даими җылылык булдыра, районга барып, укытучыларга хезмәт хакларын үз вакытында алып кайта.

1948 елда КПСС члены була, озак еллар мәктәпнең партия оешмасы секретаре булып эшли, күп еллар башлангыч укытучыларының методик берләшмәсен җитәкли. Шушы мәктәптә 1966 елга кадәр укыта, 1970-72 елларда, пенсиягә чыккач та, интернатта тәрбияче булып эшли. Озак еллар эшләү дәверендә ул күп Мактау грамоталары,



1962 ел

медальләр ала, “Хезмәт ветераны” була.

Гөлсем Гайнуллинаның укучылары, ныклы белем алып, бик күпләре югары уку йортларын бетерделәр. Академик Мансур Нәбиуллин, шагыйрь Марсель Гыймазетдинов, фәннәр кандидаты, доцент Сәлахи Тажиев, СССРның мәгариф отличнигы Шәмсия Ибәтуллина, Камил Насыйфуллин һәм башкалар – аның укучылары. Аларның уңышларында Гөлсем апаның өлеше чиксез зур.

Хөрмәтле мөгаллимә инде вафат. Урының оҗмахта булсын, кадерле Укытучы.

“Апа-а-а, без Сезне көтә-ә-б-е-е-з”

Һавада эре-эре кар бөртекләрен әле бер, әле икенче якка бөтерә-бөтерә җил тузына. Кичтән үк котырынган буран күз ачарга да ирек бирми, сулышны кыса. Алда, тирәюньдә берни күренми. Бары тик юлның як-ягына кадап куелган “маяк” наратларны, бик игътибар белән караганда гына, шәйләп була. Шушы юлдан кар көртләрен ера-ера берәү бара. Ул әле якасын күтәрә төшә, әле җил каерып ачкан пәлтә итәкләрен ябып, төзәтеп куя, кулындагы сумкасын күкрәгенә кыса. Шулвакыт ерактан, каяндыр алдан, җил улавына кушылып, һавада тонык кына аваз ишетелә: “Апа-а-а, без сезне көтәб-е-е-з”. Юлчы, бер мәлгә туктап кала, тавыш килгән якка кулын болгап ала. “Хәзер, хәзер, балалар”, – дип, үз алдына җавап кайтара да, адымнарын тизләтә.

Зәйтүнә Галиәхмәт кызы Галиева 1925 елда Бондюг районының Татар Тәкәше авылында дөньяга килә. Тыйнак, тырыш кыз Зәйтүнә кечкенәдән үк балалар укытырга, язмышын мәктәп белән бәйләргә хыяллана. Тик бу хыяллар тормышка ашканчы әле бик күп кырыс еллар, авыр юллар узарга, тормышның михнәт-газапларын, ачлык-ялангачлыгын татырга туры килә аңа. Әмма, кыенлыкларга карамастан, белем алуга омтылышы, матур киләчәк төзүгә хыяллары зур була яшь кызның.



Күрше Бәзәкә авылында җидееллык белем алганнан соң, Зәйтүнә Алабуга педучилищесында башлангычларны укыту методикасы буенча экстерн рәвештә имтиханнар бирә, укытучы исемен ала, алга таба ел саен диярлек белемен күтәрү буенча курслар үтә.

1947 елда ул Абалач мәктәбендә укыта башлый. Шушы мәктәптә эшләгәндә үзенең язмышын фронттан яңа гына кайткан укытучы егет Фәйзелхак Хөснетдинов белән бәйли, Бәзәкә килене була. Алга таба алар дус-тату гаилә булып гомер кичерәләр һәм дүрт бала үстерәләр.

Абалачтан Бәзәкәгә яшәргә кайткач, Зәйтүнә укыту эшен туган авылы Тәкәштә дәвам итә. Ике авыл арасы өч километр чамасы. Мөгаллимә 20 елга якын буран дими, яңгыр дими, аң-белем һәм тәрбия бирү өчен көн дә шушы юлдан үтә. Исәпләп карасаң, ничә чакрымнарга басты икән ул юллар?!

Мөгаллимә, укучылары тирән белемле булсыннар өчен, бар тырышлыгын куя, белемен эшкә җигә, дәресләрен җитди дә, шатлыклы да итәргә омтыла. Моның өчен ул һәр дәресендә диярлек уеннар куллана. Чөнки уеннар уйнау, табышмаклар, мәкальләр куллану балаларга белемне үзләштерергә ярдәм итә, мөстәкыйльлек, җитезлек, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияли, өйрәнгән кагыйдәне аңлауга, алган белемнәрне кабатлауга һәм ныгытуга булыша. Менә ни өчен укучылары җитди дә, шаян да, сөйкемле һәм тәмле телле, үзләрен сөендерә дә, дәртләндерә дә белгән апаларын яраталар, хөрмәт итәләр икән.

1968 елдан Зәйтүнә Галиева Бәзәкә мәктәбендә укыта башлый. Зур коллективта да эшен оста белүче, балаларны яратучы, һәр сабый язмышын үз йөрәгеннән үткәрүче, балаларга икенче әни була белгән зирәк педагог һәм игелекле җан итеп күрсәтә.

Җәмәгать эшләрендә дә иң актив кешеләрнең берсе була ул. Фәйзелхак абый белән күпме спектакльләрдә, концертларда катнашып, онытылмас образлар тудыралар.

Инде пенсиягә китәр вакыт җиткәч тә, ул үзе кебек сәхнә осталары Әдия, Мәүлия, Шәргыя апалар белән концертларда катнашты, җырлады, биеде, район смотр концертларында еш чыгышлар ясады.



Районның мәгариф профсоюзы комитеты оештырган чаңгы ярышларында "50 яшь һәм аннан да өлкәннәр" командасында теләп катнаша иде. "Иң беренче киттем, иң азактан килдем", – дип, елмаеп килә иде ул финишка кулына чаңгыларын тотып, – үзебезнең местком рәисен "поддержать" итеп катнаштым инде, – дия иде көлә-көлә.

Менә шундый ачык күңелле, риясыз, йөзеннән нур, ихласлылык бөркелеп торган хөрмәтле шәхес иде ул Зәйтүнә апа.

1980 елда Зәйтүнә апа лаеклы ялга чыкты. Яраткан хезмәтенә багышланган гомер мизгелләрен барлап, хатирәләргә бирелгән минутларда бик еш болай дип сөйли иде: "Күз ачмаслык яңгырлы-буранлы көннәрне укучыларым мине Тәкәш үренә кадәр каршыларга киләләр иде. Мәктәп белән үр арасы – ярты чакрым чамасы. Шул балаларның "Зәйтүнә апа-а, без сезне көтә-б-е-е-з", – дип кычкырган тавышлары бүген дә колагымда яңгырый. Ул аваз – юлымда кабынган якты маяк иде минем өчен.

Үргә менеп җитүгә, балаларым мине чолгап алалар, кочаклыйлар, өстемдәге карны кагалар. Кайсы күшеккән

кулларыма үзенең җылы, йомшак бияләен кидерә, кемдер нәни куллары белән битемә, керфекләремә сарган бәсне җебетә. Ә малайлар, шундук сумканы алалар, мине көчләп диярлек чанага утырталар. “Апа, без Сезне бик тиз мәктәпкә китереп җиткерәбез. Тотыныгыз, апа”, – дип кычкыралар да, биш-алты малай баудан тартып, авылга элдерәләр. Ә мин, чанада бөрешеп утырган көе, шушы сабыйларның кече күңеллелегенә, миһербанлылыгына күңелем нечкәреп, елыйм да, елмаям да...



Зәйтүнә апаның укучылары инде 10 нчы сыйныфка җиткәннәр

Димәк, мин балаларыма кирәк кеше. Алар мине яратуларын, кадер-хөрмәт итүләрен еллар узгач түгел, ә бүген үк, менә хәзер белдерәләр икән, укытучы өчен болар шатлык, сөенеч, зур рәхмәт түгелмени?

Сагынам шул елларны... Әгәр мөмкин булса, шул елларга, карлы-буранлы юлларыма кире кайтыр идем”, – дия иде ул Тәкәш ягына карап, яшьле күзләрен сөртә-сөртә.

Укытучы Зәйтүнә Галиеваның бер сыйныфтан өч укучысы мәктәпне алтын медальгә тәмамлады. Болар: Бикмөхәммәтова Илсөяр, Гыйльфанова Резидә, Минехаҗиева Раушания. Алар – мөгаллимәнең тырыш хезмәте җимешләре.

1998 елның май аенда Зәйтүнә апабыз бакыйлыкка күчте. Рухыгыз шат, урыныгыз ак булсын, кадерле Мөгаллимә Апа!

Мәгърифәт нуры өләшүче



Укытучы Арыслангали Әюп улы Әюпов бик күп сабыйлар өчен – беренче укытучы. Ул 1918 елның августында Сарман районының Иске Әлмәт авылында ярлы крестьян гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Ике яше дә тулмаган сабый, әти-әнисе ачлыктан вафат булу сәбәпле, ятим кала. Туганнан туган абыйсы аны үз тәрбиясенә ала. Уку яшенә җиткәч, авылларында башлангыч, урта белемне Сарманда ала.

Арыслангали Әюпов 1933 елда Алабуга педтехникумына укырга керә һәм аны 1936 елда тәмамлый. Яшь белгеч, кулына юллама алып, Әгерҗе районының Иж-Бубый авылына килә. Даны бөтен татар дөньясына билгеле булган мәдрәсәле бу авылның мәктәбендә мәгърифәтче Бубыйлар эшен дәвам итү, балаларга тәүге дәресләр бирүдән горурлык хисләре кичерү төмен татырга насыйп була аңа биредә.

1938 елда Арыслангали Әюповны язмыш җилләре ерак Үзбәкстан якларына алып килә. Кышлактан-кышлакка йөреп, яшь татар мөгаллиме үзбәк балаларын укыта, аларга мәгърифәт нуры өләшә, ата-аналар арасында агарту эшләре алып бара.



1939 елның 1 августыннан Наркомпросвещение тарафыннан Әюпов Арыслангали-

ли Бондюг районының Бәзәкә авылына укытучы итеп җибәрелә. Әмма биредә елдан артык эшләүгә, сугыш башлана. Сәламәтлеге буенча аны фронтка алмыйлар, ә Самара өлкәсенең Чапаевск каласына хәрби заводка эшкә җибәрәләр. Биредә ул 1941 елның июленнән 1944 елның 15 августына кадәр маляриолог булып эшли. Яхшы хезмәте өчен Михаил Иванович Калининнан Рәхмәт хаты ала.

1944 елның 1 сентябреннән кабат Бәзәкә мәктәбендә эшли башлый. Сабый балалар, ягъни аңа укырга килгән башлангычлар, укытучыларын беренче күрүдә үк яраталар, үз итәләр, аңа тартылалар. Укытучы, балаларны укырга, язарга, хисапларга өйрәтеп кенә калмый, аларның күңел нечкәлекләрен искиткеч тиз сизә, барлык тойгыларын һәм уйларын аңлый. Яңа теманы ничек итеп сөйләргә, төшендерергә, белемнәрен ничек баетырга киңәшләгән төгәл билгели ул. Дәресләрдә бер генә балага да каты итеп дәшми, ачуланмый, әмма тиешле тәртипне һәрчак таләп итә. Дәрес материалын гади итеп аңлата, балалар арыган очракта, йә җыр җырлатып ала, яки кыска гына әкият сөйли. Шулай балаларны ял иттерә дә, кабат дәресне дәвам итә.

Арыслангали Әюпов укучылары өчен тырышлык, ихтыяр көче, таләпчәнлек үрнәге була.





Аның укучылары Гыймадиев Мөнәвир, Габдрахманов Рәис – төзелеш институтын, Мөхәммәтҗанов Равил – Уфа нефть институтын, Гыйльфанов Рәфис – авиация, Кәшбиева Рәмзия – химия-технология институтын, Гыйльфанова Рәйсә – Тимирязев ис. а/х академиясен, Тажиев Рәфис – ветеринария институтын тәмамладылар, һөнәрләре буенча оста белгечләр булдылар. Алар үзләренә белем нигезләрен биргән беренче укытучы абыйларына чиксез рәхмәтле.

1964 елның мартында Арыслангали абый Әюпов вафат булды. Авыр туфрагыгыз җиңел булсын, кадерле Укытучы.

Балалары сынатмый

Укытучы Нажия Мәхмүтова, беренче сыйныфка килгән балаларның сәләтләрен тикшерү йөзеннән, аларны шигырь сөйләргә такта янына чыгара. Менә кечкенә генә сап-сары чәчле бер кыз (ул Гайнуллина Рәмзия була) такта янына чыга һәм кычкырып сөйли башлый: әлеп, би, ти, си, җомхый...

– Үскәнем, булды, җитте, рәхмәт, шигырь сөйли беләсең икән. – Ә соңгы җөмләне укытучы баланың колагына пышылдап әйтә. – Әмма бу шигыреңне өйдә генә сөйлә, яме, әби-бабаңа. Биредә андыйларны сөйләргә ярамый.

Ә беркөнне Нажия апалары балаларга хәбәр җиткерә:

– Укучылар, бүген безгә комиссия килә.

Тиктормас һәм күп белергә омтылучы Мансур шунда ук сорап куя:

– Апа, нәрсә соң ул комиссия?

– Комиссия ул, балалар, районнан, Казаннан килгән тикшерүче кешеләр. Алар сезнең белемнәрегез белән кызыксыналар. Ни дәрәҗәдә йөгерек укыйсыз, дөрес исәплисез, матур һәм хатасыз язасыз. Менә шуларны тикшерәчәкләр. Җиңеп чыга алырбызмы, укучылар?

– Җиңәбез, апа, нишләп җиңмәскә! – дип, самимилек белән бердәм җавап бирә 4 нче сыйныф балалары.

– Мин сезгә нәрсәләр һәм ничек өйрәттем, шулай эшләгез. Һәр өтер, ноктагызга кадәр игътибарлы булыгыз. Мин ышанам сезгә, укучылар.



Нәҗия Мәхмүтованың укучылары, чыннан да, сынатмыйлар, җиңеп чыгалар бу зур сынау-комиссияне. Классның яртысыннан артыгы контроль эшләрне 4-5 гә эшли, “3”ле 2-3 балада гына, “начар” билге бөтенләй булмый.

Казаннан килгән дәреслек авторлары, Министрлык һәм район мәгариф бүлеге вәкилләре бу уңышка гаҗәпләнәләр дә, укытучыны һәм балаларны уңышлары белән тәбриклиләр дә.

Нәҗия Мәхмүтова 1924 елда Бәзәкә авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1932 елда мәктәпнең беренче сыйныфына укырга керә һәм аны 1942 елда тәмамлый. Сугыш елларында авыл китапханәсендә китапханәче, мәктәптә пионервожатый булып эшли. 1947 елдан авыл Советында секретарь вазыйфаларын башкара. Шул ук елны Алабуга педучилищесында экстерн имтиханнар бирә һәм мәктәптә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшли башлый.

1950 елны Алабуга укытучылар институтын читтән торып тәмамлый.

Нәҗия Мәхмүтова зур һөнәри осталыка ия, инициативалы, иҗади эшли белә торган, үз хезмәтенең чын остасы булган укытучы. Балаларның грамоталылыгын үстерү өчен ул даими иҗади эшләр үткәрә, өстәмә дәресләр бирә. Авыр үзләштерүче балалар белән индивидуаль эш алымнары куллана. Үзе дә күп укый, эзләнә, яңа методик үрнәкләрне үз эшендә сыный, кулланма итә. Ел саен аның 30-40 укучыдан торган сыйныфларында бер генә өлгермәүче дә булмый. Шундый югары сыйфатлы эш нәтиҗәләре күрсәткән һәм балалар тәрбияләүдә фидакарь хезмәте өчен мөгаллимә Нәҗия Мәхмүтова 1966 елда “Халык мә-

гарифе отличнигы”, 1969 елда “Татарстанның атказанган укытучысы” дигән югары исемнәргә лаек була.

Шулай итеп, Нәҗия Мәхмүтова, 1947 елдан башлап, кырык ел гомерен башлангычта һәм соңрак V-VII сыйныфларда татар телен һәм әдәбиятын укытуга багышлый.



Нәҗия апаның укучылары илебезнең төрле почмакларында эшлиләр. Шуларның егермеләбе, югары уку йортларын тәмамлап, намуслы хезмәт итәләр. Менә алар: Бәшәров Фәрит – КАИны тәмамлады, Бәхтегәрәева Мөнирә (педагогик фәннәр кандидаты), Мөхәммәтҗанова Сәкинә, Петрова Тамара, Фәссәхова Әнисә – педагоглар, Нәҗметдинова Зәнфирә, Садриева Розалия – химиклар, Тажиев Шәрифҗан, Гыймадиев Мансур – авыл хуҗалыгы белгечләре, Сәлимуллин Мансур – табиб.

Мөгаллимә үзенең укучылары, аларның уңышлары, җиңүләре белән гомере буе горурланып яшәде.

1987 елда лаеклы ялга чыкты, актив тормыш рәвеше алып барды. Нинди генә чарага чакырсалар да, ул анда катнашты, чыгышлар ясады, истәлек-хатирәләре белән яшь буынга авылыбыз, мәктәп тарихын күзалларга ярдәм итте.

2007 елның августында хөрмәтле шәхес Нәҗия апа Мәхмүтова бакыйлыкка күчте. Урыныгыз җәннәттә булсын, кадерле Укытучы.

Мөгаллимә Роза Кәлимуллина



Роза Кәлимулла кызы 1918 елның 20 июнендә Бәзәкә авылында крестьян семьясында туа. Аның балачагы һәм яшьлеге бик авыр чорда уза. Илдә гражданнар сугышы бара, коточкыч корылык, ачлык. Исән калу өчен кечкенә кыз туганнары белән тормышның һәр мөмкинлегенә чытырдап ябыша. Ничек кенә авыр булмасын, әтиәнисе Розаны мәктәпкә укырга бирәләр. Бәзәкә мәктәбен тәмамлагач, балалар белән эшләү теләге туа һәм ул, Алабугада экстерн имтиханнар биреп, башлангыч сыйныфлар укытучысы һөнәрен ала. Хезмәт юлын 1941 елда Каменский районының Чуракай авылында башлый, соңыннан озак еллар туган авылыбызда эшли. Аның хезмәт стажы 32 елга тула.

Мөгаллимә Роза Кәлимуллина, укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, дәресләрендә һәрбер балага якын килә, укучыларның танып-белү активлыгын үстерергә тырыша. Аларга тирән белем һәм ныклы тәрбия бирү өчен бөтен көчен куя. Фәннәргә кечкенәдән үк кызыксыну уяту максатыннан, һәрбер дәрестә диярлек таратма материаллар, карточка-рәсемнәрдән файдалана. Балаларны үз фикерләрен дөрес һәм эзлекле итеп сөйләргә өйрәтә.

Һәр үткәргән тәрбияви чара аша мөгаллимә үз укучыларында кече яшьтән үк бер-береңә уңай мөнәсәбәт, ярдәмчеллек, җаваплылык кебек мөһим әхлак сыйфатлары тәрбияләргә омтыла.

Башлангыч сыйныф укытучысы Роза Кәлимуллина яраткан эшенә бирелгән, педагогик такт, гаделлек, бала күңелен аңлый белү кебек сыйфатларга ия була.

Озак еллар эшләү дәверендә авыл халкы арасында хөрмәтле булды, чөнки үз вазифаларына намус белән ка-

рады. Роза Кәлимуллина 1973 елда лаеклы ялга чыга.

Укучылары Мехәмәтнур Сабитов – Татарстанның атказанган укытучысы, Халидә Мулланурова, Җәүһәрия Минехаҗиева – шулай ук педагоглар, Илсөяр Әюпова – авыл хуҗалыгы белгече, Вагыйз Сиражетдинов – Казан Эчке эшләр министрлыгында хезмәт куйды. Алар Роза апаны зур рәхмәт хисләре белән искә алалар.

2000 елда Роза апа ахирәткә күчте. Авыр туфрагыгыз җиңел булсын, кадерле Укытучы.

Көйле математик

Аның язмышы искиткеч авыр да, гыйбрәтле дә. Аксакал олы һәм михнәтле тормыш юлы узган шәхес.

Габделхәй Гыйльфанов Гыйльфан улы 1921 елда Бәзәкә авылында крестьян семьясында дөньяга килә. Биш яше тулганда, әнисе вафат була, әтисен, мәчеттә балалар укытканы өчен, төрмәгә ябалар. Шулай итеп, дүрт бала карт әби тәрбиясендә кала.

1929 елда беренче сыйныфка укырга керә. Тик аны, бер гаиләдән өч бала укытып булмый дип (ике өлкән абыйсы инде укыйлар), мәктәптән кайтарып җибәрәләр. Укырга теләгә булган малай моны авыр кичерә. Шулай да, Габделхәй өйдә тик ятмый, абыйлары ярдәмендә һәм үзлегеннән укырга, язарга, хисапларга өйрәнә. 1930 елда аны, инде укый-яза белгәч, 2 нче сыйныфка укырга алалар.

Ятимлектә, фәкыйрьлектә узган сабыйлык чоры авыр була. Әби бик карт, каты авырудан 19 яшьлек апалары үлеп китә, ашарга-эчәргә юк. Шунлыктан язларын дәресләрне еш калдырырга туры килә. Чөнки кечкенә малай да абыйлары белән басу-кырларда өшегән бәрәңге, юа, балтырган эзләп көнозын йөри, арый, талчыга. Җәйге каникулларда да ял эләкми, IV-V сыйныфтан соң һәр җәйне ул бер көн калдырмый яшелчә бригадасында эшли. Монда ичмасам, бригадир күрмәгәндә, бераз кәбестә, помидор ашап була. Шундый юл белән ул үз тамагын үзе туйдыра баш-

лый. Әмма кыенлыклар күреп тә, Габделхәй Гыйльфанов укуын ташламый, тырышлыгын киметми. 1933 елда пионер сафларына керә. 1936 елда VII сыйныфны бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый һәм Алабуга педтехникумына укырга керә.

Биредә уку аның өчен яңа дөнья ачылуга, кояш чыгуга тиң була. Ул анда көнгә 150 грамм икмәк алып, ашханәдә башкалар кебек туклана, ә бу авылдагы җитәр-җитмәс ризыктан күпкә яхшы була. Шуңа күрә тырышып укый, төрле чараларда актив катнаша. 1939 елда техникумны "бик яхшыга" бетерә һәм, уку алдынгысы буларак, Казан университетына юллама ала. Әмма башкалада уку кыска гомерле була: 1939 елның көзендә, II Бөтендөнья сугышы башлану сәбәпле, университеттан хәрби училищега җибәрелә. Ләкин, сәламәтлеге буенча узмыйча, авылга кайта һәм Бондюгның 2 нче мәктәбендә укыта башлый. 1940-41 уку елында Бәзәкә мәктәбенә физика-математика укытучысы итеп күчерелә. Тик уку елын төгәлли алмый, май аенда армиягә алына.



Ә бер айдан... сугыш.

– Сугыш минем бөтен яшьлегемне йотты, – дип, көрсенеп искә ала Габделхәй абый ул дәһшәтле елларны.

Габделхәй Гыйльфанов 1946 елда авылга исән-имин әйләнеп кайта, туган мәктәбендә укыта башлый. Эшләү дәверендә читтән торып укуын дәвам итә. 1949 елда Алабуга укытучылар институтын гел яхшы билгеләргә бетерә, 1956 елда Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика бүлеген тәмамлый.

Бәзәкә мәктәбе укучыларының күпчелеге Хәй абыйның (балалар яратып та, кыскартып та аны шулай атыйлар) математика дәресләренә гашыйк булалар. Чөнки



мөгаллим үз шәкертләрен һәр дәрестә математик могҗизалар дөньясына алып керә, дәресләрен фәнни югарылыкта үткәрә. Әмма ул моны һәр укучы бала аңлар-лык итеп гади, уңай юллар белән төшендерә. Дәресләрдә теоретик белем бирү белән бергә, укучыларның логик фикерләү сәләтләрен үстерүне максат итеп куя, мәсьәләләр чишкәндә балаларның һәр фикерне аңлап үзләштерүләренә, теге яки бу чишелешнең рациональ юлларын табуларына һәм мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәләр ясауларына омтыла. Укытучы сайлаган белем бирү ысуллары укучыларның иҗади сәләтен үстерә, гамәли белемнәрен тирәнәйтә.


Шулай итеп, 1939 елда башланган мөгаллимлек эшен Хәй Гыйльфан улы гомере буе, ягъни 40 ел яратып, тырышып башкарды. Мәктәптә, районда, республикада иң көчле, танылган математиклар исемлегенә керде, икенче төрле әйтсәк, мәктәбебездә "фәннәр патшасы" булган математиканың "патшасы" булды. Аның укучылары югары уку йортларында яраткан фәннәре математиканы бик җиңел укыдылар, бу фәннән көчле студентлар булдылар. Мисал өчен, шәкерте Нәбиуллин Мансур Кәрим улы, Казан авиация интитутын бик яхшы билгеләренә бетереп, теоретик механика кафедрасы каршындагы аспирантураны тәмамлады, галим, академик булды, Спейс-Шатл тибындагы континентара космик ракеталар эшләү өлкәсендә зур хезмәт куйды. Шушы хезмәтләре өчен академик В.М.Кельдыш медаленә лаек булды. Академик Нәбиуллин үз хезмәтләрен фәнни китаплар итеп бастырды һәм остазы Хәй абыйга чиксез хөрмәт белән бүләк итте. Ә мөгаллим аны, изге ядкарь итеп, бүген дә кадерләп саклый.

Үзең чәчкән орлыкларның мул уңыш бирүен күрү, тою өлкән яшьтәге мөгаллим өчен зур куаныч түгелмени?



Билгеле, зур куаныч, олы сөенеч һәм чиксез шатлык! Мөгаллим Хәй Гыйльфанов 1963 елда фидакарь хезмәте өчен “Татарстанның атказанган укытучысы” дигән югары исемгә лаек булды.

1961 елдан алып ул мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдире, 1965-70 елларда директоры була. 1965-67 елларда хәзерге мәктәпнең төп бинасын, ә 1970-72 елларда аның янкормасын эшләтә. Боларны эшләткәндә күпме бусагалар таптарга, Алабуга, Казан юлларын үтәргә, каршы төшүләр, кире борып чыгарулар аша, ниһаять, җиңүгә туры килә аңа.


Туган базга урта мәктәбемдә миңа тәрбия, белем биргән мәгариф укытучысы кадерле Хәй абыйга, Мәүлидә апага һәм башка укытучы абыйларга, апаларга автордан тирән ихтирам белән һәм истәлек итеп
9 январь 1991 ел

Галимнең яраткан укытучысына язган җылы теләкләре

Бөек Ватан сугышы ветераны Хәй абый Гыйльфанов, лаеклы ялга чыккач та, мәктәптән аерылмый: укытучылар коллективы, балалар аны төрле очрашуларга, бәйрәмнәргә еш чакыралар, сугышчы солдат күргәннәре турында бик теләп сөйли, аның хәтере яхшы, акылы зирәк. Ул барысын да әле кичә генә күргәндәй сөйли, хәтерендә барлый. Хәй абый күп кенә орден-медальләр белән бүләкләнгән, ә “Киевны батырлача саклау өчен” медале аны 1966 елда гына эзләп таба.

Хәй абый Гыйльфанов 1982 елдан лаеклы ялда. Хәерле, бәрәкәтле картлык, сау-сәламәт гомер Сезгә, олуг Укытучы!

Ак хыяллар иясе

1931 ел. Бәзәкә авылының зирәк һәм мөгътәбәр кешесе Госман Бәшәров гаиләсендә сабый дөньяга аваз сала. Күпсанлы, зур Бәшәрнекеләр нәселе тагын бер кешегә арта. Малайга Рәшит дип исем бирәләр.

Рәшит кечкенәдән үк күп белергә омтылучан булып, матур әдәбиятны яратып үсә. Мәктәп елларында яхшы укый, иҗади бәйгеләрдә теләп катнаша, мәктәп уңышлары турында район газетасына мәкаләләр яза.



Рәшит Бәшәров җидееллык мәктәпне бик яхшы билгеләргә генә бетерә, алга таба 4 ел Алабуга педтехникумында укый. Совет Армиясе сафларына алына, Германиядә хезмәт итә. Армиядән кайткач, 1953 елдан Бәзәкә урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта башлый. Шул ук вакытта читтән торып Алабуга дәүләт педагогия институтында укый. Институт дипломында тапшырылган 53 фәннән бер генә өчлесе дә юк аның!

Шул елларда мәктәптә химия фәнен укытучы яшь кыз Фирая Салихова белән гаилә кора.

Педагогик эшчәнлеген башлаган чорда ук Рәшит Бәшәров үзен югары культуралы, тирән белемле, киң эрудицияле, балалар психологиясен тирәнтен белүче укытучы итеп күрсәтә.

...11 нче сыйныф бүлмәсе. Рус әдәбияты дәресе. Яшь егетләр-кызлар ниндидер әсәргә анализ ясыйлар. Алар чыгышларында әсәргә, барча геройларга үзләренең уңай яки тискәре фикерләрен белдерәләр, исбатлыйлар, бәхәсләшеп алалар, укытучыга көтелмәгән сораулар бирәләр. Ә ул, тәрәзә янына басып, тыныч кына тыңлый, аларны бүлдерми, ризалашып баш кага, елмаеп ала. Кыңгырау. “Урок окончен. Благодарю всех, кто выступал. Каждый из вас был

настоящей личностью. Я доволен вами", – ди дә, укытучы класстан чыгып китә. Укучылар көндәлеккә куелган "4" ле яки "5" ле билгесенә генә түгел, ә укытучының үзләрен шәхес дип атаган сүзләрдән шатлык, канәгатьлек хисләре кичерәләр. Чөнки бу – укытучы биргән иң зур бәя!

Рус теле һәм әдәбияты укытучысы Рәшит Бәшәровның үз дәресләрендә югары сыйныф укучыларына куйган таләбе үтә җитди. "Миңа әсәр эчтәлеген, дәреслек материалын сөйләү кирәк түгел. Минем өчен һәркайсыгызның үз сүзе, үз фикере, карашы, мөнәсәбәте булу мөһим. Уйласаң – уйдырып әйт, якласаң – ышандырып якла, исбатла, кире каксаң – дәлиллә, мисаллар белән инандыр, икеләнергә урын калдырма!" Камил, Тимерхан, Рәмзияләрнең гуманитар фәннәр дәресләрендә бәхәскә кереп китүләре, һәрберсенең үз фикеренең дөрес икәнлеген һәрчак исбатларга омтылулары менә кайдан килә икән!

Әйе, укытучы Рәшит Бәшәровның яшьләргә мөстәкыйль фикерләргә, әйткән сүзен һәм кылган гамәлен аклый-яклый белергә, барган юлыннан тайпылмаска, тоткан кыйбласыннан баш тартмаска өйрәтүгә корылган методикасы иде бу. Үз укучыларын белемле, әхлаклы, зыялы кешеләр итеп тәрбияләү өчен мөгаллим бөтен көчен, сәләтен, талантын бирә, күп эшли, туктаусыз эзләнә, фән кандидатлары өчен, үз тәҗрибәсеннән чыгып, теоретик һәм практик материаллар әзерли.

Балаларны укыту-тәрбияләүгә куйган зур шәхси хезмәте өчен Рәшит Бәшәровка 1966 елда "Татарстанның атказанган укытучысы" дигән мактаулы исем бирелә.

...1968 ел, декабрь. Укытучы Рәшит Бәшәров исеменә Мәскәүдән, СССР Педагогия фәннәре академиясеннән Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгына багышланган Бөтенсоюз "Педагогик укулар"га чакыру кәгазе килә. "Педагогик укулар"да татар авылыннан килгән гап-гади укытучы танылган тел галимнәре һәм новатор укытучылар белән берәттән үзенең "Развитие познавательной активности учащихся в процессе обучения русского языка" дигән хезмәте белән уңышлы чыгыш

ясый. Соңрак аның бу чыгышы башка алдынгы тәжрибле укытучылар хезмәтләре белән бергә Татарстанның укытучылар белемен күтәрү институты тарафыннан республика укытучылары өчен ярдәмлек сыйфатында махсус брошюра булып басылып чыга.

Рәшит Бәшәров гажәеп колачлы шәхес иде. Ул талантлы педагог, яхшы директор, оста пропагандист кына түгел, менә дигән оештыручы һәм җәмәгать эшлеклесе дә иде. Үз укытучылары өчен ул авыл, колхоз тормышын, интеллигенция язмышын яктырткан сәхнә әсәре – "Вөждан газабы" дигән 3 пәрдәлек пьеса язды. Хезмәттәшләре аның бу әсәре белән халык алдында уңышлы чыгыш ясадылар, тамашачы хөрмәтен яуладылар.



Бу сыйныфтан киләчәктә булачак академик, шагыйрь, мәгариф алдынгылары чыгачак. Сыйныф җитәкчесе Рәшит абый Бәшәров. 1962 ел

Үзе җитәкләгән V сыйныф укучысы Марсель Гыймазетдиновның кәлам тибрәтүе турында белгәч, укытучы чиксез шатлык һәм куаныч хисләре белән малайга шигырь язу нечкәлекләрен аңлата, алга таба да язуыннан туктамаска өнди, файдалы киңәшләрен бирә. "Мин синнән киләчәктә авылыбызны танытырдай шагыйрь көтәм", – ди ул шәкертенә. Һәм бу шулай була да.

Гомумән, Рәшит абый укучылардагы сәләтне күрә, сизә, үстерә белде. Мәсәлән, безгә ул смотр концертлары өчен композиция-сценарийларны үзебезгә язып карарга

тәкъдим итә иде. Уңышлы чыкканнарын сәхнәдә алып барырга да куша. Шулай “Мы за мир во всём мире” дигән сценарийны мин яздым, ул абыйга ошады һәм аны районда 10 нчы сыйныфтан Мансур Хуҗиәхмәтов белән бик оста алып бардык. Ә укучысы Мәүгыйдә Җиһаншинаның рус җырларын бигрәк тә матур, оста җырлавын яратып, аны “безнең Зыкина” дип атый иде.



Әйе, Рәшит абый үзе җитәкләгән Бәзәкә мәктәбенең алдынгы һәм мактаулы булуы өчен тырышты, укучыларының еллар үткәч, зур кешеләр булып мәктәпнең мактанычы, авылның горурлыгы буласына чын күңелдән ышанды. Планнары зур, өметләре якты, күңеле тулы ак хыяллар иде аның. Әмма бу хыялларга тормышка ашарга насыйп булмады. Җир җимертеп, янып-көеп эшләп йөргән 39 яшьлек ирне, 3 бала атасы, дәртле, энергияле, талантлы, зыялы шәхесне явыз үлем, көтмәгәндә-уйламаганда, 1971 елның 9 февралендә безнең арабыздан мәңгелеккә алып китте.

Ул көннәрдә Бәзәкә мәктәбенә Рәшит Госман улы Бәшәровның исемен бирү турында сүзләр булган иде. Тик алар буш сүз генә булып калдылар, гамәлгә ашмадылар. Кызганыч... Ул моңа бик лаек иде.

Рәшит абый, чор таләпләреннән чыгып, үзен тулысынча педагогик эшчәнлеккә җиккән чын Укытучы булды. Уен-көлкене яратучы, һәрвакыт шат күңелле, рәхәтләнеп гармунда уйнаучы (ул елларда популяр булган «Раушаниям, бәгърем» җырын бик ярата иде. Кызына да шушы исемне бүләк итеп китте), күтәренке рухлы, үз һөнәренә җаны-тәне белән бирелгән чын интеллигент, олы шәхес буларак, ул укучылары, коллегалары, ата-аналар, авыл халкы күңелендә һәм хәтерендә искиткеч тирән ихтирам һәм хөрмәт хисе калдырды.

Мең рәхмәт сезгә, Мөгаллим! Без Сезне беркайчан да онытмыйбыз. Рухыгыз шат, Җаныгыз тыныч булсын.

Гомер юлы якты

Ныклык атлап килә безгә таба,
Укытучы апабыз Гаян.
Җитди холык, горур табигатьне,
Дөреслекне алган ул кайдан?

Яхшы укытучы дигән исеме
"Яхшы апа" белән янәшә.
Газиз әниләре кебек якын итеп
Һәрбер бала аңа эндәшә.

Аны, әнә, балалары сарган,
Мең сорауга җавап көтәләр.
Тормыш дигән олы имтиханны
Бергәләшеп шулай үтәләр...

Сөенече аның – шул балалар
Җирдә кеше булып үссәләр.
Тормыш сынауларын үткән чакта
Сынмый, сыгылмыйча түзсәләр.

Сөенече – шушы балаларның
Җырдай матур булса эшләре,
Җирдә яманлыкны, явызлыкны
Бетерергә китсә көчләре...



Бу шигырь юллары укытучым, сыйныф җитәкчем, хөрмәтле остазым Гаян апа Әюповага багышлана, аның холык-фигылен төгәл ачыклый.

Кешенең бәхетле яки бәхетсез булуы нәрсәләргә бәйле, тормышның матурлыгын ничек күрергә, аны ничек булдырырга, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ничек тоярга? Тормыш дигән зур төшенчә турында ниләр беләбез без? Алда безне нинди юллар, нинди язмышлар көтә?

Сораулар, сораулар... Барысына да кайдан һәм нинди җавап табарга? Җавапны без укытучыбыз, сыйныф җитәкчебез Гаян апа Әюповадан көтәбез. Ә ул беребезне дә җавапсыз калдырмый. Сөйли, аңлата, чагыштыра, мисаллар китерә, ышандыра, күңелләрдә өмет тудыра.

Әюпова Гаян Мулламехәмәт кызы 1922 елда Бәзәкә авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Башка ба-

лалар кебек үк, тормышның әчесен-төчесен күреп үсә. Мәктәптә бик тырышып укый, барлык фәннәрдән дә гел яхшы билгеләр генә ала. 1940 елда урта мәктәпне тәмамлый, беренче чыгарылыш укучысы була. Өлгергәнлек аттестаты белән бергә, барлык фәннәрне дә гел "5"ле билгеләренә генә бетерү сәбәпле, ул теләсә кайсы югары уку йортына имтихансыз керү хокукын ала. Шул ук елны Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә. Тик бер курс бетерүгә, сугыш башлана. Кыз укуын өзәргә мәҗбүр була. 1941 елның көзендә аны Алабуга районының Иске Юраш мәктәбенә укытырга җибәрәләр. 1942 елның җәендә Алабуга педучилищесында өч айлык укытучылар курсларын тәмамлый, аннан, 1943 елның көзендә, Бәзәкә мәктәбенә кайта. Биредә тарих һәм җәмгыять белеме фәннәрен укыта башлый, эшен фидакарьләрчә, намус белән 1976 елга кадәр дәвам итә, озак еллар мәктәптә укыту бүлеге буенча мөдир була. Эшләү белән бер үк вакытта читтән торып Казан педагогия институтының тарих бүлеген тәмамлый.

Гаян апа Әюпова тирән белемле, киң карашлы, зур эрудицияле укытучы иде. Остазыбызның мәгариф эшендәге тырышлыгы, булдыклылыгы һәркемне сокландырырлык булды. Аның үз юлы, методикасы, югары нәтиҗәләргә ирешү алымнары да үзенчәлекле иде. Дәресләре үзенә бертөрле төгәллек, тормыш белән бәйләнешлелек ягыннан һәрчак үрнәк булдылар. Тема авыр, материал зур булса, Гаян апа керә-керешкә үк теманы сөйли башлый иде. Укучыларга беркайчан да кычкырмады, дәрестә тәртипкә чакырмады. Әмма бу аның дәресләрендә кыбырсып яки онытылып утырырга мөмкин булган икән, дигән сүз түгел. Укытучыбыздагы мәһабәт гәүдә, горур кыяфәт, ачык, туры караш, өзеп-өзеп, басым ясап әйткән сүзләр – болар һәммәсе безне шундук тып-тын калырга, җавабыңны уйлап, җыйнак, төгәл итеп сөйләргә мәҗбүр итә иде. Укучыларга ул ныклы белем бирде, төпле белем дә таләп итте. Аны "усал укытучы" дип атадылар. Әйе, усал иде, әмма явыз түгел, туры сүзле, хакыйкать сөюче, ифрат дәрәҗәдә

гадел кеше, үз фәненә бик җаваплы карый торган, укучылары, үз сыйныфы өчен җан атып йөрүче педагог булды. Бу урында искәртеп үтәм: аның классын тәмамлаган 21 укучының җидесе, мәктәп бетергән елны ук, югары уку йортларына кердек. Бу бит ул вакытта акча төртеп керү дигән нәрсәнең төшкә дә кермәгән чагы. Һәрберебез, укытучыларыбыз биргән белемгә таянып, үз көчебез, үз тырышлыгыбыз белән гадел рәвештә кердек, тырышып укыдык.



11 нче сыйныф, җитәкчебез Гаян апа һәм практикантлар. 1965 ел

Яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсендә педагогның шәхси үрнәге – аның ни дәрәҗәдә белемле, зыялы кеше булуы, һөнәри әзерлеге, холкы һәм темпераменты да зур роль уйный. Бу җәһәттән Гаян апа мәктәптә иң тәвәккәл, көчле рухлы, искиткеч зур энергия чыганагына ия, бетмәс-төкәнмәс ихтыяр көче белән башкаларга да уңай тәэсир итүче укытучы иде.

Гаян апа Әюпова гомере буе 9-10 нчы сыйныфларда укытты. Ә бу – ел саен тарих, җәмгыять белеме фәннәреннән Яңа елдан башлап май аена кадәр консультацияләр, билетларга җаваплар язу, кабатлаулар дигән сүз. Ике сменада эшләгән укытучы кичкә кабат мәктәпкә ашыга,

укучыларын имтиханнарга әзерли. Сыйныф җитәкчесе итеп тә аны һәрчак өлкән классларга билгеләделәр. Сыйныф җитәкчесе булу – бу эшкә чын күңелдән бирелеп эшләгән педагогтан ифрат күп вакыт, энергия, нык сәламәтлек таләп итә. Яшьләрнең рухи һәм әхлакый сыйфатларын баету, безне шәхес итеп үстерү өчен Гаян апа вакытын да, көчен, белемен, осталыгын да кызганмады. Ул безнең тормышыбызда онытылмаслык эз калдырган кеше. Авыл халкы арасында да Гаян апа Әюпова зур хөрмәткә ия иде. Җәмәгать эшләрендә актив катнашты, күп мәртәбәләр авыл Советы депутаты булып сайланды. Хезмәт юлы туры, гомер юлы якты иде аның. Тормыш иптәше Арыслангали абый белән биш бала үстерделәр. Ире вафатыннан соң да, балаларын укытты, тәрбияләде, кеше итте. Өч баласы мәктәпне медальгә бетерде, бишесе дә югары белем алдылар.



Мәктәптә белем бирүче, тормышта яшьләргә үз юлларын табарга булышучы, үзенең яшәү тәҗрибәсе белән шәхес тәрбияләүдә тирән эз калдырган олуг зат иде Гаян апа Әюпова. Югары әхлаклы, зур абруйлы, олы тәҗрибәле, тирән белемле, һәрчак оптимист рухлы булган, бик күп асыл сыйфатларны үзенә туплаган якты күңелле укытучым образы мине еллар аша озата килде, якты маяк кебек бары алга дәште. Мин аңа чиксез рәхмәтле, хөрмәтле.

1991 елның ноябрь аенда Укытучыбыз безнең арабыздан мәңгелеккә күчте. Туфрагыгыз ак мамык булсын, Апа, Остаз, кадерле Укытучы.

Фидакарь шәхес

Үз һөнәрен, туган ягын, туган авылын яраткан кеше генә тормышта якты эз калдыра.

Әлеге юллар Бәзәкә мәктәбендә немец теле укыткан хөрмәтле укытучыбыз Фәйзелхак абый Хөснетдинов турында.

Фәйзелхак Хөснетдинов 1916 елда Бәзәкәдә ишле балалы гаиләдә туа. Әтисе Гыйльфан абыйның кайчандыр мәчеттә балалар укытуы бу гаиләгә бетмәс-төкәнмәс кайгы-хәсрәтләр китерә. 1929 елның шомлы бер көнендә, барлык мал-мөлкәтен тартып алып, йорт хуҗасын алып чыгып китәләр. Гыйльфан ага суга төшкәндәй юкка чыга. Ата-анасыз калган дүрт бала (әниләре элегрәк үлгән була) карт әбиләре карамагында кала. Әтисез калган гаиләне өйләреннән куып чыгаралар. Алар унбер ел кеше мунчаларында яшәргә мәҗбүр булалар. Өстәвенә, "Мулла, мәзин баласы" дигән кара тамга, кая гына барсалар да, артларыннан ияреп йөри. Андыйларга совет мәктәбендә урын юк, янәсе.



Җидееллык мәктәпне Фәйзелхак районда оештырылган бердәнбер колхозчы яшьләр мәктәбендә, Камай авылында төгәлли. Аңа ул вакытта 18 яшь була. Аннан соң Алабуга китапханәчеләр техникумында белем ала, Казан педагогия институтында укый. Армия сафларына алыну сәбәпле, укуын төгәлләргә өлгерми кала.

Яшь солдат Бөек Ватан сугышының утлы-канлы мәхшәрен беренче көннән үк үз җилкәсендә татый. Сугыш хәлләре турында искә төшергәндә, ул һәрчак, тирән көрсенеп, болай дип искә ала иде.

– Сугышта иң аянычы – шәһәрләрне, авылларны дошманга калдырып чигенү, үз халкыңа ярдәм итә алмау чарасызлыгы, якын дусларны югалту әрнүләре...

Әмма Фәйзелхак абый Җиңү көненең киләчәгенә бөтен күңеле белән ышана. Шул ышаныч аңа меңнәрчә чакрымнарны үтәргә, яраланып, әсир төшкәннән соң, концлагерьларда күргән түзә алмаслык михнәтләрне җиңәргә ярдәм итә.

Туган авылына 1946 елның июнендә генә әйләнеп кайта. Озак еллар дәвамында аңа, тоткынлыктан исән котылган кеше буларак, сәяси эзәрлекләүләрне, НКВД тикшеренүләрен күп татырга туры килә.

Әмма ничек авыр булмасын, Фәйзелхак Хөснетдинов барысына да түзә, киләчәк гомерен балалар тәрбияләүгә багышлый, шушы юлдан беркайчан да тайпылмый.

1946 елның 1 сентябреннән ул Абалач мәктәбендә укыта башлый. Биредә Татар Тәкәше кызы укытучы Зәйтүнә Галиева белән гомер кора, тормыш йөген икәүләп тарталар.

Фәйзелхак абыйның “Совет мәктәбе” журналында басылып чыккан “Сәлам сиңа, Абалач” дигән шигыре яшьлек елларында шушы авылда укыткан кадерле вакытларын сагынып язылган.

Алга таба Фәйзелхак Хөснетдинов, туган авылына кайтып, озак еллар дәвамында Бәзәкә урта мәктәбендә укыта. Бер үк вакытта, читтән торып, Мәскәүдә чит телләр өйрәнү буенча ике еллык курсларны тәмамлый.



Фәйзелхак Хөснетдинов 10 нчы сыйныф белән. 1959 ел



Мәктәптә балалар укыткан еллар мөгаллим өчен иң кадерле мирас булып, хәтерендә гомер буе сакланалар.

Фәйзелхак абый Хөснетдинов бөтен барлыгын мәгарифкә багышлаган, үтә кешелекле, гаҗәеп ягымлы, изге күңелле иде. Дәресләрен искиткеч мавыктыргыч, гади, аңлаешлы итеп уздыра, уртача өлгерүче балаларны да сөендереп-үсендереп җибәрә белә иде. Җылы сүзле, игътибарлы, эзләнүчән укытучы белеме, сабырлыгы аша балаларга немец теле фәнен яраттыра алды. Без – аның укучылары, моңа бөтенебез дә шаһит. Әле дә хәтеремдә, укытучыбыз Гёте шигырьләрен татарчага үзе тәрҗемә итә иде. Урта мәктәптә немец телен төпле үзләштерү безгә югары уку йортларына имтихан биргәндә дә, уку дәверендә дә нык ярдәм итте. Фәйзелхак абыйның элекке укучысы Мөнирә Бәхтегәрәева-Нәҗметдинова хәзер фәннәр кандидаты, башта Алабуга, хәзер Чаллы педагогия институтында немец теле укыта.

Укытучыбыз мәктәптә интернациональ дуслык клубы оештырган иде. Мин Чиләбе каласында укыганда ук бер немец кызы белән хат алыша башлаган идем. Хат алышуны Бәзәкәдә дә дәвам иттем. Хатта аңлашылмаган сүзләр булса, яки үзем язган җөмләм дөрес үк түгел кебек тоелса, мин күршебез Фәйзелхак абый янына йөгереп керә идем. Ул миңа һәрчак ярдәм итте, биш ел дәвамында Регина Вайсброда белән хат алышуымда миңа ныклы терәк булды.

Фәйзелхак Хөснетдинов һәрчак хөр күңелле, көчле рухлы, тормышка гашыйк кеше булды. Язмыш биреп торган сынаулар алдында сынмады, сыгылмады, авырлыкларга бирешмәде. Үлемне күп мәртәбәләр күргән солдат булараk, ул яшәүнең тәмен-ямен белде, тормышка гашыйк иде. Кешеләрне яратты, олы белән олы, кече белән кече була белде.

Фәйзелхак абый бик тә юмарт һәм киң күңелле кеше иде. Шуны дәлилләүче бер мисал белән танышып китегез.

Моннан бер унбиш-егерме ел элек, салкын декабрь аенда, авылыбызга бер төркем чегәннәр килеп төште. Алар урамнарда әрле-бирле йөриделәр, кешеләрне туктатып, багарга тәкъдим иттеләр, сорандылар, теләнделәр.

Ишеткән-белгән авылдашлар, чегәннәрдән куркып, капкаларын бикләп куйдылар, бала-чагаларын барлап алдылар. Ә менә Фәйзелхак абый, киресенчә, үзләренә килеп кергән чегәннәрне, берни булмагандай, төн кунып чыгарга чакыра. Зәйтүнә апаның ай-ваена карамыйча (әле тиз генә чәй әзерләргә, кичкә бәлеш пешерергә куша), 6-7 кешедән торган бер гаиләне каршы ала, атларын туарыша, печән алырга рөхсәт бирә. Барлык күрше-тирә, туган-тумача шакката. Ә мәрхәмәтле укытучыбыз бу гамәлен бик гади аңлата: "Мин армиядә вакытта Бессарабиядә хезмәт иттем. Молдаван-чегәннәрнең тормыш-көнкүрешләре, холык-фигыльләре миңа таныш. Форсаттан файдаланып, шул көннәрне хәтердә яңартасым, үзләре белән сөйләшеп, ул яклардагы үзгәрешләр турында беләсем килде".

Фәйзелхак абыйның ул вакыттагы мондый адымын күпләр сәерсенеп акылсызлык, җүләрлек дип кабул иттеләр. Ә аксакал мөгаллим өчен бу – табигый хәл: аның кешеләргә карата кылган чираттагы яхшылыгы һәм мәрхәмәтлелеге генә иде. Ул аның канына, җанына салынган.

Ветеран мөгаллим җәмәгать эшләрендә дә зур активлык күрсәтте. Бик озак мәктәпнең профсоюз оешмасын җитәкләде, авыл сәхнәсендә үзешчән артист, агитколлектив җитәкчесе – саный китсәң бик күп иде аның вазыйфалары. Орден, медальләр дә, Мактау грамоталары да аз түгел. "Мәгариф алдынгысы" дигән мактаулы исемгә дә лаек иде ул. Тик кемнәрнеңдер игътибарсызлыгы аркасында аңа бу исемнең бирелмәве һәрчак күңелләребезне борчып торды.

Яшереп торасы юк, гаделсезлекләр күп булды. Шәһәрдән Бәзәкә мәктәбенә килеп яңалык һәм яктылык сулышы өргән Оркыя апа Вәлиәхмәтова, үз фәненең чын белгече булган Гаян апа Әюпова, татар теле укытуның остасы Мәсгудә апа Мөхәммәтдиновалар бу исемгә лаек түгелләр идемени?

Бу игътибарсызлык өчен, дистә еллар үткәч булса да, кадерле мөгаллимнәребездән, балаларыннан гафу үтенәсе килә.



1977 елда пенсиягә киткәннән соң да, ул тыныч, җай гына яшәү рәвешен түгел, ә киресенчә, тынгысыз, тулы тормыш белән яшәүне сайлады. Мәктәптә укучылар алдында чыгышлар ясый, әле ветераннар, әле авыл халкы арасында булды. Табигатьне яратучы зат, көннәр буе алма бакчасында мәш килде, кортлары белән "сөйләште". Һәвәскәр бакчачы да иде әле ул: җиләк-җимеш агачларының серләрен белде, әллә ничә сорт алма-гачлар үстерде. Ә көзләрен балын, алмаларын күршеләргә мул өләшә иде.

Хисле-моңлы җан буларак, шигърият өлкәсендә дә укытучыбыз безгә матур-матур шигъри тәлгәшләрен бүләк итте. Аның күркәм шигырьләрен туплап, укучысы – АДПУ доценты Сәлахетдин Тажиев, остазына чиксез рәхмәт хисләре белдереп, "Ядкарь булып яшьләргә" исемле китап итеп чыгарды.

Үзенең бер шигырендә Фәйзелхак абый түбәндәге юлларны язган иде:

Бакчачы да бакчасына кереп,
Җимешләрен күреп соклана.
Укытучы исә шәкертенең
Кеше булуына шатлана.

Әйе, чын падагог, үз һөнәренең остасы Фәйзелхак абый шәкертләре бүген зур-зур кешеләр булдылар, төрле өлкәләрдә намуслы хезмәт куялар. Аларның уңышларына, дан-шөһрәтләренә мөгаллим абыйлары Фәйзелхак Хөснетдинов гомере буе шатланып, горурланып яшәде.

Фәйзелхак абый 2005 елның 23 декабрендә вафат булды. Рухыгыз шат, урыныгыз оҗмахта булсын, кадерле Укытучы.

Аккоштай сылу Зат



Күбәләктәй очып-очып, сәхнәдә ак күлмәкле бер кыз бии. Аның җитез хәрәкәтләрен, аяклары белән тыпырдап алуларын, бөтерелә-бөтерелә әйләнүләрен күреп-күзәтеп бетереп булмый кебек. Ә ул, үзенең тиешле хәрәкәтләрен төгәлләп, тыйнак кына баш ия дә, сәхнә артына кереп югала.

Клуб тулы тамашачыны оста биюе белән әсир итүче кем ул? Халык кемгә шулай гөрләтеп кул чаба?

Бу – Мансура Әхмәтова, Бәзәкә мәктәбенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы.

Мансура Габдулла кызы Әхмәтова 1935 елда Бәзәкә авылында крестьян гаиләсендә туа. Мансурага алты яшь булганда, сугыш чыга. Әтисе Габдулла сугышның беренче көненнән үк фронтка китә һәм шул китүеннән кире әйләнеп кайтмый, хәбәрсез югала. Мансура белән энесе Мансур әниләре Рәхимә һәм динне-көнне белүче әби-бабай кулында үтә тыйнак, итәгатьле һәм миһербанлы балалар булып үсәләр.

Мәктәпне яхшы билгеләренә генә бетереп, Мансура Алабуга пединститутында укый, белгечлеге буенча рус теле һәм әдәбияты укытучысы булырга хыяллана. Институтны тәмамлагач, Бөрешле, Песәй мәктәпләрендә эшли. 1957 елдан Бәзәкә мәктәбендә укыта башлый һәм үзен бик тырыш, яңага омтылучы, инсафлы зат итеп таныта.

Мансура Әхмәтова һәр үткәргән дәресен укучыларның танып-белү активлыгын камилләштерүгә, рус телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә, укучыларында белемне мөстәкыйль туплау ихтыяҗы булдыруга юнәлтә.

Татар балалары рус телендә дөрес һәм иркен сөйләшә алсыннар өчен, мөгаллимә программаларның барлык темалары буенча карточкалар, дидактик материаллар әзерли, диафильмнар туплый. Сүзлек белән эшләргә өйрәтүгә зур игътибар бирә, балаларны өстәмә әдәбият укуга аеруча нык җәлеп итә, ачык дәресләр бирә.

Укыту белән беррәттән, Мансура Әхмәтова рус теле укытучыларының методик куст берләшмәсен җитәкли, күпсанлы доклад, лекцияләр укый. Авылда гына түгел, район күләмендә коллегалары арасында олы ихтирамга лаек була. Аның эш тәжрибәсе күпләргә үрнәк булып тора.

Җәмәгать эшеннән дә читтә калмый ул: концерт, спектакльләрдә актив катнаша, тамашачы күңелен яулап, өздереп бии.



Сыйныф җитәкчесе буларак та мөгаллимәнең тәрбиягә авыр бирелүче яшүсмерләр белән якыннан торып аңлашуы, баланың рухи үсешен тәэмин итәрдәй дөрес юнәлеш бирү юллары, аларның ата-аналары белән тыгыз элемтәдә булып, шәхси эшләү алымнары яхшы нәтиҗәләргә китерә. Гаиләләрендә үтә киеренке мөнәсәбәтләр булган Сәгинур, Шамил исемле кыз һәм малайларны Мансура зур көч, түземлелек һәм үҗәтлек белән мәктәпкә китертүгә ирешә, алга таба аларның язмышларын уңай якка үзгәртә. Бу турыда 60 нчы еллар азагында "Азат хатын" журналында журналист Д.Зөбәерова "Озын чәчле мөгаллимә" дигән мәкалә дә язып чыккан иде.

Тырыш, эзләнүчән, кызыклы һәм нәтиҗәле эш алымнарын табарга омтылучы Мансура Әхмәтова, гади укытучы гына булу кысаларыннан чыгып, гыйльми эш белән шөгыльләнергә ният кыла. 1968 елда Мәскәүгә китеп,

РСФСР Мәгариф министрлыгының милли мәктәпләр буенча фәнни-тикшеренү институтында эшли башлый. Ул елларда үзенең эш тәҗрибәсен чагылдырган татар балаларын рус теленә өйрәтү методикасына кагылышлы байтак мәкаләләре “Совет мәктәбе” (хәзерге “Мәгариф”) журналында басылып чыга.

Булачак фән эшлеклесе М.Әхмәтова Мәскәүдә эзләнү-тикшеренүләр дөньясына чума. Ул телгә багышланган төрле рефератлар, докладлар яза, аларны уку өчен Ленинград, Грозный, Ташкент, Казан, Уфа калаларында конференцияләрдә, педагогик укуларда катнаша. Аның гыйльми эше “Развитие речи учащихся как основа обучения русской орфографии в татарской школе” дип атала. Фәнни җитәкчесе – педагогия фәннәре докторы, профессор Л.З.Бакеева, рәсми оппонентлары профессор А.В.Дудников һәм педагогия фәннәре кандидаты Р.Б.Сабаткоев булалар.

Шулай итеп, алга куелган максатларга ирешү юлыннан уңышлы барган бер мәлдә, Мансура Әхмәтова алдына авыр чир мәкерле киртә куя һәм, озак тә үтми, аны безнең арабыздан алып та китә.

Мансура апа! Озын кара толымнарыгыз, зифа буйсыныгыз, күбәләктәй җиңел йөрешегез белән табигатьнең иң гүзәл кошы – аккош кебек, ак һәм пакь зат булып, укучыларыгыз һәм авылдашларыгыз хәтерендә мәңге сакланасыз.


Урыныгыз җәннәт түрләрендә булсын, озын чәчле кадерле Мөгаллимә!

Гомер язлары ел да кабатлана...

Ел саен табигатькә әйләнеп килгән язлар – Фоат Көләчевның гомер язлары да. Чөнки (1927 ел) яз аенда туган көне аның. Җиргә килгән һәр яз белән үзенең гомер хисабын алып бара ул. Әле генә 18 иде, аннан 50, инде менә 83 нче яз да килеп җиткән. Әй, бу гомер агышлары... Туктатып та, кире борып та булмый икән үзләрен...

Балачак авырлыклар, юклык, кыенлыклар белән сизелми дә үтеп китә, инде мәктәпкә барырга да вакыт килеп җиткән. Авылда колхоз төзүгә зур тырышлык куйган әтисе балаларын белемле итүгә бөтен көчен бирә. Шунлыктан аның гаиләсе авылда хөрмәтле, абруйлы була.

Тиздән авыр һәм фажигале сугыш башлана. 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, Фоатның укуы өзелә. 17 яшьлек егет илне сакларга, армия сафларына алына. Авыр сугыш шартларында озак хезмәт итәргә туры килми, ике елдан соң, авыру сәбәпле, демобилизацияләнә.



Авылда эшче көчләр җитми. Әтисе Гатаулла абзый 1935 елдан алып картайганчы колхоз тимерчелегендә эшли. Фоат та берара әтисе янында эшләп ала. Аннан соң, аның киңәше белән, укуын дәвам итәргә була. Бондюгтагы 2 нче номерлы мәктәпнең унынчы сыйныфына укырга керә. Аны уңышлы гына тәмамлап, алга таба Алабуга укытучылар институтында укый. Аны 1950 елда тәмамлаганнан соң, Бәзәкә мәктәбенә физика-математика укытучысы итеп билгеләнә. Шул көннән башлап, 40 ел армый-талмый яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә бөтен көчен, сәләтен, энергиясен биреп эшли. 1956 елда, читтән торып, Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый, бөтен гомерен балаларга физика фәнен укытуга багышлый.

Фоат абый Көләчев – үз эшенең чын остасы була. Бәзәкә мәктәбендә генә түгел, бәлки район һәм күрше авыл мәктәпләре укытучылары арасында да мактаулы, хөрмәтле булып, абруй казана. Секция һәм куст берләшмәсе утырышларында коллегалары арасында бай тәҗрибәсе белән бик теләп уртаклаша. Класс җитәкчесе буларак та (ә аңа һәрчак күрше авыллардан килгән, бигрәк тә малайлар күп булган классны җитәкләүне тапшыралар), ул укучыларның киңәшчесе, аларга дөрес юл сайларга чын йөрәктән ярдәм итүче, балаларны иҗади рухландыручы, хәлгә керә белүче, сабыр холыклы укытучы була. Педагог Көләчев үз укучыларын яратып кына калмый, аларны шәхес итеп күрә, хөрмәт итә. “Үз гомеремдә бер генә мәртәбә дә укучылар алдында утырып дәрес бирмәдем һәм таләп иткән нәрсәне башта бу укучыга уңайлымы, ул моны башкара алырмы, дип таләбемне кат-кат тикшереп, үз-үземә сорау бирә идем”, дип үз тәҗрибәсе белән уртаклашып сөйли иде ул яшь педагогларга. Фоат абыйның яраткан бер фразасы бар иде. “Укытучыга дәрес үткәрү өчен ике генә әйбер кирәк: кара такта һәм акбур”. Чынлап та, укытучыбыз нәкъ шулар белән дәресләрендә могҗизалар тудыра иде.

Фоат Көләчев – үз фәнен чын күңелдән ярата, нык белә, аны су кебек эчә. Шунлыктан фәне буенча күп еллар дәвамында 100% өлгерешкә ирешә. Һәр уку елында дәрәҗәле укытучының сыйфат күрсәткече – 58-60% була. Аның нәтиҗәле хезмәтен югары органнар да күреп алалар. Ул тырыш хезмәте өчен обком, Мәгариф министрлыгы, роно һәм горком тарафыннан күп тапкырлар Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә.

65 нче елда, мәктәптә беренчеләрдән булып, фидакарь хезмәте өчен “Халык мәгарифе отличнигы” дигән мактаулы исемгә лаек була. Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары вазыйфаларын башкара. Вакыт тыгызлыгына карамыйча, ул озак еллар дәвамында, дәрестән тыш оештырылган фото, радио һәм техник түгәрәкләрне җитәкли. Балаларның техник иҗаты буенча республика күләмендә оештырылган конкурсларда катнашып, күпме

призлы урыннар яулый аның шәкертләре! Санап бетергесез... Мәктәптә аның тырышлыгы нәтиҗәсендә техник средстволардан файдалану яхшы оештырыла. Ныклы игътибарлылык, даими күзәтүчәнлек нәтиҗәсендә алар һәрчак имин, төзек хәлдә сакланалар.



Фоат абый чираттагы чыгарылыш сыйныфы белән. 1980 ел

Фоат Гатаулла улы авылда җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Дистә еллар пропагандист булып эшли, занятиеләрне тыңлаучыларны җәлеп итәрлек итеп оештыра.

Бер булганнан бар да була, диләр. Фоат абый да нәкъ шундыйлардан. Әллә ниләр майтара ул. Кемдер аннан телефонын төзәтүен сорый, кемдер борынгы сәгатен, телевизорын, электр самоварын. Үтенеч белән килгән беркемне дә кире бормый, аларга ярдәм кулын суза. Халык аңа рәхмәтен җиткерә. Әйе, эшеңне яратып эшләү – үзе зур бәхет.

Алда булса зур теләк
Эштән дәрт таба йөрәк.

Бу мәгънәле сүзләр Фоат абый турында.

Фоат абый Көләчев 1987 елдан пенсиядә.

Фоат абыйның пенсиягә китүе дә кызыклы булды. Ул пенсиягә чыкканнан соң да берничә ел эшләп йөрде әле.

Шулай беркөн абый укытучылар бүлмәсенә, кәефе кырылган димме, әллә ничегрәк килеп керде. Үзе берөзлексез кабатлый: “Менә малай, менәтерә агай” (абыйның яратып әйтә торган сүзләре).

– Абый, ни булды соң? – дибез.

Менә нәрсә булган икән.

– Залда расписание карап торам шулай. Менә бер кечкенә генә малай, беренче сыйныфтандыр инде, тыштан атылып керде дә стенадагы сәгатькә карагандай итенде (сәгать исәпли белә микән әле үзе), аннары миңа карап шар ярды: “Бабай, әле дәрескә керергә звонок булдымы?” Әллә нишләп киттем, җәмәгать. Менәтерә, мин әйтәм, әйтте бу. Бала сине бабай итеп күрә икән, значит, сиңа алга таба да әле укытам, әле эшлим, дип йөрергә “ничу” дигән сүз бит инде бу. “Мин китсәм, дөнья бетә” дигән тиле фикер белән үз-үзен юатып, эшеннән китә алмый йөрүчеләр бар-барын, әмма мин түгел. Үз кадереңне үзең белергә кирәк. Китәм, җәмәгать.

Әйтте – китте абыебыз. Уку елын гына төгәлләде дә, мәктәпкә кабат килмәде ул. Фоат абый безгә үз мисалында һәр нәрсәнең үз вакытында гына кызык һәм кирәк икәнлеген төшендереп китте.

Тормыш иптәше Мәүлия апа Таҗетдинова белән гаилә корып, озак еллар бергә укыттылар, гаилә учагын сүндермичә, өч бала тәрбияләп үстерделәр.

P.S. Ни кызганыч, китабым дөнья күрер алдыннан гына укытучыбыз бакыйлыкка күчте. Урынығыз оҗмахта булсын, кадерле укытучыбыз Фоат абый!

Балаларга багышланган гомер

1954 ел, август. Бәзәкә мәктәбе. Яшь кенә бер кыз директор кабинетының ишеген кага.

– Исәнмесез. Мин Казаннан идем. Менә, сезнең районга, сезнең мәктәпкә эшкә җибәрделәр. Үзем Чистайныкы. Сезнең якларны ишеткәнем дә, белгәнем дә юк иде. Зинһар, абый, шушы юлламага “Безгә химик кирәкми”,



– дип язып кына җибәрегез әле, үз ягыма кайтыр идем.

– Ә-ә-ә, син химик мени әле? Сеңелкәем, безгә нәкъ менә син кирәк тә инде. Әйдә, әйдә, рәхим ит безнең мәктәпкә. Без менә нәкъ сине көттек, кая ул җибәрү.

Директор кызны, авыз ачарга да ирек бирмичә, бишкуллап эшкә ала. Ә кыз һаман үзенекен уйлый: "Ярар, җибәрмәсәгез, бер ел ничек тә түзәрмен дә, барыбер үз ягыма китәчәкмен".

Әмма яшь белгеч Фирая Салиховага Бәзәкә мәктәбендә укытучы булып кына түгел, ә авылында ук гомерлеккә килен булып калырга язган булып чыга.

Салихова Фирая Хажи кызы 1932 елда Мөслим районының Әмәкәй авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Соңрак гаиләләре Чистай районына күчеп килә һәм кыз шушы районның Мөслим мәктәбендә урта белем ала. Беренче укытучысы Зөһрә апаны әле дә онытмый, чиксез хөрмәт белән искә төшерә.

1950-54 елларда Казан дәүләт педагогия институтының табигать фәннәре һәм география бүлеген тәмамлый.

... Әй, бу вакыт дигәннәре, бигрәкләр дә тиз үтә икән. Бәзәкәгә килеп укыта башлавына һәм яшәп калуына да 55 елдан артык гомер үтеп тә киткән.

Әле кайчан гына, укучылар каршына кереп, ул беренче дәресен биргән иде. "Балалар мине тыңларлар микән? Тәҗрибәләрем барып чыкса гына ярар иде", – дип борчылган иде. Тыңлыйлар аны, беренче дәресеннән үк яраталар укучылары Фирая апаларын. Тәҗрибәләре дә уңышлы чыга. 40 ел мәктәптә укыту дәверендә күпме мәртәбәләр үткәрергә туры килә аңа ул тәҗрибәләрне. Ә күпме дәресләр бирелгән, контроль һәм практик эшләр эшләнелгән, консультацияләр, олимпиадалар үткәрелгән? Гомумән, саны бармы аларның? Юк, билгеле... 40 ел гомер бала-

ларга белем, тәрбия бирүгә багышланган – бары шул!

Әйе, химия фәне җиңелләрдән түгел. Аны укытуның эчтәлеген билгеләгәндә, Фирая Салихова укучыларны химия белән таныштыру һәм химик биремнәрне үзләштерү өчен иң элек кирәкле фәнни төшенчәләрнең минимумын бирә, көндәлек тормышта кулланыла һәм укучыга яхшы таныш булган яки һәр кеше өчен мәҗбүри белү кирәк булган матдәләрне һәр дәрестә диярлек оста файдалана. Шулай итеп, укучыларына үз фәнен яраттыра ала.



Мөгәллимә үзенең 10 В сыйныфы белән. 1975 ел

Һәр хезмәт мул уңыш биргәндә генә кадерле. Бу җәһәттән укытучы Фирая Салихованың күңеле тыныч. Ул чәчкән белем орлыклары уңдырышлы туфракта мул уңыш бирделәр. Химия фәнен яратып һәм җиңел үзләштергән шәкертләре югары уку йортларында да йөзгә кызыллык китермиләр. Сайлаган һөнәрләре буенча диплом алып, намуслы хезмәт куйдылар һәм танылган шәхесләр булдылар. Тажиев Рифкат, Галәлетдинов Насих, Мөхәммәтҗанова Сабира, Зиннәтуллин Тимерхан, абыйлы-сеңелле Мансур һәм Миннур Сәлимуллиннар, Нәҗметдинов Сәетнур, Закиров Фәйзелхан, Сабиржанов Әзәл, Ямалутдинова Эльмира (Төркиядә табиблык итә) һәм башкалар – табиблар, Нәбиуллин Мансур, Бәшәров Фә-



рит – КАИны, Мөхәммәтҗанов Равил, Гимашев Мирзаһит – Уфа нефть институтын, Гыймадиев Мөнәвир, Насыйфуллин Камил, Нәҗметдинова Зәмфирә, бертуган Кәлимуллиннар һәм башкалар – КХТИны бетереп, галим, инженер, технологлар булдылар. Ә 1968 елгы чыгарылыш укучысы Садыйков Раяф (Татар Сарсазы егете) "Татарстанның атказанган химигы" дигән югары исемгә лаек булды. Горурланыгыз, Мөгаллимә, болар сезнең уңышлар!

Мин дә Фирая апада химия фәнен укыган идем. Әмма химия белән минем ничектер "борчак пешмәде" һәм бу фән буенча көтелмәгән бик кызыклы (бәлки кызганыч та) бер хәл килеп чыккан иде. Шуны бәян итим әле.

...Химиядән дәүләт имтиханы бирәбез. Бу көнне Песәйдә – Сабантуй. Класс егетләре белән килешеп куйдык: нәрсәне белмибез, алар безгә булыша, ташлап чыгып китмиләр (бу фәннне алар яхшы беләләр). Миңа Шакиров Рафаэз (инде мәрхүм, урыны җәннәттә булсын) булышырга тиеш. Менә билетлар алдык, әзерләнәбез. Теоретик материалны беләм кебек, искә төшерәм, язгалыйм. Рафаэз бу фәнне яхшы белә (гомумән, ул бик яхшы укый иде), инде ике соравын да тиз-тиз генә сөйләп тә бирде. Мәсьәләсен эшләргә дип, аны кабат утырттылар, тик бу юлы икенче урынга, миннән бөтенләй читкә.

Менә мине сөйләргә чакырдылар. Үземчә сөйләдем, 1-2 сорау да бирделәр, "ярар, хәзер өченче соравыңа әзерлән", дип, кабат утырырга куштылар. Мәсьәлә эшләргә утырдым утыруын, тик һич кенә дә эшли алмыйм. Рафаэз да миңа карап-карап ала, тик мәсьәлә язылган кәгазьне аңа берничек тә җибәреп булмый: ерак та, комиссиядәгеләр дә гел карап торалар. Аны инде ике тапкыр сөйләргә чакырдылар, ә ул, әле әзер түгел, дип чыкмый да торды, тик өченче мәртәбәсендә инде чыгарга мәҗбүр булды. Ул тагын тиз генә мәсьәләсен аңлатып бирде, "5"ле диеп, аңа класстан чыгарга куштылар. Ул нишлим соң, дигән кыяфәт белән, миңа карый-карый чыгып китте. Бетте, соңгы өмет өзелде... Мин, күзләремне тутырып, аңа карап калдым.

Инде алга таба бик тырышып мәсьәлә чишкән кыяфәт чыгарып утыруның мәгънәсе юк иде. Мин комиссия өстә-

ленең бер башында басып торган Фирая апа янына чыктым да кәгазьне аңа суздым. Ә анда бары бер җөмлә язылган: “Фирая апа, үтерсәгез дә мәсьәләне эшли алмыйм”.

Язуны укыгач, Фирая апа башта җәя кылы кебек өскә таба тартылды, аннары тиз генә комиссия ягына карап алды, аннары күзләрен кулындагы язуга төшереп: – Әйе, әйе... Ә менә монда хата, монда ялгышкансың, Эһе... эһе, – дия-дия, “мәсьәләне” тикшерде дә, “Өчлелек булган, бар чык”, – дип, ишеккә күрсәтте. Мин тизрәк бүлмәдән чыгып китү ягын карадым. Шул ук минутта артымнан Фирая апа атылып чыкты “Син, кызыкай, нәрсәләр уйлап чыгардың тагын? Башны бетерә яздың бит. Бу бит – гос-эк-за-мен! Ярый әле күрмәделәр, сизмәделәр бугай. Бар, югал тизрәк моннан”.

Миңа шул гына кирәк иде – очтым. Өйгә түгел лә, Сабантуйга...

Өлгергәнлек аттестатымда бердәнбер “өчле”м – шушы мин бик “яхшы” белгән химиядән булды. Хәер, ул химия дигәннәрен яхшы белү тормышымда әллә ни кирәк тә булмады кебек. H_2O (су) белән NaCl (тоз) ны болай да беләбез, көн саен кулланабыз ич үзләрен.

Тирән белемле, бай тәжрибәле, педагогик-психологик яктан нык әзерлекле, шулай ук яңалыкларга омтылучы һәм алдынгы тәжрибәне үз фәне буенча оста куллана белүче Фирая Салихова мәгариф өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен Министрлыкның Мактау кәгазе һәм 1987 елда “Халык мәгарифе отличнигы” дигән мактаулы исемгә лаек була. Чын педагогларга хас булган гадилек, тыйнаклык һәм әхлаклылык кебек шәхси сыйфатларга ия булган Укытучы Фирая Салихова укучылары һәм халык алдында зур хөрмәткә лаек зат. Зур рәхмәт сезгә, Мөгаллимә апа! Ныклы сәламәтлек, бәхетле озын гомер телим Сезгә!



Иҗади эшләүче педагог

“Син кулыңа китап алдың. Анда ниләр язылганын, ниләр барын белмисең әле син.

Беренче битен укыдың, икенчесен, унынчысын, йөзенчесен. Син үзеңне башка, таныш түгел мохиттә сизә башладың.



Күп нәрсәләрне белеп тә җиткермәвең ачыкланды. Күп нәрсәләрне белдең. Шатланып көлдең, моңландың, уйландың. Нәфрәтләнергә һәм сокланырга өйрәндең...

Син кулыңа китап алдың. Сиздеңме, аның тышлыгын ачканда син гүзәл бер дөньяның ишеген ачтың!”

Бәзәкә урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мәсгудә Мөхәмәтдинова һәр ел саен башлангычтан урта сыйныфларга килгән балаларны шулай әдип Г.Бәширов сүзләре белән ана теле һәм әдәбияты дөньясына алып керә, әсәргә кызыксыну, уку теләге уята. Ә шул вакытта сабыйлар йөзендәге самимилек, гаҗәпләнү, кызыксыну, өмет тулы карашларны тою, күрү – үзе бер гүзәл мизгел!

Мәсгудә Мөхәмәтдин кызы Мөхәмәтдинова 1926 елда Бондюг районының Камай авылында туа. Тиздән гаиләләре белән шушы ук районның Тукай авылына күченәләр. Башлангыч белемнең 1-2 нче сыйныфын – Тукайда, 3-4 сыйныфларны – Сарсазда, 5-7не – Песәй мәктәбендә ала. 8-9 нчы сыйныфларны сугыш елларында Бәзәкә мәктәбендә бетерә. 10 нчы сыйныфны Алабуга укытучылар институты каршында оештырылган әзерлек курсларында төгәлли. Бик яхшы укыганлыгы нәтиҗәсендә, Мәсгудәне укытучылар институтының татар теле бүлегенә имти-

хансыз кабул итәләр. Биредә укуын 1948 елны төгәлли, кулына диплом ала. Яшь белгеч Балтач районына эшкә билгеләнә. Бу районда өч ел укытканнан соң, ул үз районына әйләнеп кайта һәм Бигәш авылы мәктәбендә бер ел рус теле һәм әдәбияты укыта. Шул ук елны укытучыларның август киңәшмәсендә роно мөдире районның ике яшь белгечен белемле, оста педагоглар, дип аерым мактап китә. Болар – Бигәш мәктәбендә эшләүче Камил Гыйльмуллин һәм Мәсгудә Мөхәмәтдинова булалар.

1952 елда Бәзәкә мәктәбенә укытырга кайта һәм биредә 31 ел хезмәт куя.

1956-61 елларда читтән торып Алабуга дәүләт пединститутын тәмамлый.

Әдәбият – кешенең рухи дөньясы һәм гомумкешелек кыйммәтләре, образлы фикерләү, сүз сәнгате турында белем бирә торган фән. Әдәбият кешедә әдәп-әхлак, эстетик зәвык тәрбияләү, матурлыкны танырга өйрәтү көченә ия.

Менә шушы көчкә таянып, мөгаллимә Мәсгудә Мөхәмәтдинова 35 ел буе татар әдәбияты дәресләрендә үз шәкертләрендә мөстәкыйльлек, үз-үзенә ышаныч, иҗади фикерләү ихтыяҗы булдырырга тырыша, укучыга үз фикерен әйтә һәм исбатлый алу өчен шартлар тудырырга, һәр балада талантлы, үзенчәлекле шәхес күрергә омтыла.

Мөгаллимә үз эш стилен булдыра. Балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, һәр дәрескә иҗади әзерләнә, яңа эш алымнарыннан киң файдалана, шәкертләрен татар теленең бөтен нечкәлекләрен, байлыгын күрә белергә өйрәтә. Класстан тыш укуга зур игътибар бирә, яңа китап-әсәрләр белән таныштыра, балаларны газета-журналларга күзәтү ясарга өйрәтә, язучыларга багышланган кичәләрне оста оештыра.

Тел һәм әдәбият кабинетында һәр дәрес өчен дидактик материаллар тупланган папкалар (аларның күпләре балалар белән кулдан эшләнгән), язучылар иҗатын яктырткан альбомнар булдыра.

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мәсгудә Мөхәмәтдинова районда иҗади эшләүче мөгаллимнәрнең



берсе булды. Ул, укучыларны матур әдәби телдә сөйләшергә һәм грамоталы язарга өйрәтү белән бергә, мәдәни һәм рухи хәзинәләребез нигезендә тәрбияләүгә зур игътибар бирде. Дәресләрдә әдәби әсәр белән танышкач, төрле чагыштырулар аша, уңай яки тискәре якларын күрсәтеп, образ-геройларны бәяләгәндә, мөгаллимәбез гел бер сорау бирә иде: "Ә син бу очракта нишләр идең?" Менә шушы гади генә сорау сине әллә нишләтә дә куя. Син үзеңнең күңел сандыгыңны ачып, уй-хисләреңнең, кичереш-тойгыларыңның тышка бәреп чыкканын сизми дә каласың. Күңелендә ни бар – шуны укытучың, иптәшләрең алдына чыгарып саласың. Шушы юл белән ул безгә яхшыны – начардан, акны – карадан, хакны – нахактан аера белергә өйрәткән икән ләбаса. Әдәбият дәресләрендә үткәрелгән шигъри минутлар балаларның күңелен сафландыра, шигърияткә мәхәббәт тәрбияли. Менә шушы мәхәббәт безне сәхнәләргә менгерде, халык алдына чыгарды. Без, 9-11 нче сыйныф укучылары, шигырь-поэмаларны дулкынлану хисләре белән дәртләнеп, рухланып сөйли идек.

Йомгаклап, шуны әйтәсе килә: үсеп килүче буынга тирән белем бирү, аларда туган телебезгә мәхәббәт, халкыбызның бай мирасы белән кызыксыну тәрбияләүдә, шәкертләренә тел дигән дәрья төбеннән энҗе-мәрҗәннәр табарга өйрәтеп, шул асылташларны төссезләндерми, югалтмый, гомер буе саклап калу юнәлешендә армый-талмый эшләгән мөгаллимә ул, Мәсгудә Мөхәмәтдинова!

Олы рәхмәт Сезгә, кадерле Укытучы Апа! Исән-сау булыгыз!

Нәфис хәрбиләргә

Үз хезмәтенә чын күңелдән яратып караган, аны ихлас күңел белән булсын дип башкарган кеше генә үз алдына куйган максатына ирешә ала. 30 елдан артык гомерен мәктәптә балаларга белем бирүгә багышлаган укытучы Зәйнак Әһлетдин улы Әһлиев менә нәкъ шундыйлардан дисәк, ялгышмабыз, шәт.

1927 елның 4 маенда туган. 9 нчы сыйныфны бетергәч, 44 елның көзендә Совет Армиясе сафларына алына, Балтыйк буе гаскәрләрендә хезмәт итә. Сугыш беткәч, Урал хәрби округында укып, кече командир була һәм 1951 елдан Зәйнак Әһлиев – офицер. Ул Ерак Көнчыгышта, ягъни Курил утрауларында, Сахалинда 9 ел хезмәт итә. Запастагы офицер булып демобилизацияләнгәч, теше-тырнагы белән белем алуга керешә. Башта урта мәктәпне, аннан соң, читтән торып укып, Казан дәүләт университетын тәмамлый һәм туган авылы Бәзәкәдә укучыларны башлангыч хәрби хезмәткә һәм авыл хуҗалыгы фәненә өйрәтә башлый.



Ул җитәкчелек иткән чорда Бәзәкә урта мәктәбенең производство бригадасы күркәм уңышларга ирешә. Аның балалар белән яулаган мул уңышны чагылдыручы экспонатлары республика күргәзмәләрендә катнаша һәм Татарстан Мәгариф министрлыгы тарафыннан грамота һәм кыйммәтле бүләкләр белән билгеләнә. 1964 елда производство бригадасының алдынгы әгъзасы Гыймазетдинова Рәмзия Мәскәүдә яшь натуралистларның IV Бөтенроссия слётында катнаша. Бер уңайдан әйтеп китми булмый, чыннан да, мәктәбебезнең производство бригадасы искиткеч үрләр яулый иде. Башта Зәйнак абый, аннан соң Шәмсия Гыймазова җитәкчелегендә һәм укытучылар тырышлыгы белән ул үз биеклекләрен югалтмый. Соңрак, шушы ук бригаданың икенче члены Сабитова Наилә Ставрополь краеның Новопавловская станицасында уздырылган укучылар производство бригадаларының Бөтенроссия слёты делегаты була, ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамотасын алып кайта.

Зәйнак абый Әһлиев дистә еллап мәктәптә директор булып эшләде: башта Турай мәктәбендә, аннары Бәзәкәдә.

Мөгаллим күп еллар җәмәгать эшләрендә бик актив катнашты: агитатор, пропагандист, партия оешмасы секретаре, авыл Советы депутаты булды, ветераннар советын җитәкләде. Әмма Зәйнак Әһлиевның чын сәләте, осталыгы укучыларга хәрби-патриотик тәрбия бирүдә ачыла. Ул егет-кызларга чын мәгънәсендә башлангыч белем һәм күнекмәләр бирә. Военрук оештырган сугыш



Сыйныф җитәкчесе Зәйнак абый чыгарылыш укучылары арасында. 1958 ел

ветераннары һәм армиядән кайткан солдатлар белән очрашулар, КВНнар, төз ату һәм винтовка сүтеп-җыю бәйгеләре, тирда ату күнегүләре (шушы урында искәртеп китәргә кирәк, Зәйнак абый, зур тырышлыклар белән, мәктәп янында диаметры – 6, озынлыгы – 25 метр булган ике параллель торбадан менә дигән тир булдыруга иреште) – болар барысы да яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләүдә отышлы чаралар була. Ә винтовканы күзләрне бәйләгән килеш сүтеп-җыю – үзе бер тамаша. Әле егетләр генә түгел, кызлар да искиткеч осталык күрсәтәләр, һәр детальнең исемен дөрес атыйлар. Ул заманнарда бик популяр булган “Ажаган” (пионерлар өчен), “Бөркеткәй” (комсомоллар өчен) хәрби спорт уеннарында балалар бик теләп катнашалар иде. Әйе, беренче карашка уен кебек кенә, әмма күпме сынау-каршылыкларны җиңәргә, зур

тырышлыклар куярга туры килә иде укучыларга бу уеннар вакытында. Тик борчылырга урын юк, аларны моңа остазлары Зәйнак Әһлиев даими һәм нык әзерли. Ул егетләргә патриотик рухта: "Сез – Ватанны саклаучылар!" – дип, һәрчак искәртеп тора.

Зәйнак абый һәрчак хәрби киемнән йөрде, укучылардан да шуны таләп итте. Военрук абыебыз мәктәптә тәртипне коры тотты, бигрәк тә малай-егетләрне күз уңаеннан югалтмады. "Башыңны туры тот! Бөкрәеп йөрмә! Төз йөр, матур атла!" – дип кисәтеп, эленке-салынкы йөрергә урын калдырмый иде. Үзе дә гомере буе хәрбиләргә хас күнекмәләрен югалтмады: төз гәүдә, төгәл, җитез хәрәкәтләр, ныклы адымнарыннан аны әле бүген дә әллә кайлардан танып була.

Берара Зәйнак абый физкультура һәм география дәресләрен алып барды. Үзе хезмәт иткән Ерак Көнчыгышның табигатенә: сихри гейзерларга, мәһабәт сопкаларга безне гашыйк итте. Бу фәннәрне дә ул укучыларына яраттыра алды. Географиядән дәрес материалын гына түгел, кайсы вакытта сорасалар да, картаны яхшы белүне таләп итте.



Хәрби сбор вакытында. Басканнар: сулдан беренче – Ахунов Шәрифҗан, өченче – Зәйнак Әһлиев. 1973 ел

1987 елда лаеклы ялга чыгып, әле берничә ел мәктәптә эшен дәвам итте. Тормыш иптәше Әнисә апа белән ике бала үстер-

деләр, икесе дә югары белемле, матур тормыш корып яшиләр.

Әйе, инде укучылары үз гомер сукмакларының инде ягтысын узып барган мәлдә остазлары Зәйнак Әһлиевның исән-имин, сау-сәламәт, аңлы-зиһенле булуы, шәкертләре белән ачык, тирән фикер сөреше белән теләсә нинди темага әңгәмә кора алуы – соклангыч күренеш. Киләчәктә дә шулай була күрсен.

Рәхмәт сезгә, кадерле Укытучы!

Өлкән буын укытучысы

...1931 ел, август азагы. Бәзәкә авылы урамы буйлап кулына кечерәк кенә чемодан тоткан, озын, төз гәүдәле, кыска чәчле бер кыз килә. Өстендә гәүдәсенә килешле итеп тегелгән матур күлмәк, аякларында ялтыравыклы туфлиләр.

Урамда очраган һәр кеше, туктап-туктап, кызга текәлеп карап кала. Аякларына чабата, өсләренә киндер күлмәк-ыштан кигән бәзәкәлеләр өчен чиста-пөхтә, яңача киенгән кызны күрү гайре табигый хәл була.

Кем булыр бу? Нишләп йөри?

Ул арада кыз мәктәпнең кайдалыгын сорый. Укытучы икән ләбаса. Бәзәкәгә әллә Казаннан, әллә Алабугадан килгән, исеме Оркыя икән, дигән сүзләр шунда ук авылга тарала.



Унда Оркыя апа Вәлиәхмәтова. 1933 ел

Вәлиәхмәтова Оркыя Вәлиәхмәт кызы 1909 елда Буа районының Мунчали авылында туа. Нәселе инсафлы, затлы, бабалары 10 буын муллалар. 1930 елда гаиләләре Алабугага күченеп килә. Бу шәһәрдә укытучылар әзерли торган бер еллык курста укый һәм шул ук елны аны Бәзәкә авылына укытучы итеп билгелиләр. Оркыя апа белән бергә авылга, мәктәпкә матурлык, зәвыклык дигән төшенчәләр килеп керә. Ул кигән матур, үзенә үтә килешле күлмәкләр, эшләпә, шарф, беретлар авыл хатын-кызлары арасында әле күрелмәгән нәрсәләр була.

1931-34 елларда читтән торып Алабуга педучилищесын тәмамлый. Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта. Укытудан тыш, ул авыл халкын наданлыктан арындыру максатында оештырылган "ликбез"ны җитәкли, бу эштә иң беренчеләрдән булып катнаша. Яшь укытучыларга өйдән-өйгә кереп, халыкны ничек укытырга, нәрсәдән башларга икәнлекне аңлата, төшендерә, үзе дә дистәләгән грамотасыз кешеләргә башлангыч уку-язу күнекмәләрен өйрәтә.

Инде 1927 елда ук оештырылса да, һаман җайга салына алмаган пионер оешмасының хәлен күреп, Оркыя Вәлиәхмәтова аны аякка бастыру, балаларны күпләп пионерга кертү эшенә алына, эшне башкарып чыгарына ышана. Һәм ялгышмый. Зур тырышлык белән аңлату эшләре алып бара, һәр балага шәхсән якын килә. Кичә генә оешмага керергә теләгән балалар, иртәгесен, сөмсерләре коелып, "Апа, мин пионерга кермим, әтиләр ачулана", – дип елап киләләр. Тагын әти-әниләре янына барырга, бу оешманың максатын, эчтәлеген аңлатырга, үгетләргә туры килә. Шулай итеп, пионер оешмасына балалар күпләп керә башлыйлар. Бәзәкә мәктәбе пионер оешмасының киләчәктә ирешәчәк уңышларында, яулаячак җиңүләрендә аны оештыруда, аякка бастыруда үзеннән зур көч һәм ихтыяр күрсәткән укытучы Оркыя Вәлиәхмәтованың роле бик зур.

Оркыя апа, татар теленнән тыш, мәктәптә география, тарих, хезмәт дәресләрен дә укытты, өлкән буынның мөх-



Утырганнар: сулдан уңга – Разживина Наталья (Комаровка авылыннан), Вәлиәхмәтова Оркыя апа, Галимуллина Мәүлидә; басканнар: Шакиров Галимҗан, Зиннәтуллина Гаян. 1948 ел



тәрәм укытучысы булды. 1966 елда лаеклы ялга чыкты.

Өлкән мөгаллимә ире белән өч кыз тәрбияләп үстерде, өчесенә дә дөрес тәрбия, күркәм үрнәк сыйфатлар бирделәр. Өлкән кызлары Альта апа Мәхмүтова галим булды. Казан дәүләт университетының татар халкы тарихы кафедрасы доценты.

Алисә апа шулай ук Казанда бер оешмада җитәкче булып эшли, Әнисә Алабугада 30 елдан артык рус теле укытты, I категорияле укытучы булды.

1982 елда Оркыя апа Вәлиәхмәтова бакыйлыкка күчте. Урыныгыз оҗмах, рухыгыз шат булсын, кадерле Укытучы.

Шатлык өлгешче Әдия

...Май аеның гадәти бер эш көне иртәсе. Бәзәкә авылы урамнары шау-гөр килеп мәктәпкә баручы укучылар төркеменең көр авазларына күмелгән. Бер төркемдә баручы кызыл галстуклы пионерлар, култыгына газета-журналлар, китаплар кыстырган урта яшьләрдәге җитез хәрәкәтле апа белән янәшә атлап, кызып-кызып аңа нидер сөйлиләр, ара-тирә туктап, бәхәсләшеп тә алалар.



Апа дигәнебез – Бәзәкә урта мәктәбенең өлкән пионервожатые Әдия Сәлим кызы Ибраева (1926 елгы, крестьян гаиләсендә туып-үскән). Аның балаларга сөйләрдәй, бәхәсләшердәй, уйлашырдай сүзләре байтак җыйналган, күрәсең. Остаз балалар белән мәктәпкә килеп җитүен сизми дә кала.

Мавыгу характерны формалаштыра, кешене җәлеп иткән эш аның тышкы халәтен үзгәртә диләр. Кызыл галстук, ак кофта Әдия Ибраевага аеруча яшьлек, тантаналылык төсмере бирә.

Ә вожатый биографиясе болай башлана: урта мәктәпне тәмамлаганнан соң ул Минзәлә педучилищесына укырга керә. Аннан соң яшь, тырыш, актив кызны Казанда ВЛКСМ өлкә комитеты каршында вожатыйлар өчен оештырылган читтән торып уку университетына (ЗУПВ) курсларга җибәрәләр. Ике елдан Әдия Ибраева, кызыл галстук бәйләп, туган авылы Бәзәкәгә кайта. Шул чордан вожатый галстуктан беркайчан да аерылмый.

Ул җитәкләгән дружина озак еллар дәвамында районда гына түгел, бәлки республика буенча иң яхшыларның берсе була. Монда инде барлык пионерларның да уртак тырышлыгы, омтылышы барлыгы ачык аңлашыла. Нинди генә ут борчасы булмасын, берәүнең дә үзе генә әллә

ни эш майтара алмаслыгын Әдия апа яхшы белә.

Дружина пионерлары, В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасы игълан иткән маршларның төрледән-төрле маршрутлары буйлап уңышлы хәрәкәт итеп, мактауга лаеклы эшләр башкаралар. Авылның беренче пионерлары Әминә Бәдертдинова, Хәй Гыйльфанов, Мәрьям Көләчева белән очрашулар уздыру дисеңме, сугыш һәм хезмәт батырларының җырга тиң гомер елъязмаларын мәңгеләштерү дисеңме...



Актив комсомол кызлар. 1958 ел

Укучылар макулатура, көл, тимертомыр, дару үләннәре җыю операцияләрендә башлап йөриләр. Бер елны пионер кыз Әюпова Рәвия, 130 кг гөлҗимеш җыеп тапшырып, Уфа витамин заводының кыйммәтле бүләгенә – велосипедка лаек була.

Район буенча ел да үткәрелә торган үзешчән сәнгать смотрында Бәзәкә мәктәбенең пионерлар һәм комсомоллар коллективы дистәдән артык еллар рәттән беренче урынны алып килә, Мактау кәгазьләренә һәм истәлекле бүләкләргә лаек була.

Уку, белем алу буенча да дружина уку елын югары процент өлгереш белән тәмамлый. Дружинадагы 7 отрядның бишесе “Алгы сафтагы отряд” исемен йөртә. Мондый гүзәл сәхифәләр исемлеген дәвам итәргә мөмкин. Әмма югарыда телгә алынганнары да өлкән пионервожатый Әдия Сәлим кызы Ибраеваның үз эшенә нык бирелгәнлеген, дружинадагы һәр пионер күңелендә ялкын кабыза алганлыгын ачык күрсәтә.

Менә ни өчен ел саен Бөтенсоюз пионер оешмасының туган көнендә Бәзәкә мәктәбе пионерлар дружинасы

байрагына “Уңфлангчы дружина” дигән җиңү тасмасын беркетәләр.

Ул елларда район вожатыйларының бер генә семинары да Әдия Ибраевадан башка узмый. Ә бер кышны юлларда бик нык бозлавык була. Юл булмау сәбәпле, трассага автобуслар да чыгарылмый. Әмма вожатый Әдия апа Бәзәкәдән Менделеевскига семинарга җәяү килә... Бүген үтелгән тема һәм сораулар турында иптәшләреннән кыскача белешеп, кайтыр юлга чыга. Инде көн кичкә авышкан, кайбер йортларда ут алынган була.



Вожатый Әдия апа Ибраева шәкерте АДПУ доценты, пионер хәрәкәте лидеры Сәлахи Тажиев белән. 1975 ел

Күңелемдә вожатыебыз белән бәйле байтак кызыклы хатирәләр саклана. Менә шундый бер истәлек. Һәр елны март аенда районда смотр концертлары була иде. Менә шул концертлар бетеп, без I урынны яулагач, кайтырга җыенабыз (безне алырга йөк машинасы килә). Бер-беребезгә сыенып, кузовка җәелгән саламга ятабыз да үзебез шунда ук “ижат иткән” җырны башлыйбыз. Хәтерлисезме, элек “Татар халык җырлары” китабында “Татбригада сугышчылары җыры” дигән җыр бар иде.

Фирганә-Бохара –
Без үткән ара,
Фрунзе – безнең командарм,
Дошманнарның җиңдек барын
Данлы елларда.

Ә без, шул җырның сүзләрен үзебезчә үзгәртеп, болай җырлый идек:



Бәзәкә-Бондюга –
Без үткән ара.
Әдия апа – командарм,
Бондюгларның җиңдек барын
Шушы көннәрдә.

Аннары дәррәү “Ура” кычкырабыз, шатлыктан кул чабабыз, инде шактый арыган булуыбызны да, ашыйсы килүне дә онытабыз.

Күп эшләде Әдия Сәлим кызы. Ничек өлгерде икән ул?! Шактый зур гаиләсе булуын да искә алсаң, аңа сокланмый мөмкин түгел. Күрәсең, үз хезмәтеңне вакыт үтсенгә генә түгел, чын күңелеңне биреп башкарсаң, Әдия апаның үзе әйтмешли “бер эшнең дә авырлыгын сизмисең”. Ул пионерлар белән бергә шау-гөр килеп яшәүдән, алар янында сабый бала була белүдән ямь тапты, укучылар ирешкән һәр уңышка чын күңелдән шатланды, үзе дә һәрчак балаларга шатлык өләште, безнең белән, сабыйларча куанып, җырлады, биеде. Бию дигәннән, Әдия апа, чыннан да, бик матур бии иде. Ял кичәләрендә баянчы янына килә дә: “Дамир, җаным, әйдә, уйна минем көйне”, – дия. Баянчыбыз – мәктәп директоры Дамир Гыймазов баянда матур итеп уйный, “окно”, ягъни буш сәгатьләрдә баянын алып: “Кызлар, сезгә комачауламыйммы? – дип сорый да, әкрен генә моңлы көйләрен уйный башлый иде. Ә без, шулай ук әлегә дәресләре булмаган хатын-кызлар, дәфтәр-көндәлекләребезне тикшерә-тикшерә, талгын гына агылган көйләрне ләззәтләнеп тыңлыйбыз. Менә шундый баянчы ничек итеп Әдия апаның теләген үтәмәсен инде. Ул өлкән вожатый апабызның яраткан “Тамчы” көен сузып җибәрә һәм биючебез салмак кына, төз, гүзәл акккош кебек, зал буйлап “йөзеп” китә. Ә без аны соңыннан алкышларга күмә идек.

Әдия Ибраевада тәрбияләнүчеләр арасында үзләрен почетлы пионер хезмәтенә багышлаган кешеләр дә бар. Болар: Алабуга дәүләт педагогия университеты доценты Сәлахи Таҗиев, Бәзәкә мәктәбендә 35 ел укытучы (шуның 25 елын өлкән вожатый) булып эшләгән, бүген инде

лаеклы ялдагы Рәмзия Гәрәй кызы Мөхетдинова һәм башка бик күпләр. Алар остазлары Әдия апа Ибраевага чиксез рәхмәтлеләр.



Әдия апа Ибраева үзенең актив пионерлары белән. 1958 ел.

Мәңге картаймас, һәрчак яшь булып калыр кебек Әдия апабыз 1999 елда безнең арабыздан мәңгелеккә китте. Авыр туфрагыгыз җиңел булсын, кадерле вожатый Апа!

Балалар һәм табигать дусты

Ботаника, зоология, биология дәресләрендә балаларда табигатькә: үсемлекләр, кошлар һәм хайваннар тормышына, әйләнә-тирә күренешләргә карата күзәтүчәнлек, игътибарлылык тәрбияләү мөһим бурычларның берсе булып тора.

Кайберәүләр музыкада, рәсем сәнгатендә, төгәл фәннәрдә бик яхшы фикер йөртә алсалар да, еш кына әйләнә-тирәдә очып йөри торган чыпчыкны песнәктән яки арышны бодайдан аера белмиләр. Кеше үзен чорнап алган тирәлектә югалып калмасын өчен, аны кече яшьтән табигать серләренә төшендерә башлау зарур. Әнә шулай эшләгәндә генә сабый күңелендә әйләнә-тирә мохит белән кызыксыну туа, ул әкренләп, табигатьтәге матурлыкны күрә һәм аңлый белергә өйрәнә. Бу исә аңарда табигать байлыкларына сакчыллык, шәхси җаваплылык тәрбияли.

Менә шушы күркәм сыйфатларны, тере табигать ту-

рындагы белемнәрне үз дәресләрендә безгә биология укытучыбыз Мәүлидә апа Галимуллина бирде.

Мәүлидә Галимуллина 1924 елда Бондюг районының Абалач авылында эшче семьясында туа. 1935 елда Татар Кокшанына күченәләр. Җидееллык белемне үз авылларында ала, урта мәктәпне Камайда тәмамлый.



Мәүлидә Галимуллинаның чәчәктәй яшьлек чоры авыр сугыш елларына туры килә. Мәктәпне әле генә бетергән 17-18 яшьлек кызларны шәфкать туташлары әзерләү курсларында укыталар, шул ук вакытта аларны урман кисү, күмер алу өчен агач яндыру кебек авыр эшләрдә йөртәләр.

Укытучы Мәүлидә апа белән без 5 нче сыйныфта таныштык. Әле дә истә, классыбыз белән "Хламидоманада" сүзен әйтә алмыйча җәфаланып беттек. Хор белән әйттерә-әйттерә, ниһаять, дөрес әйтергә өйрәтте апабыз. Укытучы Мәүлидә Галимуллина дәресләрендә төрледән-төрле таблицалар, муляжлар куллана, кызыклы тәҗрибәләр үткәреп, биология фәненең кызыклы, мавыктыргыч булуын укучылар аңына һәм күңеленә сеңдерә.

Укучылар өчен оештырылган хисапсыз дәрес-экскурсияләр туган якны, аның табигатен өйрәнүдә, тирәяк мохитне танып белүдә уңай йогынты ясыйлар. Шушы юнәлештә эзлекле эш алып барган мөгаллимә һәр баланың үз туган ягында үскән үлән-чәчәкләрен, агач-куакларын, кош-кортларын, киек-җәнлекләрен белсеннәр, таныссыннар, дөрес һәм чама белән файдалансыннар өчен нык тырышты, күп көч куйды. Ул мәктәптә озак еллар "Яшь натуралист" түгәрәген җитәкләде. Аның эшен түбәндәге максат белән алып барды: укучыларның биология фәненнән белемнәрен киңәйтү һәм тирәнәйтү, үсемлекләрнең үсешен күзәтү, тәҗрибәләр өчен материаллар туплау,

биология кабинеты өчен күрсәтмә әсбаплар әзерләү һәм башкалар.

Җәйге каникуллар вакытында да ул балаларга эштән бушаган араларда күбрәк табигатьтә булырга, үсемлекләр, бөҗәкләр, кошлар тормышындагы үзгәрешләрне күзәтергә, үләннәрдән гербарийлар тупларга биремнәр бирә иде.

Әле бүгенгедәй хәтерлим, минем әллә 5 нче, әллә 6 нчы сыйныфны төгәлләп килгән май ае. Әни иртүк колхозда эштә булу сәбәпле, озаграк йоклаганмын: сыер көтүдән калган. Шул сыерны көтү артыннан куа-куа шактый ерак юл үтелде. Минәч юлына килеп җиткәч кенә сыерны көтүгә куштым. Барганда мышнап төшсәм дә, кайтканда инде җырлый-җырлый кайтам, сулыкларны чаптыр-чоптыр ерып. Кинәт күзем үлән арасында ялтырап яткан бер әйбергә төште. Мин, туктап, күзәтә башладым. Куш учка сыярлык үтә күренмәле элпәдән торган куык үзе, ә эчендә борчак зурлыгында бик күп шарчыклар бар. “Ни булыр бу? - мин әйтәм-тукта, Мәүлидә апага алып кайтып күрсәтим әле, ул белсә белә инде. Ул бит биология укытучысы, табигатьтәге бар нәрсәне белә”. Тиз генә аягымдагы кәлүшнең берсенә куыкны җайлап кына салдым да, бер аякта кәлүш, сыңары-ялантәпи, чаптым авылга.

Табылдыкны бер банкага салып, төштән соң мәктәпкә киттем, аны дәрестә укытучыга күрсәттем. Мәүлидә апа аны игътибар белән карады, лупа белән дә күзәтте. “Бака уылдыгы бу, Рәмзия. Зур рәхмәт алып килгәнең өчен. Менә иптәшләреңә дә синең ярдәмең белән тере бака яралгыларын күрделәр. Кичен түгәрәккә килгәч, без әле бу экспонатны җентекләп тикшерербез, сөйләшербез. Шулай кызыклы табылдыкларга юлыксагыз, мәктәпкә алып килегез”, – диде ул. Әйе, табигать серләренә төшенү өчен күп белергә һәм эзләнергә кирәк шул.

Биолог Мәүлидә апа Галимуллина җитәкчелегендә укучылар мәктәп тирәли нинди генә агачлар үстерми иде! Чып-чын дендрарий! Каен, миләш, имән, карагай, артыш, чикләвек, сәрви, сирень агачлары бүген дә мәктәп тер-

риториясен бизәп, ямьләп торалар. Язын, алмагачлар һәм шомырт агачлары чәчәккә күмелгәч, чәчәк исләреннән башлар әйләнә...

Ә мәктәп яны участогы үзе ни тора иде! Яшелчә бакчасында эшләү – тормыш дәресе ул. Балалар биредә үсемлекләрнең үсүен күзәтәләр, аларны карап үстерү серләрен үзләштерәләр, яшелчәләргә зарар китерүче корткычлар белән көрәшергә өйрәнәләр. Берсеннән-берсе матур чәчәкләр үстерүнең укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү өчен зур әһәмияткә ия булуын яхшы аңлаган биолог Мәүлидә Галимуллина укучылары белән нинди генә төр чәчәкләр үстермәделәр!

Чәчәкләр белән берәттән, бакчада әллә нинди җиләк-җимеш, яшелчәләр, тәмләткеч үсемлекләр үстерелә, алар өстендә ел саен кызыклы тәҗрибәләр үткәрелә. Ә көзен балалар үзләре үстергән уңышның иң зур, иң авыр, иң кызыклы һәм иң күп чыкканнарын күргәзмәгә куялар, "Уңыш бәйрәме" үткәрәләр. Җәйге эшләрдә иң актив катнашканнарга грамоталар һәм бүләкләр тапшырыла. Мәктәп яны тәҗрибә участогы гомер-гомергә районда иң яхшылар исәбендә булды. Мул итеп җыелган яшелчә һәм җиләк-җимеш мәктәп ашханәсенә тапшырылды, артып калганы авыл халкына сатылды. Кергән акчага бакча өчен кирәк-ярак, орлык һәм инвентарь алынды.



Биология укытучысы Мәүлидә Галимуллина үзенең эш тәҗрибәсен башка укытучылар белән дә юмарт уртаклашты. Ул бик күп ачык дәресләр бирде, докладлар укыды, семинарларда чыгышлар ясады.

Тырыш укытучының фидакарь хезмәте югары бәяләнде: ул 1968 елда "Халык мәгарифе отличнигы" исеменә лаек булды. Мәүлидә апа Галимуллина 1982 елда лаеклы ялга китте.

Ире Хәй абый Гыйльфанов белән алар өч ул үстерделәр, бүген оныклары, оныкчыклары бар. Моннан да бәрәкәтле, хәерле тормыш бармы икән өлкән буын мәктәп ветераннары өчен! Озын гомер һәм ныклы саулык-сәламәтлек сезгә, кадерле Укытучы.

Бала җанлы мөгаллим

Без, укучылары, аны һаман елмаеп, мактап искә алабыз. Бәзәкә мәктәбендә 36 ел укыту дәверендә гаҗәп тыйнак, искиткеч әдәпле, үз эшен һәм балаларны чын-чынлап яратуы белән дан казанган укытучы иде ул.



Әхәт Габдулла улы Төхвәтуллин 1925 елда Бәзәкә авылында дөньяга килә. Әти-әниләре гади крестьян, соңнан колхозчы булалар. 1933 елның 1 сентябрендә беренче сыйныфка укырга керә. Тырыш укучы буларак, барлык фәннәрне бик теләп үзләш-терә. Аеруча физика, математиканы якын күрә. 1943 елда унынчы сыйныфны тәмамлый.

...Илдә сугыш бара. Мәктәптә укытучылар җитешми, бигрәк тә ир-ат укытучылар юк. Яшь егет Әхәтне мәктәптә эшләргә калырга чакыралар. Ул берсүзсез риза була һәм кичәге укучы бүген туган мәктәбендә укыта да башлый. Алга таба берара Камай мәктәбендә эшли. Сугыш беткәннән соң Бәзәкә мәктәбендә педагогик эшчәнлеген дәвам итә. 50 нче еллар башында Алабуга укытучылар институтын бетерә. 55-59 нчы елларда Киттән торып Казан дәүләт педагогия институтында укый, география укытучысы дигән диплом ала.

Әхәт абый Төхвәтуллин тиз арада балаларның һәм ата-аналарның иң якын дустына әверелә. Чөнки эшли башлавының беренче көннәреннән үк бер нәрсәгә яхшы төшенә: укытучы тирән белемле һәм үзе үрнәк тәрбияле,

бала җанлы булырга тиеш. Әхәт Төхвәтуллин гомере буе шундый кеше булды да. Әхәт абый Бәзәкә мәктәбендә иң универсаль укытучы иде дисәк, бу аңа карата дөрес бәя булыр. Чөнки мәктәптә бик күп төрле фәннәрне: математика, физика, химия, тарих, география, хезмәт, хәтта немец телен дә укытты.

Белем һәм тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеге турыдантуры укытучы һәм укучы эшчәнлегенә бәйле булуны күздә тотып, Әхәт Төхвәтуллин дәресләрендә укучылар күңелен күтәрердәй һәм шәхси инициативасын үстерердәй эш төрләрен актив куллана. Дәрес материалын аңлаткан вакытта балаларга элек билгеле булган әйберләрдән дә яңалык таба белү, бу яңалыкны тормышта дөрес куллану ысулларын өйрәтә.

Тәжрибәле укытучы дәресләрне оста оештыра, төрле күрсәтмә әсбаплардан, техник чаралардан киң файдалана.

Әхәт абый үтә инсафлы, итәгатьле кеше иде. Ата-аналар, хезмәттәшләре һәм укучылар белән һәрчак ипле, әдәпле сөйләште, беркайчан дорфа, тупас булмады. Начар билгене дә ул шелтәләп түгел, ә җайлап, менә болайрак итеп куя иде.

– Утырыгыз, Рәмзия, билге куям... икеле куям, – дия иде.

Ничек үпкәлисең инде шундый йомшак, тәмле телле абыйга. Икеле, тәк икеле...



Әхәт абый Төхвәтуллин үзе җитәкләгән класс белән. 1959 ел

Өлкән сыйныфларның җитәкчесе буларак, укытучыбыз бик еш һәм озаклап укучылар белән кырда, басуларда була иде. Аның җитәкчелегендә укучылар кукуруз үстерү өчен чүлмәк сугуда, чүп утауда, җитен йолкуда, бәрәңге җыюда, чөгендер сирәкләүдә эшләделәр. Балалар белән беррәттән үзе дә җигелеп эшли, ял вакытларында кызык хәлләр, мәзәкләр сөйләп, арыган, күшеккән балаларны көлдерә, юата. Ә тиктормас малайларны, ашап туйгач, тәмәке пыскытырга чокыр-чакырлар арасына ычкынмасыннар өчен, һәрберсен исемләп чакырып, үзе янына туплый иде дә, спорт дөньясындагы яңалыклар белән, үзе шахмат-шашка яратучы буларак, шахмат корольләре Капабланка, Алёхин, Фишер һәм башкалар турында мавыктыргыч итеп сөйли иде.

Әхәт абый, кырда эшләгән укучыларны сөендерү йөзеннән, еш кына колхоз яшелчәсеннән помидор яки кыярлар алып килә иде. 1-2 помидорны эшләпәсенә сала да, аннары бер укучыны арт белән бастыра: «Монысы кемгә» – дия-дия, яшелчәләрне һәр укучыга гадел итеп бүлә иде.

Укытучыбыз балалар белән табигатькә экскурсияләр, 2-3 көнлек җәяүле походлар оештырырга яратты. Шулай бер җәйне безне, бер төркем укучыларны, Кама аръягындагы бик күптәнге булган Матвей тегермәненә алып чыккан иде. Без җәяүләп башта Ижёвка авылына бардык, шунда, Кама яр буенда, учак ягып аш пешердек, кундык, иртәгесен су трамвае белән Белоус урманына чыктык, тегермәнне күрдек. Шулай итеп, туган ягыбыз табигате белән танышып, хозурланып, бик канәгать булып авылыбызга кайттык.

Әхәт абый Төхвәтуллин җәмәгать эшендә дә бик актив катнашты. Дистә еллап "Белем җәмгыяте"н җитәкләде, халык алдында лекция-докладлар укыды, радиоузелдан чыгыш ясаучыларны әзерләде, аларга материаллар табышты.

Болар укытучы өчен күпме көч, энергия, вакыт таләп итә торган эш-мәшәкатьләр. Ә бит укытучы кешенең әле төннәр буе дәфтәр тикшерәсе, планнар язасы, төрле отчетлар төзисе, иртәгесен мәктәптә классы белән дежур

торасы һәм башка күп төрле эшләре бар. Тагын гаиләсе, үз балалары, хуҗалык мәшәкатьләре күпме? Әйе, укытучы хезмәте билгеләнгән сәгатьләр эченә сыеп бетәрдәй генә түгел шул...

Шушындый тынгысызлык, борчу-мәшәкатьләр сәламәтлеккә зыян салмый калмый, билгеле. Әхәт абый пенсиягә кадәр үк, алты ел алдан "выслуга"га чыгарга мәҗбүр булды. Ә лаеклы ялга ул 1985 елда чыкты. 1993 елда укытучыбыз йөрәк авыруыннан кинәт вафат булды.

Урыныгыз оҗмахта булсын, кадерле Мәгаллим абый. Сез артык гади, риясыз, әйбәт кеше идегез.

Династия дәвамчысы



Укытучы Көләчевлар династиясенең дүртенчесе – Көләчев Тәгъзим Гатаулла улы. Ул 1930 елда Бәзәкә авылында туа, мәктәпкә кадәр балалар бакчасына йөри. 1938 елда беренче сыйныфка укырга керә. Мәктәп елларында тырышып укый, математика, физика фәннәрен ярата, бу фәннәрдән мисал, мәсьәләләргә бик тиз төшенә, тиз чишә. Пөхтә, матур язуы белән сыйныфташларыннан аерылып тора. 1948 елда Алабуга укытучылар институтына укырга керә. Аны 1952 елда тәмамлап, Чаллы районының Суыксу мәктәбендә укыта башлый. Әмма тиздән аны Совет Армиясе сафларына алалар. Солдат хезмәтен Хабаровск краенда үтә. Армиядән кайткан елны ук Бәзәкә мәктәбендә математика укыта башлый.

Көләчев Тәгъзим абый – үз һөнәрен яратып, бар белемен чын күңеленнән балаларга бирергә тырышучы укытучы иде. Үзе тыныч, сабыр һәм үтә юаш кеше. Аның бу сыйфатларын белеп алган балалар дәресләрендә шаярып,

шукланып та алырга яраталар иде. Әмма ул, киң күңелле һәм зур түземлелеккә ия буларак, укучыларга беркайчан да тавыш күтәрми, ачуланмый, ә киресенчә, ипләп-җайлап кына аларны әдәпле һәм тәртипле булырга чакыра, һәр укучыга үз фәнен белдерергә, яраттырырга тырыша. Класста яңа дәрес материалын аңлатканда да, мөстәкыйль эшләр оештырганда, өстәмә дәресләр үткәргәндә дә – ул һәрчак сабыр, гадел укытучы. Гомумән, ул гомере буе әдәпле, инсафлы кеше булды.

Тәгъзим абый Көләчев хезмәттәшләре белән дус, тату мөгамәләдә булды, кирәк икән, һәркемгә ярдәм кулын сузарга әзер торды.

Укытучыбыз шахмат-шашка уйнарга яратты. Бу спорт төре буенча районда укытучылар арасында уздырылган ярышларда, мәктәп данын яклап, бер каршылыксыз һәм бик теләп, ел саен катнашып килде. Ул ярышлардан һәрчак Мактау кәгазьләре алып кайта иде.



Район ярышларында катнашкан көн. Тәгъзим абый уңнан икенче. 1985 ел

Тәгъзим абый Көләчев Песәй кызы Саимә апа белән гаилә корып, ике бала үстерделәр. 1984 елда, 54 яшендә Тәгъзим абый Көләчев вафат булды.

Урыныгыз җәннәттә булсын, кадерле Укытучы.

Уйный баян, уйный үзәкләрне өзеп...

...Мәктәп заллары буйлап йөрәккә ятышлы моңлы көй агыла. Ул, ургып чыккан чишмә төсле, әле көчәя, әле җәйге җылы җил кебек, җанга назлы, йомшак кагылып, ачык тәрәзәләрдән тышка чыга да, мәктәп яны каеннары арасына кереп югала...

Кулына баян тотып сихри көйләр тибрәтүче, безнең яраткан җыр укытучыбыз Нурулла абый Аликин, күзләрен йома төшеп, үзе тудырган көй-моң тавышын әллә тыңлый, әллә уйлый, әллә инде күңеленнән үксеп елый... Уйный баян, уйный үзәкләрне өзеп...



Аликин Нурулла Ярулла улы 1923 елда Чаллы районының Суыксу авылында игенче гаиләсендә туа. Кечкенәдән үк көйгә-моңга гашыйк була. Оста җырчыларны онытылып, авыз ачып тыңлый, гармун уйнаучының бармак хәрәкәтләрен бирелеп күзәтә, аңа таба якынрак елыша. Әти кеше улының көй-моңга хирыс икәнлеген сизә, күрә, ләкин ничек аны гармунлы итәргә? Менә шуны-сы күңелне борчый, йөрәкне телгә-ли. Алай да Ярулла абзый ныклы карарга килә: гаилә авызыннан өзеп булса да Нурулласына гармун алып бирергә! Әйткән сүз – аткан ук. Озак та үтми, әти кеше Чаллы базарыннан тальян гармун алып кайта. Шул вакытта кечкенә Нурулланың әй шатланганнары, сөенгән-нәре! Әйтерсең лә аңа ат бүләк иттеләр.

Менә шул көннән башлап, Нурулла Аликин гармуныннан аерылмый инде. Аның гармуны мәктәптә укыганда сабакташларына, авыл халкына, армия хезмәтендә солдат дусларына, фронтта сугышчан иптәшләренә көй-моңнарны, сагыш-шатлыкларны мул өләшә, күңелләргә кагыла, үзәкләрне өзә...

Нурулла Аликинның Бәзәкә мәктәбенә килүенең үз тарихы бар. Сугыштан соңгы еллар. Мәктәп директоры – фронтовик Гайнан Әхмәтов мәктәп өчен утын хәстәрләү мәсьәләсендә һаман шул Белоус авылына килә, лесник белән киселәчәк делянкаларны карап-күреп йөри. Кайтыр алдыннан кибеткә сугыла. Ә анда кечкенә генә буйлы, ябык гәүдәле ир-ат, өздерепме-өздереп баян уйный. Кибет эче көй-моң белән тулган. Директор, монда нигә кергәнлеген, нәрсә алырга тиешлеген дә онытып, әсәрләнеп уйнаучыны тыңлый. Менә баян тынып кала. Бераздан Гайнан Әхмәтов уйнаучыга дәшә:

– Егет, әйдә минем мәктәпкә. Тиешенчә дәресләр бирербез. Менә дигән квартирга урнаштырырмын. Зинһар, үтенечемне кире какма.

Баянчы, бераз гына уйланып тора да, елмаеп җавап бирә:

– Ә нигә бармаска, барам.

Менә шулай Нурулла Аликин, әле күптән түгел генә сугыштан кайткан, өстеннән солдат гимнастеркасын һәм галифе чалбарын да салмаган килеш, Бәзәкә мәктәбенә килә.



Рәсемдә баянчыбыз Аликин Нурулла абый, шул елларда пионервожатый булып эшләгән Тәскирә Хуҗиәхмәтова. 1960 ел

Аның җыр-музыкага, матур итеп рәсем ясарга сәләтле, бик күп нәрсәләргә һәвәс кеше булуын мәктәптә тиз белеп алалар. Аңа җыр, рәсем, сызым, физкультура дәресләрен бирәләр. Мәктәп залларын һәм бүлмәләрен эстетик зәвык белән бизәү эшләре Аликин Нурулла өстендә була. Укытучыларга төрле чаралар, ачык дәресләр өчен, районга, республикага җибәрү максатыннан нинди төр плакат, стенд, альбом, транспарант кирәк булмасын – болар барысы да Аликин абыйның йөрәк җылысын биреп тудырган хезмәт җимешләре була.

Көй-моңга тартылган балалар өчен ул "Яшь баянчылар" түгәрәге оештыра. Бик күп малайларның күңеленә музыкага карата мәхәббәт орлыклары сала.



Нурулла абыйның яшь баянчылары. ("Работница" – Бөтенсоюз журналында чыккан фото. 1972 ел

Аликин абый холкы буенча гаять юморлы, кызык кеше иде. Һәрвакыт берәр мәзәк, көлкеле хәл сөйләп, кызык, шаян сүз әйтеп, һәркемнең күңелен күтәрә, үзе дә рәхәтләнеп көлә. Ә сәхнәдә нинди артист иде ул! Теге яки бу рольне "Аликин Нурулла башкара", – дип әйтеп бетермәстән, зал шаулатып кул чаба башлый, авыз ера. "Артист" үзе сәхнәгә чыгып басуга, халык егылып көлә, аңа сүз башларга ирек бирми. Шунлыктан аңа соңга таба көлкеле рольләр бирмәс булдылар. Әмма халык аның башкаруында җитди рольне барыбер кабул итмәде.

Нурулла абый гаиләсе белән Алабугада яши башлагач та (хатыны Нурия апа нефть промыселында эшләде), Бәзәкәгә вахта автобусларында килеп укытып йөрде.

Иртәнге 6 да чыгып китеп, кичке 6 да өенә кайтып кереп эшләсә дә, ул һәрчак диярлек репетицияләрдә булды, смотр, концертларда катнашты, бер мәдәни чараны да өзмәде. Ул вакытларда мәктәбебезнең район смотрларында ел саен беренче урыннар алып килүендә җыр-музыка укытучыбыз Аликин Нурулла абыйның өлеше гаять зур булды.

Күп еллар узса да, соңарып булса да (инде үзе булмаса да, балалары укыр), болар өчен остазыбызга зур рәхмәт әйтәсе килә. Сез, кыска гына буйлы, җиңел-җитез гәүдәле, һәрчак шаян сүзле, елмаюлы укытучыбыз Нурулла абый, без – балалар күңелендә эстетик зәвык, матурлык, гүзәллек сыйфатлары тәрбияләп, үзегез дә якты, гүзәл кеше булып күңелләребездә сакланасыз. Рухыгыз шат булсын, кадерле Укытучы!

Бала дөрес юл сайласын

“Тарих – олы сабак ул”, – дип әйтергә ярата иде үз фәнен балаларга белдерәсе, яраттырасы килеп, тарих укытуга зур тырышлык куйган мөгаллим Мулланур Тажиев.



Тажиев Мулланур Минһажетдин улы 1928 елда Бондюг районының Бәзәкә авылында хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. 1937 елда туган авылы мәктәбенең беренче сыйныфында укый башлый. 9 нчы сыйныфны бетергәч, Минзәлә педучилищесына укырга керә. Аны тәмамлаганнан соң, Бондюг районының Бөрешле авылында башлангыч мәктәптә бер ел, аннары ике ел Бәзәкәдә укыта. 1949 елда Совет Армиясе сафларына чакырыла. Солдат хезмәтен төгәлләп кайт-

кач, яшь белгечне шушы ук районның Сәйтәк авылы башлангыч мәктәбенә укытучы һәм мәктәп мөдире итеп билгелиләр. Биредә эшләү дәверендә читтән торып укытучылар институтын һәм Казан дәүләт педагогия институтының география һәм табигать фәннәре факультетын уңышлы тәмамлый.

1955 елның сентябреннән Сәйтәк авылы башлангыч мәктәбе сигезьеллык итеп үзгәртелә. Мулланур Таҗиевны кабат мәктәп директоры итеп билгелиләр. Шул көннән башлап 1971 елга кадәр, ягъни Сәйтәк мәктәбеннән киткәнче, ул укытучы һәм директорлык вазыйфаларын башкара. Җәй-кыш, яз-көз, яңгыр, пычрак, буран дип тормый, көн саен иртә-кич әле җәяү, әле велосипедта, әле юлда очраган машинага утырып мәктәпкә килә, балалар укыта. Шушында партия сафларына алына, озак еллар авыл һәм мәктәпнең партия оешмасын җитәкли.

Сәйтәк зур авыл түгел. Әмма ул елларда мәктәптә балалар саны шактый күп була. Мулланур Таҗиев директор булган чорда мәктәпнең педагогик коллективы балалар арасында ныклы тәртип булдыру, тулы өлгерешкә ирешү, дәресләр калдырмау өстендә бердәм һәм нәтиҗәле эш алып бара. Тырыш, принципиаль, куйган максатына ирешүчән директор җитәкчелегендәге укытучылар, балалар зур тормышка әзерлекле, белемле һәм тәртипле булып чыксыннар өчен бөтен көч-энергияләрен, тырышлыкларын бирәләр. Укучылар мәктәпара һәм район олимпиадаларында, төрле бәйгеләрдә һәм ярышларда алдынгы урыннарны яулыйлар, Мактау кәгазьләренә, дипломнарга, бүләкләргә лаек булалар.

Мулланур Таҗиев, география, тарих фәннәрен укытып, балалар күңелендә туган як табигатенә мәхәббәт, аның тарихы белән кызыксыну, кешеләре белән горурлану кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләргә омтыла. Сәйтәк әрәмәлегенә, басу-кырларга, якындагы нефть промыселына, химзаводка күпсанлы экскурсияләр оештыра. Бала укыганда ук игенче, механизатор, нефтьче, завод эшчесе, төзүче һәм башка һөнәрләрне дөрес сайлап алсын өчен,

һөнәри әзерлеккә өйрәтүгә зур игътибар бирә. “Һәр бала киләчәктә дөрес юл сайласын”, – дип тырыша директор. Мулланур Таҗиевның педагогик эшчәнлегенең тагын бер асыл ягы – тәрбиягә авыр бирелүче укучылар белән индивидуаль эшләү. Көн саен, даими, иртәгәгә калдырмый башкара ул бу эшне. Авыр тәрбияләнүче укучыны көн саен күз уңаенда тоту, сөйләшеп, тикшереп, белешеп тору, ата-аналары белән тыгыз элемтәдә булу кебек гамәлләр, һичшиксез, эзсез калмый, уңай нәтиҗәләр бирә.

Мөгаллим җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Һәр сайлау кампаниясендә алыштыргысыз сайлау комиссиясе рәисе, пропагандист, лектор була. Мәктәп коллективы белән авыл халкы алдында концерт, спектакльләр куюда үзе башлап йөри, төп рольләрдә катнаша.

1971 елдан Мулланур Таҗиев Бәзәкә мәктәбендә укыта башлый, лаеклы ялга чыкканчы шушы коллективта эшли. Яңа урында да укыту-тәрбия эшендә төгәллек, тәвәккәллек, башлаган эшен азагына кадәр башкарып чыгу кебек сыйфатларын югалтмый, киресенчә, арттыра гына. Ул җитәкләгән сыйныф укучылары ныклы белемле, җәмәгать эшләрендә бик актив булулары белән аерылып торалар.



Мулланур Таҗиев үзе җитәкләгән сыйныф белән. 1973 ел

Балалар укытуда һәм тәрбияләүдә фидакарь хезмәте һәм ирешкән уңышлары өчен Таҗиев Мулланур 1965 елда “Халык мәгарифе отличнигы” дигән мактаулы исемгә лаек була.

Фельдшер кыз Лотфиева Шәмсия белән 1957 елда гаилә корып, балалар үстереп, аларга күркәм тәрбия бирәләр.



Мулланур абый холкы белән ачык күңелле, уен-көлкеле кеше иде, шаяртып сөйләшергә, яшьтәш коллегалары белән гәп корып, яшьлекләрендә булган кызык хәлләрне искә төшерергә ярата иде. Укытучылар кичәләрендә, бәйрәмнәрдә актив катнашты: элек үзләре яратып биегән “Сигезле”, “Маршлы” биюләрен безгә, ул вакыттагы яшьләргә, өйрәтергә теләп, “ду” китереп, уенга бастыра иде. Бию тәмамлангач, Мулланур абый, безне таратмыйча, әйләп-бәйләндәге кебек бер “җепкә” тезеп, үзе тирәсенә “урый”, үзе уртада кала. Барыбыз да “уралып” беткәч, кулын югары күтәрә дә: “Яшәсен укытучылар көне! Совет укытучыларына – дан!” – дип кычкыра. Ә без “Ура!” кычкырабыз, рәхәтләнеп көлешәбез. Шул кичә-бәйрәмнәрдә хатыны Шәмсия апа белән матур итеп вальс бии иде. Икесе дә озын, төз буй-сынлы, горур кыяфәтле бу пар, иң беренчеләрдән булып, залның бер башыннан икенче башына кадәр бөтерелеп-әйләнеп, үтә килешле һәм сокландыргыч итеп бииләр иде...

1988 елда Мулланур абый Таҗиев лаеклы ялга чыкты.

1997 елның сентябрендә йөрәк авыруы көтмәгәндә аны безнең арабыздан мәңгелеккә алып китте.

Тыныч йоклагыз, кадерле Укытучы!

Тормышта кирәк булачак

Мулланур абый Тажиевның тормыш иптәше Лотфиева Шәмсия Вагыйз кызы Бәзәкә мәктәбендә шактый еллар санподготовка дәресләрен алып барды.

Ул Минзәлә районының Калмыя авылында туып үсә. Шушы авылда 4 сыйныфны тәмамлаганнан соң, көн саен барып-кайтып, 8 км ераклыктагы Күзкәй мәктәбендә укый. 10 нчы сыйныфны бетергәч, Минзәлә медучилищесында белем ала. Юллама буенча Бондюг районының Тойма авылында сигез ай эшли, аннары Бәзәкәгә килә. Бәзәкә егете Мулланур Тажиев белән гаилә коралар, 40 ел бергәләшеп тормыш алып баралар, өч бала үстерәләр, өчесенә дә югары белем алырга бөтен мөмкинлекләрне булдыралар.



70-80 нче елларда урта мәктәпләрдә башлангыч хәрби әзерлек дәресләре укытыла. 9-10 нчы сыйныф егетләре Зәйнак Әһлиев белән хәрби серләргә төшенсәләр, кызлар Шәмсия апа белән медицина нечкәлекләрен өйрәнәләр. Шәмсия апа, чын табибә буларак, ак халатын, башлыгын киеп, кызларны гражданнар оборонасында шәфкать туташлары, санитарлар алдында торган бурычлар белән таныштыра, аңлата: яраларны бәйләү, шин кую, носилкалар белән эш итү, беренче ярдәм күрсәтү һәм башка күнекмәләрне өйрәтә. Соңнан теоретик һәм гамәли белемнәр буенча зачётлар ала. Кайвакытта кызларның кайберләре: “Апа, безгә бу нигә кирәк инде? Мин, мәсәлән, медицина буенча китмәячәкмен”, – дип куялар.

Табибә аларга тыныч кына җавап бирә: “Кызлар, сез булачак әниләр. Гаиләдә балалар үстергәндә, гомумән,

тормышта бу белемнәр сезгә бик кирәк булачак. Белгәнне күтәреп йөрисе түгел”.

Шәмсия апа Бәзәкә авылында 45 ел берөзлексез эшләп, халык сәламәтлеген саклауда һәм ныгытуда куйган хезмәтләре өчен берничә мәртәбә Татарстан АССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә һәм “I категорияле фельдшер” дигән дәрәҗәгә лаек була.

Шәмсия апа хәзерге вакытта лаеклы ялда. Рәхмәт, хөрмәтле Табибә апа! Тазалык-саулык сезгә.

Әйбәт апа

Кояш чыгып, бераз югарыга күтәрелүгә, авыл урамыннан җәйләүгә көтү кузгала. Аның артыннан ук дияр-лек, түбән очка таба йөгерә-атлый бер хатын-кыз ашыга. Кем ул, кая ашыга? Бу бит безнең интернатта тәрбияче булып эшләүче Мәүлидә апа Бәшәрова икән. Шулай көн дә ул иртән балалары янына ашыга.



Мәүлидә Бәшәрова 1933 елда Бәзәкә авылында туа. Мәктәп елларында тырышып укый, пөхтә, чиста, бик тыйнак кыз була. Мәктәпне 1950 елда тәмамлап, читтән торып Алабуга укытучылар институтының биология-география факультетында укый. Ул 3 нче курсны тәмамлаган елны, укытучылар институты бетерелеп, педагогия институтына әверелә, ә яңасында биология-география факультеты ачылмый. Мәүлидә кыен хәлдә кала. Алай да, озак уйлап тормастан, документларын Уфа укытучылар институтына җибәрә, әмма соңарып кына килгән хатта җавап катгый була: “4 нче курска студентлар алынмый”. Шулай итеп, соңгы курска килеп җиткәч, кыз-

га укуын төгәлләү мөмкинлеге калмый. Мәүлидә кулына “Незаконченное высшее” дигән кәгазь генә ала.

Алга таба ул Бәзәкә мәктәбендә урта классларда ботаника фәнен укыта, химия-физика лабораториясендә лаборант булып эшли.

60 нчы елларда Бәзәкә мәктәбе каршында чит авыллардан килеп укучы балалар өчен интернат ачыла. Биредә күрше-тирә авыллардан (Сәйтәк, Татар Тәкәше, Мари Тәкәше, Турай, Ахтиял, Песәй, Әтәс, Татар Сарсазы, Ташчишмә, Тойгужа, Тукай) килгән 50-60 бала яши. Интернатта урын җитмәгәч, балаларны квартираларга урнаштыралар. Шул чорда Мәүлидә Бәшәрова интернатта тәрбияче булып эшли башлый. Беренче көннәреннән үк ул интернат бүлмәләрен уңайлы итеп үзгәртеп кору, матур итеп җиһазландыру эшләрен яратып, зур теләк белән башкара, моңа балаларны да җәлеп итә. Тәрбияче Мәүлидә шуны аңлый: әти-әниләреннән атна буена аерылып торган балалар өчен интернатта өй шартлары булдыру, ягъни бүлмәләрнең матур бизәлеше, тиешле җылылык һәм яктылык булу, елмаеп озатучы һәм каршылаучы апалар – бала күңеленә менә нәрсәләр уңай тәэсир ясый. Шунлыктан, ул уку һәм яшәү өчен мөмкин бар уңайлылыкны булдыру максатында, иртәдән кичкә кадәр армый-талмый хезмәт куя.

Тәрбиячене иртә таңнан балалар янына ашыга, дидек. Чөнки һәрберсен җайлап уятырга, урын-җирне җыештыруларын, юынып, ашап-эчеп мәктәпкә китүләрен күзәтергә, оештырырга кирәк. “Дәфтәрем яки китабым калган”, – дип кире кайтмасыннар өчен, һәрберсен диярлек исемләп көн дә кисәтергә, исләренә төшерергә туры килә.

Көндезләрен тәрбияче-педагог кичәге көнгә анализ ясый: нәрсәгә ирешелде, нәрсә әлегә килеп чыкмады, сәбәпләре нилектән. Ә бүген кич ниләр башкарасы? Балаларны мәктәптән каршы алгач, ашап-эчеп бераз ял иткәннән соң, дәресләр әзерләү башлана. Белем алу, аны үзләштерү, истә калдыру дәрәҗәсе бар балага да тигез бирелми. Тәрбияче Мәүлидә һәрберсенә шәхси якын ки-



лергә, ярдәм күрсәтергә омтыла. Күпләренә үзе булыша, кайберләренә көчле укучыларны билгели. Нәтиҗәдә, теманы аңламадым, дип дәрескә әзерләнмичә калган укучылар булмый диярлек.

Дәресләргә әзерләнеп беткәч, һәр кичне нинди дә булса берәр тәрбияви чара үткәрелә: әдәп-әхлак темаларына әңгәмәләр, концерт, туган көннәр бәйрәме, танцылар, төрле уеннар оештырыла. Авыл клубына кино карарга культпоходлар ясыйлар.

Һәр баланы үз канаты астына алып, аларга җан җылысын бүләк иткәнгәдер, биредәге һәр бала тәрбиячене "әйбәт апа" дип атый, аңа тартыла. Күпләре әйбәт апага эч серләрен ачалар, аннан киңәш көтәләр. Бала нинди генә гозер белән мөрәҗәгать итсә дә, Мәүлидә Бәшәрова кулыннан килгәнчә ярдәм күрсәтергә әзер. Шуңа күрә интернатта яшәүче балалар әниләредәй игелекле, сабыр, ягымлы тәрбиячене чын күңелдән яраталар, хезмәттәшләре, ата-аналар хөрмәт итәләр.

Мәүлидә Бәшәрова байтак еллар җәй айларында балаларны мәктәпнең тәҗрибә участогында эшләтте. Биредә дә ул һәр балага ничек эшләргә кирәклекне башта үзе күрсәтеп, тиешле нәтиҗәгә тыныч кына аңлату юлы белән ирешә. Бакчада эшләүче балаларга үз өеннән пешереп коймак-кабартмалар алып килә, үлән чәйләре эчерә. Ә көзләрен бәрәңге, яшелчә ашлары пешереп ашата. Балалар, хезмәт көненең ничек үткәнен дә сизмичә, өйләренә канәгать булып кайталар. Ә аларны "Рәхмәт сезгә, балалар, иртәгә тагын барыгыз да килегез, яме" – дип озатып калган киң күңелле, олы йөрәкле остаз Мәүлидә Бәшәрова үзенең кемгәдер кирәк булуыннан зур канәгатьләнү хисе ала, аңында, йөрәгендә яшәү дәрте тагын да көчәя.


Мәүлидә апа 1988 елдан лаеклы ялда. Рәхмәт сезгә, кадерле Укытучы, әйбәт тәрбияче апа.



Яраткан мөгаллимебез

Алар, укытучы Гыйльмуллиннар гаиләсе, безнең авылга 1959 елда килделәр. Лена апа – рус теле һәм әдәбияты, Камил абый – география, тарих фәннәре укытучылары иде.

Камил абый энергияле, көчле ихтыярлы, талантлы укытучы иде. Шушы сыйфатлары өчендер, аны бик тиз арада мәктәп директоры итеп билгеләделәр.



Камил абый дәресләрен җанлы, кызыклы итеп үткәрә иде. Дәреслек материал белән генә чикләнмичә, төрле газета-журналлардан мисаллар китерә, алардан өзекләр укый һәм, иң кызыклы урында туктап, җавапны үзебезгә эзләргә, табарга, фикеребезне белдерергә куша. Гомумән, укытучыбыз үзенең дәресләрендә киләчәктә хыялланган һөнәрне үзләштерү өчен төпле белем кирәклекне безгә һәрдаим искәртеп, башыбызга, күңелебезгә сеңдереп килде. Үзе хәрәкәтчән, тынгысыз, янып торган кеше буларак, укучыларның пассивлыклары, сүлпәнлекләре белән килешми, киресенчә, активларны, кыюларны, чаяларны хуплый, өстен күрә иде.

Укытучы – белем бирүче дә, тәрбияче дә, иҗатчы да. Камил абый Гыйльмуллин, директор, парторг булуына карамастан, шәкертләре тормышы белән бер казанда кайнады. Смотр концертларына әзерләнгән чакларда, кичләрен ул безнең янга килеп, монтаж, сценарийлар төзергә, отышлы җыр-биюләр сайларга, үзенчәлекле чыгышлар уйлап табарга ярдәм итте. Смотр концертларына да килеп җитә, чыгышыбыз өчен җан атып, безне рухландырып тора, бару-кайту өчен техника мәсьәләсен дә хәл иткән була. Укытучыбыз үзе дә кичәләрне кызыклы итеп алып



бара иде: сүзгә, телгә осталыгы, һәр бәйрәмдә халык тулы клубта, мәктәптә үз шигырьләрен тәэсирле укуы әле бүген дә күз алдында.

Камил абый һәрвакыт ачык күңелле, гади, эчкерсез иде. Без, укучылар, аның бу сыйфатларын кайчак үз файдабызга кулланырга да батырчылык иттек. Менә бер мисал.

1962 ел. Мин 8 нче сыйныфка Чиләбе каласыннан (1-2 ел шунда укыган идем) кайтып төштем. Өстә шәһәрчә мәктәп формасы, аякта биек үкчәле туфлиләр, башта ул чорда модада булган прическа – өеп куелган чәч. Сыйныф җитәкчем Гаян апага бу ошамады: "Бу "чүмәләң" белән дәрескә килмә", – диде. Бер әйтте, ике... Ниһаять, апаның түземе бетте, ул мине дәрестән куып чыгарды. Миңа шул җитә калды: туп-туры директор янына кереп киттем.

Камил абый, эшеннән бүленеп, күтәрелеп миңа карады.

– Ни өчен дәрестә түгел?

– Гаян апа бу "чүмәләң" белән дәрескә кертмим диде.

– Чүмәлә?... Нинди чүмәлә?

Мин чәчемә күрсәттем. Директор бер мәлгә миңа арты белән борылды, мөгаен, елмаюын күрсәтергә теләмәгәндер инде.

– Ник килдең соң?

– Соң, абый, миңа шулай ошый. Мондый прическа хәзер модада бит. Минем кебек кыска буйлы кешене озынрак та итеп күрсәтә әле ул. Абый, шулай йөрергә рөхсәт итегез инде?

Директор бер мәлгә дәшми торды.

– Ошый дисең инде "чүмәләң"? Ярый, бар дәресеңә. Камил абый рөхсәт бирде, диген. Әмма бу модалар укуыңа зыян китермәсен. Аңладыңмы? Мәктәпнең иң актив укучысы булганың өчен генә рөхсәт бирәм.

Атылып чыгып чаптым. Класска кереп, җавапны тапшырдым. Гаян апа бер генә сүз әйтте: "Утыр!". Башка беркайчан да бу турыда сүз кузгатмады. "Чүмәлә" мәсьәләсе шулай хәл ителде.



Лена һәм Камил Гыйльмуллиннар. 1959 ел

Камил абый Гыйльмуллин минем язмышымда тагын бер бик мөһим роль уйнады.

...10 нчы сыйныфта укып йөрүем. Беркөн мине директор кабинетына чакырдылар. Камил абый утырырга кушты, сүз озын буласы.

– Менә нәрсә, сеңлем. Без сиңа бик җитди эш тапшырырга булдык әле. Авылда өч инвалид бала бар. Менә шуларны өйләренә барып укытырга кирәк. Бу эшне син башкарып чыга алырсың дип ышанабыз.

– Абы-ы-й, мин укытучы түгел бит, аларны ничек укытыйм?

– Беләм, холкың белән тик-тормас "кычыткан чыпчыгы" инде син. Тик монда җитдилек кирәк булачак. Күршеңдә башлангыч сыйныф укытучылары Зәйтүнә, Мәүлия апаларың бар, шулардан сораш, белеш, дәреслекләр, планнар ал. Иртәгә үк дәресләрдән соң укытырга керешерсең. Я, килештекме?

Мин беразга бер сүз дә әйтә алмый тордым.

– Я инде, бөтенләй куркып төшмә. Сиңа кадәр аларны Тәскирә Хуҗиәхмәтова да укытып алды. Аның да килеп чыкты, син дә булдырырсың. Кем белә, бәлки киләчәктә син чын укытучы булырсың. Монысы сиңа үзеңне сынап карау булыр. Ярый бар, хәерле сәгатьтә.

Шулай итеп, мин, чын укытучы сыман, балалар укытырга керештем. Рәшит Шакиров, Мансура һәм Мәхмүт Нәҗиповлар (инде өчесе дә мәрхүмнәр) минем беренче укучыларым булдылар. Аларны ике ел укыттым, чын педагогларча эш хакы алдым. Мәктәпне бетергәндә бераз стажым, хезмәт кенәгәм бар иде. Алдан эшләп килгән булгач, институтта укыган 5 ел да стажга керде. Менә шу-



лай итеп, мәктәптә үк укытучылык эшен алып бару миңа киләчәктә чын педагог булырга зур ярдәм һәм этәргеч ясады. Моның өчен мин Камил абыйга чиксез рәхмәтле булдым.

Камил абый Гыйльмуллин иҗат кешесе иде. Район һәм республика газеталарына шигырьләр, хикәяләр, юморескалар, күпләгән мәкаләләр язды (хәзер дә яза, укып-белеп торабыз). Һәрчак ачык йөзле, шаян сүзле, җор телле һәм күтәренке күңелле оптимист мөгаллим мәктәп коллективы, укучылар алдында зур абруй казанды.

Гыйльмуллинар гаиләсе безнең авылга ничек көтмәгәндә килгән булса, шулай кинәт кенә китеп тә барды. Бу 1965 ел иде (киләсе елда безнең чыгарылыш буласы). Безнең мәктәп тәмамлаганны да көтмичә китеп барулары на моңаеп та, бераз үпкәләп тә йөргән идек. Без мәктәпне бетергән 1966 елны сыйныфыбыз өчен чыгарылыш кичәсе уздырмадылар. Ни өчен, нилектән – моны төгәл белә алмадык (төрле имеш-мимешләр булды булуын). Камил абый булса, бу хәл булмас иде, ул барыбер үткәрү юлларын табар иде, дигән үкенечле уй озак еллар күңелләребезне әрнетеп йөрде.

Ә тиздән Камил абыйның гаиләсе белән Түбән Кама каласында урнашуын, аның үз һөнәре буенча эшен дәвам итүен белдек. Аннары күп еллар буенча без аны, артист-юморист буларак, "Мунча ташын"нда күрү бәхетенә ирештек. Рәхмәт сезгә, кадерле Укытучы. Сау-сәламәт булыгыз, озын, рәхәт гомер кичерегез.

P.S. Бу истәлек геройларының фотосурәтләре миндә булмаганлыктан, Камил абыйның өлкән кызы Илсөярнең телефон номерын көч-хәл белән табып, аңа шалтыраттым, җибәрә калса, почта аша җибәрергә куштым. Шул сөйләшүдән соң ике көн дә узмады, Камил абый безгә үзе килеп керде. 80 яшьтән узган укытучымның өлгерлегенә, тәвәккәллегенә шаккаттым. Абый белән озак сөйләштек, хатирәләр яңарттык. Ул безгә "Тормышым чаткылары" дигән яңа китабын бүләк итте. Балалар өчен 3-4 китабы дөнья күргән икән. Күп кенә шигырьләре рус телендә

укучы татар балалары өчен дәреслекләргә кертелгәннәр. Афәрин, Укытучым!

Күбәләктәй саф күңел...

Лена апа Гыйльмуллина рус теле һәм әдәбиятын укытты. Дөрес, ул безнең сыйныфта укытмады, шуңа күрә аның дәрес бирү рәвеше һәм методик осталыгы турында берни дә әйтә алмыйм. Әмма мәктәптә, урамда күреп, без аңа соклана идек. Кеше белән сөйләшкәндә гел елмаеп, яктырып торучы апа иде ул. Аның эчкерсез, садә җан булуы бөтен кыяфәтеннән, буй-сыныннан үтәли күренә сыман. Мәктәпкә, дәресләргә ул бәйрәмгә килгән кебек шатланып, бик килешле итеп киенеп килә иде.

Үзенә генә хас сөйкемлелеге, тыйнаклыгы белән күбәләктәй саф күңелле зат булып истә калды Лена апа безнең йөрәкләрдә.



Лена апа җәмәгать эшләрендә дә актив катнашты: концерт, спектакльләр куйганда, сәхнәдә аны еш күрә идек. Бер концерт бик тә истә калды. Ничәнчедер Яңа елны каршылау концерты иде ул. Менә сәхнәгә Лена һәм Мәүлия апалар биергә чыкты. Икесе дә кап-кара (?) крахмалланган марля күлмәкләрдән. Алар җиңел генә биеп киттеләр, төрле хәрәкәтләр ясап, сәхнәне әйләнделәр. Кинәт клубта ут сүнде. Нәрсә бу, ни булды? Шулчак, караңгылыкны яктыртып, сәхнәдә генә утлар җемелдәде. Бик кеченә лампочкалардан сирпелгән яктылык, биючеләрнең нефть вышкалары формасында тегелгән күлмәкләрендә кабынган икән бит. Менә әкәмәт! Утлар бер яналар, бер сүнәләр, ә апалар биюләрен дәвам



итәләр. Бар халык, авыз ачып, хәйран калды.

Моның кадәр катлаулы конструкцияне физигыбыз Фоат абый ул символик вышка-күлмәкләр буйлап сузылган чыбыкларда уралып-чуалып бетмичә, иркенләп биерлек тә, дистәләгән лампочкаларны кирәк чакта гына яна һәм сүнә торган итеп тә ничекләр урнаштырган, көйләгән – чын табышмак! (Афәрин, Фоат абый!). Безгә бик ошаган иде ул хикмәтле маскарад костюмнары. Әле бит шул елларда авылыбыз янында гына нефть чыгара башлаганнар иде. Менә бит, укытучыларыбыз шул чорны костюмнарда ничек оста чагылдыра белгәннәр һәм биюче апалар нинди матур да, оригиналь да номер әзерләгәннәр!

Лена апа ире Камил абый белән өч бала үстерәләр. Кызганыч, укытучы апага балаларының үсеп җитеп гаилә коруларын, оныкларын күрү насыйп булмаган. Ул яшьли гүр иясе булган. Урыны җәннәттә булсын.

Шул елларда (1970 еллар булырга тиеш) Камил абыйның яшьлек мәхәббәте булган хатыны вафатына багышлап язылган шигыре район газетасында басылып чыккан иде. Миндә ул шигырь бүгенгәчә саклана. Автор, Себернең гүзәл Лена елгасы образына мөрәҗәгать итеп, аның аша сөеклесе Ленага дәшә, аңа күңел җылысын, кайнар хисләрен, мәхәббәтен бүләк итә, киләчәктә, чиксез мәңгелектә очрашу насыйбына ишарә ясый. Бу шигырьнең эчтәлеген мин шәхсән нәкъ шулай кабул иттем.

Бу шигъри юлларны кабат искә төшереп үтү – Лена апа рухына дога булып ирешсен. Амин.

Лена

Агып чыга, ургып ага
Байкал тау кырларыннан.
Дулкыннары җыр отканнар
Бабамнар моңнарыннан.
Лена!
Күңел хисем сиңа!
Лена!

Ак балыктай уйный-уйный
Суларында коендым.
Сихәт бирдең. Идел-әнкәм
Сыман миңа тоелдың.
Лена!
Йөрәк җырым сиңа!
Лена!

Котып диңгезләренә син
Җан җылысы бирәсең.
Үзең зифа, суың шифа,
Һай, күз генә тимәсен.
Лена!
Күңел җылым сиңа!
Лена!

Ярларында карагайлар,
Әйтерсең, яшел келәм.
Килер вакыт, очрашырсың
Идел егете белән.

Кыя таулар, мәрмәр ярлар,
Сине иркәләп кала.
Мин бит бер Идел егете,
Сагынам. Ерак ара.
Лена!
Йөрәк җылым сиңа!
Лена!

Лена!
Мәхәббәтем сиңа!
Лена!
Лена!

Балалар бакчасы тәрбиячеләре

Сабый балаларга дөньяны танып белүдә, укырга керү өчен иң әүвәлге әзерлек һәм тәрбия күнекмәләре бирүдә үзләреннән зур көч куйган, шушы балаларны һәр ел саен 1 сентябрьдә мәктәпкә озаткан балалар бакчасы тәрбиячеләрен атап китмәү һич мөмкин түгел. Гомер буе бары бер һөнәргә – сабыйлар тәрбияләүгә тугры калып, нәниләрнең беренче укытучылары булган тәрбиячеләребез олы хөрмәткә лаек затлар. Алар: Сабирова Оркыя, Зиннәтуллина Минямал, Хаснуллина Гайшә, Гафарова Гөлфания (30 еллап балалар бакчасында эшләп, I категорияле методист-тәр-





Сулдан: Хаснуллина Г., Зиннәтуллина М., Гафарова Г.

бияче дигән мактаулы исемгә лаек булды), Кәлимуллина Газизә, Галимова Сәрия, Бәшәрова Хамисә, Гыйльфанова Фәния һәм башкалар. Ихлас күңелдән рәхмәт сезгә.

Хөрмәтле тәрбиячеләр!

Нәни йөрәкләргә күпме
Җылылык өләшәсез.
Бары тик яхшы гадәтләр
Аларга өйрәтәсез.
Сездән күчкән назлы караш,
Сез әйткән изге теләк.
Озата барсын мәктәпкә
Уңышлы уку теләп.
Сезнең борчу, кайгыртулар,
Зур көч түгүегез дә
Изгелек булып мең кабат
Кайтсыннар үзегезгә.

Тынгысыз эшсөярләр

Танылган кинорежиссер Станиславский: “Театр чишенү бүлмәсеннән башлана”, дигән. Ә мәктәпнең йөзе аның һәрчак җыештырулы, чиста ишегалды, зал һәм бүлмәләреннән башлана.

Бу чисталыкны, җыйнаклыкны һәм пөхтәлекне тырыш, өлгер, житез җыештыручы апалар булдыра иделәр. Аларның исемнәрен баштан ук атап китим әле: Әхмәстинова Баян, Гайнуллина Миневафа, Гыймазетдинова Мәрьям, Гыймадиева Мөгаллинур, Бәшәрова Кадерниса, Шәехова Миниса, Халикова Нәҗия, Миннәхмәтова Рәхимә, Шәрәфиева Нәгыймә, Шәфигуллина Галимә, Хөрмәтуллина Разия, Габдуллина Асия (аш пешерүче), Сабитова Гөлҗинан (интернатта төнлә кунучы), Зәйнетдинова Сабира һәм башкалар.



Сулдан: Гыймадиева Мөгаллинур, Миннәхмәтова Рәхимә, Шәехова Миниса апалар

Җыештыручы апаларыбыз мәктәп идәннәрен юарга суны баштарак инештән, эчәргә чишмәдән көянтә-чиләк белән ташыганнар (соңрак мәктәп аты белән олы мичкәдә алып кайта башладылар). Алар идәннәрне көн саен ком белән ышкып юганнар (алга таба ул идәннәр буялган). Әле дә хәтерлим: һәр классның мичләрен кардан ак итеп агарта иделәр. Көн саен ул мичләрне иртәнге 4 тән килеп яктылар, ис булмасын өчен, яныннан китмичә, кисәүләрнең янып беткәнен көттеләр. Утынны үзләре үк әзерләделәр: җәйдән үк, укытучылар белән чиратлашып, урманда кул пычкысы белән кистеләр (мәктәпләр өчен утынны авыл советы соңыннан гына кайтарта башлады). Кайткан утынны мичкә сыярлык итеп кабат кистеләр (бу эштә, без, укучылар да катнаша идек). Көн саен лампа-куыкларны





Сулдан: Гыймазетдинова Мәрьям, Гайнуллина Миневафа, Габдуллина Асыя апалар

тазартып, чистартып тордылар. Кышын мәктәпнең бик зур ишегалды карын көрәделәр. Һәр дәрес беткән саен җиз кыңгырауны башта залда, аннары ишегалдында кулдан шалтырата иделәр. Эх, ул кыңгырау чыңнары...

Әле бездә бер матур традиция бар иде: кышкы зәһәр салкыннарда мәктәп түбәсенә кызыл флаг эләләр (моны да дежур укытучы яки техничка эшли). Ул – үзенә күрә кисәтү сигналы, коткаручы маяк ролен үтәүче гамәл

иде. Ягъни, 25^0-30^0 салкын икән – укучылар, бүген укымыйсыз, дигән сүз. Шул флагны күреп, әй шатлана, сөенә идек инде! Мәктәпкә барырга дип чыккан юлыбыздан - Ура! - кычкырып, кире өйләребезгә чаба идек.

Тәнәфесләрдә буфетчы Камал апабыз (соңрак Шиабиева Хәдичә апа) безне авыл пекарнясында пешкән йомшак ак калач һәм чәй белән сыйладылар. Бер стакан чәй белән бер тулы телем итеп киселгән ипи кисәкләре буфет өстәленә тезелеп куела, шуны чираттан килеп аласың. Бер тавыш, этеш-төртеш юк.



Буфетчы Камал апа Нуриева

Җәй айларында күрше рус авылы (безнең колхозга керә иде) Ык Тамагы мәктәбендә оештырылган пионер лагеренда ял итә идек. Биредә дә безнең белән техничка апаларыбыз булдылар. Алар тәмле ашлар пешерделәр, бүлмәләрне, урын-җир әйберләрен чиста, пөхтә тоттылар. Өйгә кайтасы килеп, сагынып-моңаеп китсәк тә, апаларыбыз безне юатып, күңелләребезне күтәрергә тырыштылар.



Бәшәрова Кадерниса апа

Мәктәбебездә хуҗалык җитәкчеләре (завхоз) Нуриев Мулланур, Мөхәммәтдинов Миннәхмәт, Сабитов Хәмәт абыйлар тырышып эшләделәр. Алар мәктәп өчен кирәк-яракны үз вакытында алып кайтып тордылар. Керосин, куык, чиләк, көрәк, акбур һәм башка кирәкле әйберләргә беркайчан да өзеклек һәм кытлык булмады.

Менә шушындый абыйларыбыз һәм техничка апаларыбыз безне якты-җылы, чиста-пөхтә мәктәптә укыту, сау-сәламәт булуыбыз өчен үзләреннән зур тырышлык куйдылар, намуслы хезмәт иттеләр.

Рәхмәт сезгә, чисталык сагында торучы тынгысыз эшсөярләр!

Кадерле мөгаллимнәр, тәрбиячеләр

Сез һәммәгез дә чиста, якты күңелле затлар идегез, гадилек һәм гаделлек үрнәкләре. Бездән соң балалар күңелендә, кешеләр хәтерендә якты эз, матур хатирәләр генә калсын дип эшләдегез, яшәдегез.

Безгә, матур хыялларга төренеп, киләчәккә зур планнар корып, язмышыбызга якты өметләр баглап укыган һәм яшәгән егет-кызларга, сез киң күңеллелекнең, тормышны, кешеләрне яратуның иң зур үрнәген күрсәткән асыл затларыбыз булдыгыз.

Озак еллар буенча һәркайда тыйнак, ипле-әдәпле булып, мораль кысаларына сыймаслык гамәлләр кылмыйча, төрле гайбәт, имеш-мимешләргә бернинди җирлек тудырмыйча, төп миссиягезгә тугры калдыгыз: балаларга ныклы белем бирдегез, югары әхлак сыйфатлары тәрбияләдегез.

Бер йодрык булып тупланган зур коллективта дус, тату гаиләдәй яшәдегез. Менә нәкъ шуның өчен укучыларыгыз, ата-аналар, авыл һәм район халкы алдында зур абруйлы, мәртәбәле һәм мактаулы булдыгыз. Афәрин!

Бүгенге көндә Сез – энҗе бөртекләре кебек кенә калган шәхесләребез. Инде барыгыз диярлек 80 яшьне уздыгыз. Әмма сезгә "әби", "бабай" дип дәшәргә тел, язарга каләм бармый. Сез безнең өчен иң матурлар идегез, эшегез, хисләрегез, эчке дөньягыз белән матурлар. Әле бүген дә сез шундый ук матур, гүзәл, безне укыткан чордагыча, нәкъ 18 яшьтә кебек... (киресенчә укысаң, билгеле). Күңелләребездә дә мәңге шундый булып калырсыз...



***

Шушы урында Бәзәкә мәктәбендә төрле елларда, төрле вакыт дәвамында эшләгән, алда исемнәре әйтелмәгән укытучыларыбызны атап китәсем, аларга рәхмәт әйтәсем килә.

Сугыштан соңгы елларда эшләделәр:

Зиннәтуллина Минегаян (башлангыч сыйныфлар)
Шакиров Галимҗан (тарих)

60 нчы еллардан:

Фәтхуллин Зиннур (авыл хуҗалыгы фәне),
Әхмәрова Бәдәр (интернат тәрбиячесе),
Төхвәтуллин Зиннур (математика),
Хәсәнова Сабира (рус теле),
Ибәтуллина Шәмсия (рус теле һәм әдәбияты). Укучыларны җыя, тыя, туплый белде. Үз фәненең остасы булды, көчле, белемле укучылар чыгарды.
Латыйпова Һәвия (татар теле),
Шакирова Сания (китапханәче),
Шәймөхәмәтов Әхәт (авыл хуҗалыгы, трактор),
Шагина Әнисә (рус теле һәм әдәбияты),
Гайнетдинова Әдибә (биология),
Гыйльфанов Зиннур (математика). Таләпчән директор, көчле укытучы булды. Бәзәкә мәктәбендә балалар иң күп укыган чорда эшләде, коллективта ныклы тәртип булдырды.
Гыймазетдинова Мәүлиха (башлангыч),
Ахунов Шәрифҗан (физкультура, хезмәт),
Җиһаншин Габделхәй (авыл хуҗалыгы),
Сабитова Роза (рус теле).

Рәхмәт Сезгә, кадерле укытучылар! Һәркайсыгыз олы ихтирамга, гомум игътибарга, чиксез рәхмәтләргә лаек.

Укытучым

Яшәгән һәр көнең, эшләгән һәр эшең
Сызылыр якты бер нур булып.
Сайлаган юлыңа гомерең буена
Рәхмәтләр өелсен тау булып.

Шушы шигырь юлларына кушылып, сыйныфташым Әнвәр Зиннәтуллинның сезгә адресланган җылы сүзләрен җиткерәсем килә. Бу шигырен ул мәктәп бетерүебезгә 40 ел узганнан соң очрашу тантанасына багышлаган иде.

40 елдан соң очрашу

Нәкъ 40 ел үткәч очраштылар
Егерменче гасыр балалары.
“Әби-Бабай”, – диеп арттан йөри
Балалардан туган балалары.

Картаелган, чәчкә бәсләр кунган,
Бер-беребезне көчкә таныйбыз.
Таныйбыз да, гөрләп көлешәбез,
Әйтерсең лә, егет-кыз чагыбыз

Сыйныфташлар!
Искә алыйк әле яшь чакларны,
Бер бушатыйк әле җаннарны.
Мәңлеккә киткәннәрне барлыйк,
Зурлап искә алыйк аларны.

Үлгәннәрнең каберен белү кирәк,
Исәннәрнең кадерен белик без!!!
Укытучы абый-апаларга
Йөрәкләрдән чыккан шушы сүз:

Рәхмәт сезгә!
Кадер сезгә!
Хөрмәт сезгә!

Алмаш буын

70 нче еллар башында көч-энергияләре ташып торган бер төркем яшьләр, язгы ташкын кебек ургылып, Бәзәкә мәктәбенә кайтып төштеләр, өлкән гвардиядән буыннар эстафетасын үз кулларына алдылар, мәктәп тормышына яңа сулыш өрделәр.

Болар: Бәшәрова Әлфия, Гобәйдуллина Галия (татар теленнән күп призерлар чыгарды), Низаметдинова Мәрьям (минем якын күршем, 30 еллап бергә эшләдек, бик тырыш, үз эшенә карата үтә җаваплы, җитди, тырыш мөгаллимә), Хөрмәтуллин Нурфаез, Мәхмүтова Әнисә, Гыймазов Дамир, Сиражетдинова Җәмилә, Мөхетдинова Рәмзия, Әхмәтҗанова Саяра, Хәбирә һәм Фәрит Насыйфуллиннар, Таҗиев Сәлахетдин, Сабитов Мехәмәтнур, Иванова Галина, Бикмурзина Илдия. Соңрак, 80 нче елларда, мәктәпкә бүгенге укытучылар: Шакирова Гүзәл, Гыймадиева Нурания, Мулланурова Халидә, Кәлимуллина Равилә, Миннибаев Илдар, Ефимова Лилия, Вахитова Раушания һәм башкалар килде.





Гыйльфанов Зиннур, Гыймазов Дамир, Гыймазова Шәмсия – ул еллардагы мәктәп җитәкчелеге

Яшь егетләр һәм кызлар, үзләрен укыткан өлкән буын педагоглар кебек, институтта алган белемнәрен укыту-тәрбия процесында киң кулланып, яңача алымнар, заманча ысул-

лар белән җиң сызганып мөгаллимлек эшенә керештеләр. 70-90 нчы еллар дәвамында директорлар булган Гыйльфанов Зиннур, Гыйльфанов Хәй, Әһлиев Зәйнак, Гыймазов Дамир, Гыймазова Шәмсия (мәктәптә 30 елга якын тәрбия эшләре мөдире булды, Алабуга, Менделеевск, Әгерҗе районнары арасында СССРның бердәнбер халык мәгарифе отличнигы) җитәкчелегендә Бәзәкә мәктәбенең исемен яңа үрләргә менгереп, үз эшләренең чын осталары булдылар, зур уңышларга һәм җиңүләргә ирештеләр.





Бәзәкә мәктәбендә озак еллар эшләгән алдынгы укытучылар: Низаметдинова Мәрьям, Сабитов Мехәмәтнур, Гобайдуллина Галия

Ихлас күңелдән рәхмәт Сезгә!
Хөрмәтле укытучылар!

Кешелекле, ярдәмчел һәм гадел,
Чишмәдәй саф, садә күңелле.
Яшен булып яшьнәп, күкрәп яшәп,
Уздыгыз сез гомер-мизгелне.

Сезгә карап сокланабыз һәрчак,
Күңелләрдә туа горурлык.
Рәхмәт Сезгә! Әле ярый сез бар
Безгә өлге булып торырлык.

Мөгаллим-остазларыбыз!

Мәктәпнең төрле еллардагы укучылары сезне кайнар хисләр, җылы сүзләр белән озак вакытлар йөрәк түрләрендә саклар әле. Саклар...


А Югары
булак
идәре
Я

Атказанган укытучылар

Бәзәкә мәктәбенең данын еракларга җибәргән укытучыларны ничек мактамыйсың да, алар белән ничек горурланмыйсың?!

Мәктәбебездә дүрт укытучы – "Татарстанның атказанган укытучысы" дигән югары исемгә лаек булды. Менә алар: Гыйльфанов Хәй Гыйльфан улы (1963 ел), Бәшәров Рәшит Госман улы (1966 ел), Мәхмүтова Нәҗия Хаҗи кызы (1967 ел), бүгенге укытучылардан Сабитов Мехәмәтнур Гәрәй улы (2007 ел).

Мәгариф алдынгылары

Ун укытучы "Халык мәгарифе отличнигы" дигән мактаулы исем йөртәләр: Көләчев Фоат Гатаулла улы, Мәхмүтова Нәҗия Хаҗи кызы, Бәдертдинова Әминә Бәдертдин кызы, Таҗиев Мулланур Минһаҗ улы, Галимуллина Мәүлидә Галимулла кызы, Әһлиев Зәйнак Әһли улы, Ибраева Әдия Сәлим кызы, Салихова Фирая Хаҗи кызы, Гыйльфанов Зиннур Нуриәхмәт улы, Гыймазова Шәмсия Гали кызы.

Мөхетдинова Рәмзия Гәрәй кызы һәм Гыймазов Дамир Гарифҗан улы – "Россия Федерциясенең гомумбелем бирү өлкәсендәге шәрәфле (почетлы) хезмәткәре" дигән күкрәк билгесенә лаек булдылар (2004 ел).

Миннибаев Илдар Нурулла улы – Татарстан Республикасының "Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен" дигән күкрәк билгесе белән бүләкләнде (2008 ел).

"Иң-иң"нәр

Бәзәкә мәктәбе укытучыларының балалар зиһененә, күңеленә чәчкән белем һәм тәрбия орлыклары тиздән мул уңыш биргәннәр. Менә шул уңышның "җимеш"ләрен барлап-санап үтик әле.



Укучыларга бик яхшы укыганнары өчен медальләр бирелә башлаган вакыттан алып 20 нче гасырның соңгы елы булган 2000 нче елны кертеп исәпләсәк, мәктәбебезне 35 ләп укучы алтын һәм көмеш медальләргә тәмамлаган. Беренче көмеш медаль Мансур Нәбиуллинга бирелгән (1962 ел), беренче алтын медальне Гөлшат Хуҗиәхмәтова алган (1972 ел).

Галимнәребез

Бәзәкә мәктәбен тәмамлаган шәкертләр арасыннан дистәгә якын галим кешеләр чыкты.

– Нәбиуллин Мансур Кәрим улы – физика-математика фәннәре докторы, профессор, академик.

– Тажиев Рифкать Минһаж улы – хирург-онколог, профессор, Петербургның фән һәм сәнгать академиясе әгъза-корреспонденты. (Сүз уңаенда өстәп китим: онколог Тажиев Әлфия апа Авзаловага бик җитди операция ясап, мәшһүр җырчыбызның гомерен һәм кабатланмас тавышын саклап калган шәхес).

– Мәхмүтова Альта Хаҗи кызы – Казан дәүләт университетының татар халкы тарихы кафедрасы доценты.

– Апалы-энеле бертуган Мансура һәм Мансур Әхмәтовларны “Мәскәү галимнәре” дип атарга була. Алар Мәскәүдә яшәп эшләделәр: Мансура апа – СССР педагогия фәннәре кандидаты, Мансур абый – техник фәннәр кандидаты иделәр.

– Тажиев Сәлахетдин Фәрдетдин улы – Алабуга педагогия институты доценты, педагогия фәннәре кандидаты.

– Нәҗметдинова Мөнирә Зәки кызы – Чаллы пединституты доценты, педагогия фәннәре кандидаты, чит телләр кафедрасы мөдире.

– Мәктәпне 2000 елда бетергән Булат Илдар улы Миннибаев сигезенче фән кандидаты булырга әзерләнә, тарих фәннәре буенча диссертация өстендә эшли. Уңышлар телик булачак яшь галимгә!

Атказанган исемендәгеләр

Татарстанның атказанган укытучысы исемен йөртүче һәм гап-гади мөгаллимнәребездә белем алган укучыларның дистәдән артыгы инде үзләре атказанган кешеләр булдылар.

– Гыйльфанов Мөхәммәтнур, Азин Нуриәхмәт, Нуриев Миневәҗит, Тарасова Зоя – Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре;

– Фәттахов Мәүҗит – Татарстанның атказанган драма артисты;

– Таҗиев Рифкать – ике мәртәбә атказанган шәхес: ТРның атказанган табибы, ТРның атказанган фән эшлеклесе;

– Нәҗметдинов Сәетнур – ТРның атказанган табибы;

– Әхмәтҗанов Мулламехәмәт – ТРның атказанган нефтьчесе;

– Гыймадиев Зөфәр – ТРның атказанган автотранспорт хезмәткәре;

– Гыймадиев Мөнәвир – ТРның атказанган төзүчесе. Заманча йортлар салу остасы, Чаллы шәһәрендә "Трест-подряд" төзү оешмасының генераль директоры. Эше күп, вакыты тар булуга карамастан, ул туган авылында еш була, һәр яңалык, үзгәреш, борчу-мәшәкатьләр турында хәбәрдар. Кирәк булса, җитәкче якташ ярдәм күрсәтергә дә әзер. Берничә ел элек мәчетебезгә яңа янкорма төзетте. Мәктәп укучыларына да ярдәм кулы суза: төрле спорт һәм хәрби хәзерлек ярышларына да ул – юмарт спонсор, үзен укыткан һәм яшь укытучыларны да мул бүләкләүче. Шәфкатьле гамәлләреңә өчен зур рәхмәт сиңа, киң күңелле авылдаш.

– Зиннәтуллин Раил – Песәй егете, Бәзәкә мәктәбен 1968 елда бетерә, РСФСРның атказанган зоотехнигы, Перьмдә нәселле атлар үрчетү һәм аларны чит илләргә сату буенча нәтиҗәле хезмәт куйган белгеч;

– Садыйков Раяф – ТРның атказанган химигы, РФның шәрәфле (почетлы) химигы;

– Кәлимуллин Рәшит – ТРның атказанган машина төзүчесе;



Погонлы якташлар

Чыгарылыш укучыларыбыз арасында хәрбиләр дә аз түгел.

Мәхмүтов Сәетшәриф – подполковник дәрәҗәсендә отставкага чыкты, Санкт-Петербургта яшәде (инде мәрхүм, урыны җәннәттә булсын).

Фәтхуллин Габденур – Ульяновск хәрби училищесын тәмамлап, майор булды, Пермь шәһәрендә яшәде.

Гыймадиев Равил – полковник, Мәскәүдә яши.

Шакиров Рәфиснур, Шәфигуллин Фәрит, Габдрахманов Сәетнур – Байконурда, БАМ төзелешендә, төрле хәрби объектларда хезмәт куйдылар.

Зиннәтуллин Фәрит (Турай егете, Бәзәкә мәктәбенең 1976 елгы чыгарылыш укучысы) – контрадмирал, Төньяк Флоты су асты көймәләре флотилиясе командующие урынбасары.

Прокурор, подполковник Хуҗиәхмәтова Гөлшат Фәрахетдин кызы Чаллы прокуратурасында эшләде, лаеклы ялда булуына карамастан, бүгенге көндә дә хезмәтен дәвам итә.

Исмәгыйлов Рәшит, Сиражетдинов Вагыйз – подполковник дәрәҗәсендәге хәрбиләр.

Зиннәтуллина Гөлшат – Алабуга пединститутын бетерде. Соңрак Түбән Новгородның юридик академиясен кызыл дипломга тәмамлап, хәзерге вакытта Чаллы эчке эшләр бүлегендә хезмәт куя, майор.

Мөхетдинов Айдар Рәфис улы – Алабуга пединститутының техфагын бетерде. Соңыннан Екатеринбургның янгынга каршы көрәш академиясен тәмамлап, хәзер Кама буе нефть идарәсенең 26 нчы янгын сүндерү бүлегендә эшли, капитан.

Шәрәфетдинов Ленар Сәетҗан улы – Алабуга пединститутының техфагын тәмамлый, хәзерге вакытта холык төзәтү колониясендә эшли, майор.

Ибәтуллин Илшат – Алабуга милиция мәктәбен тәмамлап, Менделеевск эчке эшләр бүлегендә эшли, майор.

Сәхнә осталары



1960-90 нчы еллар дәвамында сәхнәләрдән, зәңгәр экраннардан үзенең оста уйнавы, кабатланмас образлар иҗат итүе белән халыкка рухи азык, күңелле ял, ләззәт һәм канәгатьлек хисләре бүләк иткән укучыбыз – Минзәлә дәүләт драма театрында күп еллар артист һәм режиссер булып фидакарь хезмәт куйган, шул театрның йөзек кашы булган ТРның атказанган артисты Мәүҗит Фәттахов (Турай егете) яраткан һөнәренә, зур тормышка безнең укытучылар фатыйхасы белән юллама алган шәхес.

***

Үз абыем Әнвәр Гәрәй улы Гыймазетдинов турында да бер-ике сүз әйтеп китәсем килә. Ул да Бәзәкә мәктәбендә 7 класс укып китеп, Чиләбе каласында төпләнеп яшәде һәм гомерен сәнгатькә, мәдәнияткә багышлады, баш-аягы белән сәхнә тормышына чумды, 60 нчы елдан башлап 2000 елга кадәр Урал якларында татар-башкорт халкына армый-талмый хезмәт куйды. Аның оештыру сәләте ифрат зур булды. Үзе көчле тавыш белән җырлый, искитмәле матур һәм оста бии иде. "Айгөл" исемендәге татар-башкорт халык ансамбле төзеп, шул коллектив белән Чиләбе каласында, Курган, Оренбург өлкәләрендә, башкорт авылларында даими чыгышлар ясыйлар алар. Өлкә комитетыннан мең бәлаләр белән ансамбленә автобус юллап ала, костюмнар булдыру хәстәрлеген күрә.

Соңгы 10-15 елда Әнвәр Гыймазетдинов Чиләбе трактор заводы театрында эшләде. Туган илләрен һәм мәдәниятен, милләтләрен онытмасыннар, бер дин балалары икәнлекләрен аңлап, тоеп яшәсеннәр өчен Бәзәкә егете татар-баш-



Чиләбе каласы. Чираттагы концерт вакыты. 1980 ел

корт һәм башка мөселман яшьләрен бергә туплау, җыю максатыннан: “Танышыйк-дуслашыйк”, “Чәйханә”, өлкәннәр, ялгызлар өчен “30, 40 яшьтән узганнарга” һәм башка исемдәге музыкаль, тематик кичәләр оештыра. Моның өчен байтак шелтәләр, кыенлыклар ала (үзегез аңлыйсыздыр, кайда да татарларның бергәләп җыелуы, активлашуы түрә абзыйларга тынгы бирми, эчләрен пошыра). Әмма Әнвәр Гәрәй улы бирешә торганнардан булмый: ул гадел, туры сүзле, башлаганын җиренә җиткерә. Киртә-каршылыкларны җиңә-җиңә, башлаган эшен кыю һәм үҗәтлек белән даими дәвам итә, коллективы белән яңадан-яңа үрләр яулый. Ләкин адәм баласы тимер түгел. Шулай кеше хәле, дөнья гаме белән янып-көеп, үзен аямыйча эшләү үзенекен итә – 63 яшендә, эш урынында, яшь егетләр һәм кызлар арасында (соңгы юлга озатырга баргач үзем белештем, ул көнне дә чираттагы чарасына 800 гә якын билет сатылган булган) аның йөрәге кинәт тибүдән туктый. Театр бинасыннан аны соңгы юлга озатырга меңләгән милләттәшләр килгән иде.

Татар милләте һәм минем хакка кылган игелекләре өчен абыема мең рәхмәтләр яусын, аның турындагы бу сүзләрем, истәлекләрем рухына изге дога булып иреш-сен. Амин. Шулай ук аның тыйнак, ягымлы, ярдәмчел тормыш иптәше Земфира апага (ул җиңгәм генә түгел, остазым да әле, «чүмәлә» прическаларны ясарга миңа ул өйрәтте) һәм балаларына зур рәхмәтле һәм хөрмәтлемен.

***

Сәхнә осталары турында сүзне төгәлләгәндә, шуны искәртәсе килә: Бәзәкә мәктәбендә укучыларны сүз сән-

гате буенча сәхнәгә әзерләү элек-электән үк бик көчле булды. Шуңадыр, без теләсә нинди залларда, аудиторияләрдә дә югалып калмыйча, уй-фикерләребезне нык, ышанычлы, төгәл, йөрәккә үтеп керешле итеп сөйли, тыңлаучыга җиткерә белдек. Сүз осталары Шәргыя апа Ибәтуллина, Нажия апа Җамалетдинова, Мәүлидә апа Исмәгыйлова, Сәлахи Таҗиев, Мөхәмәтнур Сабитовлар сөйләгәндә онытылып тыңлыйсың, күңелеңдә рәхәтлек тоясың. Аларның көчле, ачык, аһәңле тавышлары сине дулкынландыра, әсәрләндерә, җанда тойгылы кичерешләр уята. Ә бит матур, сәнгатьле уку оеткысын безнең күңелләргә гап-гади кешеләр: шул ук тәрбияче Зиннәтуллина Минямал апа, пионервожатый Әдия апа, башлангыч һәм татар, рус теле укытучылары салган. Аларга рәхмәт дими, нәрсә диясең!

Рәссам кулында — бар җиһан...

Сәнгать кешеләре турында сүз алгач, аның турында сөйләми, исемен атамый китү мөмкин булмаган авылдашыбыз бар. Бигрәкләр дә хисле, табигатькә, аның матурлыгына, хозурлыгына мөкиббән киткән зат – ул җирле рәссамыбыз Фәрахетдин Хуҗиәхмәтов. Бәзәкә мәктәбендә белем ала, кечкенәдән үк рәсем ясарга һәвәс була. Төрле стена газеталары, белдерүләр язуда, “яшен”нәр чыгаруда укытучыларының уң кулы була ул. Фәрахи абый үзенә буяулар, төсләр танырга өйрәткән, рәсем ясау серләренә төшендергән, шул ераста калган елларда ук сәләтле шәкертенә сәнгать дөньясына дөрес юл сайлауда маяк кебек үрнәк булган искитмәле оста, матур ясаучы рәсем укытучысы Кәшбиев Тимерхан абыйсын әле бүген дә җылы һәм рәхмәтле хисләр белән искә ала.

Рәсем ясауда Фәрахи абыйның яраткан “почмагы” – табигать, пейзаж. Аның шушы темага багышланган картиналарын карап туя алмыйсың. Чөнки йөрәкне әсир итәрдәй, гади сүзләр белән генә аңлатып булмастай илаһи



Фәрахи абыйның картиналар күргәзмәсе. 1994 ел

гүзәллек бөркелә алардан. Куе урманына кереп югаласың, чәчәкле-күбәләкле аланнарында тәгәри-йөгерәсең, үзләре күзгә күренмәгән, әмма, һичшиксез, синең баш очыңда гына өздереп сайраучы кошларын онытылып тыңлыйсың кебек тоелган хиссият күңелне биләп ала.

Рәсссамның табигатьне, җиһанны ярату белән тулы күңеле һәм оста куллары аша иҗат ителгән шушындый сихри манзарасын, табигатькә мәдхиясен күреп күзләр соклана, күңелләр хушлана, җан рәхәтлек кичерә, һәр күзәнәк ләззәт тоя.

Фәрахи абый иҗат җимешләре белән кешеләрне сөендерә, аларга шатлык өләшә. Аның рәсемнәре мәктәп залларын, кибет, колхоз ашханәсе стеналарын бизи. Картиналарын дуслары һәм туганнарының гомер бәйрәмнәренә бүләк итә.

2009 елның җәендә Алабугада уздырылган Бөтенрусия Спас ярминкәсендә картиналарының күргәзмәсен оештыра һәм бик күп табигать сөючеләрнең күңеленә хуш килә.


Менә инде ул 83 ел Ходай биргән сәләте белән яши, сулый, яраткан һөнәреннән бер генә көн дә аерылмыйча, бәхетле, сөенечле гомер сәгатьләрен кичә. Хатыны Шәргыя апа белән өч бала үстерделәр. Афәрин, мөхтәрәм рәссам. Бәхетле-бәрәкәтле, сау-сәламәт яшәү насыйп булсын Сезгә!

Укытучы күршеләр

Бәзәкә мәктәбе каршында оештырылган башлангычларның куст берләшмәсенә кергән Сәйтәк һәм ике Тәкәш авылы укытучылары турында язмый калдыру яхшы гамәл булмас. Чөнки бу кечкенә авыллардан гомергомергә безнең мәктәпкә укучылар 5 нче сыйныфка ук укырга килделәр. Соңнан, 1977 елдан, Чөмән буе авыллары балалары Песәй мәктәбенә йөреп укый башлагач та, Сәйтәк, Тәкәшнекеләр бездә укыдылар. Бүген дә бу шулай.

Сәйтәк мәктәбе 1970 елга кадәр сигезьеллык була. Әмма 1970 елның кышында ут чыгып, мәктәп янып бетә, 100 дән артык бала Бәзәкәгә килеп укырга мәҗбүр була. Менә шушы фаҗигагә кадәр Сәйтәк мәктәбендә гади, тыйнак, бик тырыш укытучылар эшләделәр. Бертуган Михаил һәм аның хатыны Фёкла Орлова, Вениамин Орлов, Матрена һәм Исмәгыйль Мортазиннар гомерләрен шушы авыл балаларына белем һәм тәрбия бирүгә багышладылар.

Матрена һәм Исмәгыйль Мортазиннарга аерым тукталасым килә.



Исмәгыйль абый 1915 елгы, тумышы белән Кукмара районының Мәмәшир авылыннан. Бөек Ватан сугышында катнаша, офицер була. Тоткынлык газапларының ачысын татырга да туры килә үзенә. Сугышка кадәр Алабуга педучилищесында укый. Матрена апа белән танышып гаилә коралар, икесе дә Сәйтәк башлангыч мәктәбендә укыталар.

Матрена апа 1919 елда Бондюг районының Максимково авылында туа. Авылдагы башлангыч мәктәпне бетергәч, Бондюг җидееллык мәктәбендә укый.



1937 елда Алабуга педучилищесына керә. 1938 елда туган авылында башлангыч классларда укытучы булып эшли башлый (укуын читтән торып дәвам итә).

Сугыш елларында авылда комсомол оешмасын җитәкли. Комсомоллар танк, самолет төзү өчен акча, сугышчылар өчен җылы киемнәр җыеп тапшыралар, фронтка посылкалар җибәрәләр.

Мөгаллимә истәлекләреннән: “Мин ул елларда төшкә кадәр мәктәптә укыттым, көннең икенче яртысында колхоз кырында балалар белән башак җыйдык, атларга печән әзерләдек. Төнлә комсомоллар белән кибән куйдык, ашлык чистарттык, борчак суктык. Авыр да, күңелле дә иде. Беркайчан да төшенкелеккә бирелмәдек”.

1948 елда читтән торып Алабуга педагогия институтын тәмамлый. Гомеренең 40 елын балалар укытуга багышлый. Тырыш хезмәте өчен 1969 елда РСФСР Мәгариф министрлыгының “Халык мәгарифе отличнигы” билгесе белән бүләкләнә.

Шулай итеп, Матрена апа белән Исмәгыйль абый, бер-берсеннән бер генә көнгә дә аерылмыйча, гомер юлларын пар күгәрченнәр кебек гөрләшеп, матур итеп үтәләр. Бары үлем генә беразга аера аларны: башта Исмәгыйль абый вафат була, аннары – Матрена апа. Исмәгыйль абый, мөселман кешесе буларак, үзен мөселман кануннары кушканча күмәргә куша. Әмма Бәзәкәдә түгел, ә хәләле белән гомер кичергән керәшен Сәйтәк авылында. “Җир барыбыз өчен дә бер”, – ди ул. Каберләре дә янәшә, икесенең дә укучысы булган Мария Тараканова кабере генә аерып тора үзләрен.

Урыннарыгыз җәннәттә булсын, кадерле Укытучылар.

Укытучы Тимеркәевләр династиясе

Татар Тәкәше мәктәбе турында сөйләгәндә, укытучы Тимеркәевләр династиясе күз алдына килеп баса. Бу гаиләдән дүрт укытучы чыккан.



Флүрә һәм Рифкать Тимеркәевләр. 1962 ел

Гаилә башлыгы Рифкать Тимеркәев 1937 елда колхозчы гаиләсендә туа. 1946 елда Тәкәш башлангыч мәктәбенә укырга керә. 1956 елда Бәзәкәдә урта мәктәпне төгәлли. Берара клубта мөдир булып эшли. Аннары армия сафларына алына, Тын океан флотында моряк булып хезмәт итә. Корабль экипажы белән Индонезиядә булалар, экваторны кичәләр.

Хезмәтен тутырып кайткач, Алабуга пединститутының педагогия факультетын бетерә (ул вакытларда шундый дүрт еллык факультет була). Тәкәш мәктәбенә директор итеп билгеләнә, бераздан аны Сәйтәк мәктәбенә укытучы итеп алалар, чөнки ул мәктәп сигезьеллыкка әйләнә, укытучылар кирәк була. Көн саен үз авылыннан килеп-китеп, төрле фәннәр укыта, ныклы белем һәм тәртип булдыру өчен зур тырышлык куя.

Сәйтәк мәктәбе беткәннән соң, Бәзәкәдә эшли башлый. Биредә тарих, җәмгыять белеме, физкультура дәресләрен укыта. Җир кибүгә велосипедта, кышын чаңгыда йөреп эшли.

Рифкать абый бик тә ачык, тиз аралашучан, ярдәмчел кеше булды. Аның күңеле якты, эчкерсез иде. Үзенә нинди эш тапшырсалар, шуны намус белән тырышып башкарды, ниндидер өстенлекләр эзләмәде, уңай мөмкинлекләр

дауламады. Физкультура укытучысы буларак, укучыларны бик еш район ярышларына алып барды. Башта Тәкәштән Бәзәкәгә төшә, аннары балалар белән Менделеевскига китәләр. Көнозын ярыш-узышларда йөреп, шәкертләрен кире Бәзәкәгә алып кайта, аннары гына, инде кич җиткәндә, авылына юл ала. Ничә еллар шулай йөреп эшләде:



Рифкать Тимеркәев һәм аның укучылары. 1978 ел

авырыксынмады, беркемгә, бер эшкә каршы килмәде.

Тормыш иптәше Флүрә апа белән өч бала тәрбияләп үстерделәр. Беренче уллары авыру, үзләре көне-төне мәктәп тормышы белән мәшгуль булсалар да, баланы беркая да илтеп тапшырмадылар, инвалид улларын чиратлап карадылар, тәрбия кылдылар. Кызларында һәм икенче улларында инсафлылык, тәртип, тырышлык кебек сыйфатлар тәрбияләделәр.

1983 елда явыз үлем Рифкать абыйны арабыздан мәңгелеккә алып китте.

Тыныч йоклагыз, кадерле Укытучы.

Сәләтле укытучы

Татар Тәкәше мәктәбендә озак еллар мөгаллимә Зәйтүнә Галиева эшләгәннән соң, аңа алмашка укучысы Флүрә Тимеркәева килә.



Флүрә Хөснетдин кызы 1939 елда шушы авылда туа. Укытучы булу теләге аны 1963 елда Алабугага әзерлек курсларына алып килә. Бер ел анда белем алганнан соң, туган мәктәбендә укыта башлый. Читтән торып институтның педагогия факультетын тәмамлый. Үзенең укучыларын белемле, тәртипле итү өчен ифрат дәрәҗәдә тырыша, балалар белән күп эшли. Дөрес һәм матур язу күнекмәләрен булдыруга аеруча зур тырышлык куя. Тиз һәм сәнгатьле итеп укысыннанр өчен, һәрберсен дәресләрдән соң чакырып, өстәмә эшли. Клубта һәрбер бәйрәмдә концертлар куялар (ә бит 5 бала белән куясыңмы, 25 бала беләнме – анысын уйлаучы юк, концерт кына булсын). Флүрә апа 30 ел яратып сайлаган һөнәренә тугрылыклы булып калды. Озак еллар эшләү дәверендә ул авыл халкы арасында зур хөрмәт казанды, җәмәгать эшләрендә актив



Тәкәш авылы балалары укытучылары Флүрә апалары һәм практикантлар янында

катнашты: фикерләү сәләте көчле бу ханым бик оста итеп шигырьләр язды, кызыклы мәкаләләре район газетасында еш басылды, үз нәселе, авылы тарихы белән кызыксынды. Кыскасы, ул бик сәләтле укытучы булды.

Флүрә апаның укучылары арасында горурланып искә ала торганнары бик күп, алар тормышта үз урыннарын таптылар. Мәсәлән: Гыйльфанов Мөнәвир – Казан университетын бик яхшыга тәмамлады, бертуган Кашафетдиновлар: Люция, Илгиз, Ләйсән – шәхси эшмәкәрләр. Кызы Тимеркәева Румия – укытучы, Песәй мәктәбендә эшли. Ул да Бәзәкә мәктәбен тәмамлады. Көчле, төпле белемле, бик тәртипле, инсафлы һәм мактаулы укытучыларның берсе. Әнисе кебек шигъриятка гашыйк. Улы Рунар шулай ук Алабуга пединститутын бетерде, Тәкәштә, аннары берара Ык Тамагында укытты. Ләкин аз укучылы мәктәпләрне кыскарту, ябу шаукымы нәтиҗәсендә, һөнәрен үзгәртергә мәҗбүр булды.

Флүрә апа 1994 елдан лаеклы ялда. Намуслы хезмәтегез, мәгариф системасына биргән көчегез, сәләтегез өчен зур рәхмәт, Флүрә апа! Саулык-сәламәтлек, бәрәкәтле гомер сезгә!

Мари Тәкәше остазы



Ветеран Җиңү бәйрәмендә

Мари Тәкәше – бер урамлы кечкенә генә авыл. Исеменнән күргәнчә, анда марилар яши. Авыл табигатьнең бик матур җиренә, урман буена урнашкан.

Шушы кечкенә авылда, кечкенә генә мәктәптә күп еллар дәвамында олы йөрәкле, киң күңелле остаз – Бөек Ватан сугышы ветераны Шамил ага Шәймәрдәнов укытты, балаларга аң-белем нурларын сипте. Ул укыткан балалар алга таба Бәзәкәдә урта белем алдылар. Алар өч телдә: мари, татар, рус

телләрендә иркен сөйләштеләр, немец телен үзләштерделәр, үзләрен безнең мәктәптә дә тырыш, тәртипле итеп күрсәттеләр.

Шамил ага авыл тормышында да актив катнашты, авылларында ветераннар советы рәисе булды, Ватан сугышында һәлак булганнарга обелиск булдыруга иреште. Булдыклы, оста умартачы да иде үзе.

1993 елда укытучы Шамил ага вафат булды. Тыныч йоклагыз, ветеран Укытучы!

Чөмән буе укытучылары

1950-60 елларда Бәзәкә мәктәбендә, инде әйтеп узганча, күрше-тирә унбер авылдан балалар укый иде. Аларга 8 нче сыйныфка кадәр үз мәктәпләрендә үз авыл укытучылары белем бирә, тәрбия кыла, укучылары башка мәктәптә дә беренче туган мәктәбенең йөзенә кызыллык китермичә, яхшы укысыннар, тәртипле булсыннар өчен тырышлык һәм көч куялар.

Чыннан да, бу укучылар арасында бик яхшы, тырыш, актив балалар байтак була иде. Алар яңа коллективка, зур мәктәпкә килгәч, шушы авыл балалары белән уртак тел табып, аралашып, дустанә булып укыйлар, укытучыларны да бик тиз яратып өлгерәләр. Әмма төрле авыллардан килгән укучылар үзләренең яраткан укытучыларын да онытмыйлар, алар турында һәрдаим җылы хисләр, матур сүзләр белән сөйләп, мактап торалар.

Чит мәктәпкә килгән укучыларга баштарак кыенга туры килә, билгеле. Соңыннан бар да җайлана, рәтләнә. Менә шул турыда сөйләүче бер кызыклы истәлекне сезгә дә җиткерим әле. Бу турыда Бәзәкә мәктәбен бетерүгә 42 ел узганнан соң очрашу бәйрәмендә турайлы Наил Нигъмәтҗанов сөйләгән иде.

– 7 нче сыйныфны бетергәч, Бәзәкәгә укырга килдек. Яңа мәктәп, барысы да чит-ятлар. Дүрт Турай малае көч-хәл белән өч дәреснең бетүен көтеп алдык та, калганнарыннан качтык, кызлар калдылар. Юл уңай кибеттән "Казбек" папиросы ал-



дык, аны юлдан читкәрәк кереп утырып тарттык, дөресрәге, тончыктык, ютәлләп җәфаландык. Юк, "Казбек" та җиңеләйтә алмады безнең хәлне. Чит мәктәптә укыйсы килми, беттекитте. Берничә мәртәбә шулай калулар, мәктәпкә барабыз дип китеп, көнозын Чомартауда, посадкада ятуларның нәтиҗәсе безнең файдага булмады: Бәзәкәдән укытучылар килеп тә җителәр. И-и-и, "пешерде" соң шул вакытны әни үземне.

Эленке-салынкы булса да, тагын йөри башладык мәктәпкә. Ул арада басуга бәрәңге алырга чыктык. Классташлар белән дә, укытучы абый-апалар белән дә якынаеп, дуслашып киттек, бу дуслыкны гомер буе сакладык.

Үзебез дә сизми калдык, тиздән Бәзәкә мәктәбе безнең өчен икенче туган йортыбызга әйләнде. Шушы мәктәптән кулыбызга өлгергәнлек аттестаты алып, зур тормыш юлына чыктык. Хөрмәтле укытучыларыбыз хәер-фатихасы белән дөрес юлны таптык, кирәкле һөнәрләрне сайладык, ялгышмадык. Әгәр узган гомерне кире кайтарып булса, мин ике дә уйламыйча, иренмичә, һич тә үкенмичә Бәзәкә белән Турай арасын көн саен тагын 10 ел үтәр идем.

– Чиксез рәхмәтләрем сезгә, кадерле укытучыларыбыз, – дип сүзен төгәлләгән иде Турай фермер хуҗалыгы рәисе.

Мәктәбебез укытучылары турында менә шундый хисле-тәэсирле истәлек-хатирә...

Нәкъ шушы урында күрше авыл укытучыларының исемнәрен атап, аларга хөрмәт хисләрен җиткерү урынлы булыр дип уйлыйм, чөнки алар Бәзәкә мәктәбенә дистәләгән еллар дәвамында тырыш, тыйнак, инсафлы укучылар җибәреп тордылар.

Менә ул мөгаллимнәр:

Турайдан: Әхмәров Миргалим, Гайшә Сәгъдиева, Нургалиев Муса, Җәмилә һәм Искәндәр Галиевлар, Кәримуллина Розалия (кызы Раилә дә инде менә 14 ел Турайдан көн дә килеп, Бәзәкә мәктәбендә инглиз теле укыта).

Соңрак алар сафына Бәзәкә мәктәбен бетергән Турай кызы Рәүфә Галиева кушыла. Гомере буе туган авылында татар теле һәм әдәбиятын укытты. Татар теленең бөтен нечкәлекләрен белгән, көчле укучылар чыгарган, бала-

ларда туган телгә мәхәббәт орлыкларын мул өләшкән мөгаллимә “Татарстанның атказанган укытучысы” дигән мактаулы исемгә лаек булды, районыбызда иң алдынгы тел укытучысы булды.

Шулай ук бу мәктәптә Төхвәтова Вәсыйга, Гыйбаева Вәсилә, Галиева Мәүлидә укытты. Турай укытучылары балаларга ныклы, төпле белем бирделәр. Афәрин!

Песәйдән: Шәрифуллин Нурулла, Камалова Мәһүбә, Ризалетдинов Нәгыйм, Ибәтуллин Гали, Әхмәтҗанов Әхмәтхан, Тәскирә һәм Камил Галиевлар, ирле-хатынлы Минрахманов Фаикъ һәм Мәрдетҗә Арсланова, Нәҗметдинов Рәфис, Венера һәм Сәетҗан Әхмәтгәрәевлар (берара Бәзәкәдә укыталар, Сәетҗан абый директор була), Нурания һәм Фердинант Сабиржановлар, Хәмидуллина Гөлнура һәм башкалар. Мин укыткан Наил Тимербаев, Әлфия һәм Ринат Җиһангәрәевлар үзләрен тырыш, инициативалы итеп таныттылар, исемнәре район мәгарифе даирәсендә гел макталып телгә алына.

Татар Сарсазыннан: Тарханов Мирза абый, Миңнәхмәтова Наилә, Әлмәтова Рәхилә (өчесе дә берара Бәзәкәдә укытканнар), Тукайдан: Идиатуллина Сөгъдә һәм башкалар.

Санап киткән бу педагогларның укучылары 3-4 ел дәвамында Бәзәкәгә йөреп белем алдылар. Алар арасыннан шулай ук танылган шәхесләр, күпләгән мактаулы кешеләр чыкты. Алда санап үтелгәннәргә тагын да өстәп әйтергә була: Турай тургае Ясәви Садыйков, 30 елга якын балалар бакчасы мөдире булып эшләгән сыйныфташым, дустым Нурания Садыйкова, Шакирова Сәлимә, милиция хезмәткәре Нигъмәтҗанова, Миннәхмәтова Хаҗия, Мөхәммәтгалиева Гөлия. Әтәс, Песәй, Сарсаздан да хөрмәтле һәм танылган кешеләр байтак чыкты.

Илһамланып эшләвегез, түзем-сабыр, бала җанлы булуыгыз, гомер сукмакларыгызны мәктәп юллары белән бәйләп, шул юллардан лаеклы һәм мактаулы үткәнегез өчен рәхмәт сезгә, Чөмән буеның хөрмәтле укытучылары!

А Вуз еллары (1966-1971)

Я



Институт

Вуз еллары – тормыш юлларыма
Мәрҗән сипкән яшьлек елларым!
Җитен чәчле җитмеш яшемдә дә
Сагынып сезне, янып җырлармын.

Алабуга дәүләт педагогия институты – минем икенче белем алган йортым. Бәзәкә урта мәктәбен төгәлләгән елның көзендә үк мин шушы уку йортына керү имтиханнарын тапшырдым.



Институтта укыган еллар – яшьлегемнең кабатланмас гүзәл чоры. Өр-яңа укытучылар, өр-яңа дуслар, исәпсез-хисапсыз лекцияләр, бераз шүрләтә торган, әмма кызыклы семинарлар, шәһәрчә яшәү рәвеше – болар барысы да шул елларның хәтердән мәңге җуелмас хатирәләре, гомеремнең иң күңелле, истәлекләргә иң бай бер өлеше.

Язмыш мине биредә дә искиткеч яхшы кешеләр белән очраштырды. Педагогларыбыз, төрле гыйльми исемдәрәҗәләргә лаек булган зур кешеләр, безне – авылдан килгән яшьләрне, гади, мәрхәмәтле, кешелекле булулары белән әсир иттеләр, без аларга карап сокландык, бераз курыксак та, үзләрен яраттык һәм хөрмәт иттек.

Болар купшы сүзләр түгел, ә чыннан да, минем язмышыма (башкаларныкына да булгандыр) бәйле булган вакыйгаларга нәтиҗә ясап әйтелгән эчкерсез рәхмәт сүзләре. Бу сүзләрне дәлилли торган бер-ике мисалым да бар.

Беренче керү имтиханыбыз рус теленнән изложение иде. Аны язып чыкканнан соң, нәтиҗәләрен ике көн көтә-



се. Шул ике көндә алдагы имтиханга әзерләнә торам.

Нинаять, билгеләр күрсәтелгән исемлекне чыгарып элделәр. Тик, ни күрим, минем фамилиям турында – «неудовлетворительно» тора. Аяк астымда җир убылды дип торам. Менә сиңа мә! Мин изложениены «2»гә язганмын булып чыга мени? Ничек болай булды соң әле бу? Бу билгегә язуыма күңелем ышанмый да, килешми дә. «Мин «икеле»гә язарга тиеш түгел», – дип, кабатлап тик торам басып. Тукта, болай зал уртасында катып торудан файда юк, ни дә булса эшләргә кирәк. Расписаниега күз төшердем дә, өченче этажга чаптым: анда безгә изложение яздырган укытучылар кайсыдыр группадан имтихан алалар икән. Мин шуларны көтәргә булдым.

Менә бер-бер артлы аудиториядән берничә егет-кыз, бераздан укытучылар да чыктылар. Мин алар каршысына атылып килдем.

– Здравствуйте. Мы 15 августа у вас писали изложение.

Минем белән укытучыларның өлкәнрәк яшьтәгесе сөйләште.

– Ну, раз писали, то и оценку свою, наверное, уже узнала.

– Да, узнала... «двойка».

– Вот как? Ну, а мы тут причем?

– Я не верю, что написала на «двойку»...

– Очень интересно. И на сколько же ты думаешь написала?

– На «четверку», «тройку», но только не на «двойку». Это какая-то ошибка. Пожалуйста, пойдемте, узнаем правду.

– Вот какая настойчивая. Правда ей нужна. Коллега, пойдемте, что ли, правду искать...

Һәм алар, чынлап та, минем гозеремне тыңлап, кабул итү бүлмәсенә юнәлделәр. Мин аларга иярдем.

Кабул итү бүлмәсендә секретарь кыз үзе генә нәрсәдер язып утыра иде. Өлкән укытучы аннан безнең язма эшләрне бирүен сорады, аннары миңа үз эшемне табарга кушты.

...Ике табаклык битләрне укытучылар бер ачтылар, бер яптылар, кабат-кабат күздән кичерделәр.

– А ведь ее работа, действительно, не на «двойку» выполнена. Объясните, в чем дело?

Кыз бер мәлгә югалып калды, тик бик тиз үзен кулга алып, аңлата башлады.

– Знаете, их тут очень много. Каждый хочет узнать свою оценку заранее. То родители приходят, всё спрашивают, то кто-то забирает документы. Видимо, я перепутала что-то...

Укытучылар да, мин дә беразга телсез калгандай булдык. Аннары өлкән укытучы кызга бик катгый төстә болай диде:

– Из-за вашей оплошности решается судьба человека (бү сүзләрне мин гомер-бакый онытмадым, балаларга белем һәм тәрбия биргәндә, гел исемдә тоттым).

Шуннан, кинәт миңа таба борылып, беренче мәртәбә саф татар телендә, боергандай, әйтеп куйды:

– Ә син нәрсә, борыныңны мышкылдатып, катып торасың? Иртәгә бит сезнең икенче имтиханыгыз. Йөгер тизрәк өеңә, әзерлән яхшылап.

Мин, атылган ук кебек, бүлмәдән чыгып очтым. Тик шундук, укытучыларга рәхмәт әйтмәвемне абайлап, кире борылдым һәм ишекне ачып: «Рәхмәт! Спасибо!» – дип кычкырдым. Зал буйлап йөгереп үткәндә, теге хәерсез исемлек янына туктап, «неудовлетворительно» сүзенең «не» өлешен ручкам белән каралтып, буяп куйдым.

Икенче көнне рус теле һәм әдәбиятын телдән «4»легә бирдем.

Исләремә төшсә, әле бүген дә ис-акылларым китә. Ничек алар, көнозын имтихан алып, үзләре дә арган-талган зур кешеләр, мине, авыл кызын, туктап тыңладылар, борчуымны аңлап, хәлемә керделәр, миннән (ә минем кебекләр күпме анда!) йөз чөермәделәр, «юк!» дип, кырт кисеп кире борып җибәрмәделәр. Япа-ялгыз башыма төшкән хаксызлыктан аралап, дөреслекне табарга ярдәм иттеләр, кайгымны таратырдай игътибар күрсәттеләр?...

Шундый гамәлгә ни әйтәсең? Рәхмәтләрнең иң зур рәхмәте булсын аларга!



...Тарих фәне буенча имтихан көнебез. Алдагы көнне үк, жирәбә сикертеп, кемнең кайчан керәсен бүлешеп куйдык. Миңа унлап кешедән соң гына керәсе, шунлыктан әле квартирамда әзерләнеп торам (тору урыным институт янында гына). Вакыт җитәрәк, институтка чаптым, турыга, хуҗалык ишек алдыннан гына керергә булдым. Ә анда, нәкъ капка турында, ниндидер бер кечерәк кенә йортны сүтеп ташлаганнар. Мин тиз генә бүрәнә-такталар өстеннән сикерә-баса чыгып барганда, менә бәла! Бер такта өстендә чыгып торган кадакка китереп тә басканмын. «Ай!» дип, кычкырып, аякны күтәрсәм, гади дәфтәр калынлыгындагы гына табанлы чүәгемне һәм аякны тишеп кергән кадакта такта асылынып тора! Я, Аллам, нәрсә инде бу! Аккан кангa карап, үзеңне кызганып торып булмый: тиз генә тактаны алып ташладым да, титаклый-титаклый институтка кереп киттем. Чынлап та, миннән алдагылар инде кереп утырганнар, бер 5 минуттан мин дә кердем.

Исәнләшеп, өстәл янына билет алырга юнәлдем. Аксаклап килүемне укытучы абый күреп алды.

– Ник аксыйсың, кызым, ни булды? (Укытучы татарча сөйләште)

Мин хәлне аңлатып бирдем.

– Тукта, син билет алып торма. Хәзер чык та, тиз генә безнең медпунктка төшеп, аягыңны бәйләт.

– Ә имтихан?..

– Имтихан качмас, ә менә синең аяк белән тагын да начаррак хәл – заражение китәргә мөмкин. Бар, бар, бәйләт тизрәк, соңнан керерсең.

Шулай итеп, мин кире чыгып китәргә мәҗбүр булдым. Яралы аякны тиз генә бәйләтеп чыктым, имтиханымны да «бишле»гә бирдем.

Миңа карата игътибарлы булган укытучы соңнан безгә тарих фәненнән керде. Ул – Әсгать абый Насыйбуллин булып чыкты. Үзе алыптай зур гәүдәле, кояштай ялтырап торган пеләш башлы, күк күкрәгендәй көчле тавышлы бу мөгаллим минем шәхси борчуыма битараф булмыйча, хәлемә керде, ярдәм күрсәтте. Башым ярылса да, миңа

мондый хәстәрлекне үз әнием дә күрсәтмәс иде, билләһи. «Ут капмагандыр бит, нәрсә дип чаптың шулкадәр?» – дияр иде дә, бетерер иде.

Рәхмәт Әсгать абыйга! Бүгенге көндә вафат булган кадерле мөгаллимемнең рухы шат булсын!

Шушындый Олы да, Гади дә, Гали дә укытучылары-бызга, инде күп еллар узгач булса да, рәхмәт сүзләремне җиткерәсем, ишеттерәсем килә.

Легендар укытучы Маһинур апа Фәйзуллина (Муса Җәлилне күреп белгән, аның белән бергә Мәскәүдә эшләгән, язучы Габдрахман Әпсәләмовны укыткан), аның кызы Ария Хәбиб кызы Вәлиева, язучы-укытучы Эдуард абый Касыймов, Галина Николаевна һәм Николай Демьянович Григорьевлар, Хәлимә апа Дулалаева, Айзирәк апа Кәримова, Фәридә Әхмәр кызы Мурадимова, безне вожатый булырга әзерләүче, пионер эшләре белән кызыксындыручы, үземә «огонь-девушка» дип яратып эндәшүче, шәхси тормышымны башлаганда миңа ярдәм кулы сузучы яраткан укытучым Дамира апа Ягъфәровага аерым Зур Рәхмәтем (соңрак, 80 нче елларда, ул мине пединститутка педагогика кафедрасына пионер эше юнәлешендә эшкә чакырган иде). Сания апа Исмәгыйлова, Леонид Шәйсолтанович Арсланов, Нәиб Нажар улы Ләисов, өч Дан ордены кавалеры, сугыш ветераны Рифкать абый Гайнуллин, Луиза Сабир кызы һәм Олег Иванович Федотовлар, Леруза һәм Хатыйп Хәкимовлар һәм тагын, тагын башкалар. Сез искиткеч һәм чын Укытучылар идегез. Булачак укытучыларга белем биргән Укытучылар. Йөзләгән, меңләгән шәкертләрегез һәм шәхсән үзем сезгә чиксез һәм гомер рәхмәтле!

Студент елларым турында бәян иткәннән соң, гомеремнең шул чорында күңелемне җылыткан, матди хәлемне җиңеләйткән якын кешем турында әйтми китә алмыйм. Бу – бертуган апам Рәйсә. Ул яшьтән үк башта Пермьдә, аннары Чиләбедә яшәде, шунда төзелештә эшләде. Әни белән миңа елына өч-дүрт мәртәбә посылкалар салды, өс-башымны карады. Кечкенә генә студент стипендиясенә зур ярдәм, иш янына куш булды ул күчтәнәч-бүләкләр. "Ач йөри күр-



мә, аша-эч, киемнәреңне рәхәтләнеп ки, тагын салырмын”, – дигән сүзләреннән башым күккә тия иде. Шушындый шәфкатьле, мәрхәмәтле һәм юмарт апам булуына сөенеп туя алмый идем (хәзер дә шулай). Рәйсә апама мин гомерем буена рәхмәтле һәм бурычлы. Берүк исән-имин, тазасау гына була күрсен, балалары Рафаэль һәм Лилия, оныклары күрсәткән куаныч-игелекләргә шатланып, сөенеп, озын-озак яшәсен, бәрәкәтле гомер кичерсен.

Тәүге адымнар

Алабуга пединститутын бетергәч, мине эшкә шушы ук районның Иске Юраш мәктәбенә билгеләделәр. Бу мәктәп – укытучы хезмәтенә багышланган биографиямнең юл башы, балалар алдында (инде дипломлы белгеч буларак) тәүге дәресләремне биргән белем учагы. Биредә мин рус теле һәм әдәбияты укыттым (шунда, беренче елымда язган дәрес планнарым әле бүген дә саклана), тәрбия эшләре буенча директор урынбасары вазыйфаларын башкардым. Мәктәпне, институтны бергә тәмамлаган авылдаш кызым Сәкинә Мөхәммәтҗанова белән безне яңа коллективта якты йөз һәм җылы мөнәсәбәт белән каршы алдылар. Коллектив зур, тату. Өлкән буын мөгаллимнәр дә, яшьләр дә безне үз иттеләр, без дә аларга бик тиз ияләштек, дуслаштык.

Мәктәп директоры Дамир Хузиевич (бу мәктәптә укытучыларга русчалатып дәшәләр иде) тәрбия эшләрендә яшьләргә таянырга кирәклекне гел искәртеп торды. «Кайда яшьләр – шунда яшьлек, яңалык, ямь», дияргә ярата иде ул.

Бу мәктәп коллективына рәхмәтем һәм хөрмәтем зур, чөнки һәркайсы булдыра алган кадәр безгә ярдәм кулы сузарга тырышты: планнар төзегәндә дә, «кыен» балалар белән ничек эшләргә, ата-аналар җыелышын ни рәвешле уздырырга, документацияне ничек тутырырга – боларның барысына да укытучы-коллегалар теләп төшендерделәр.

Әйе, белем бирү нечкәлекләренә төшенүдә тәүге адымнарны без сездә ясадык, хөрмәтле юрашлылар. Өлкән буын укытучылары: Роза Садыйковна Мөбәракшина – мәктәпнең тәҗрибәле уку-укыту завучы. Ипле, итәгатьле бу ханым беркайчан да кинәттән генә «Хәзер синең дәресеңә керәм» – дип, өнеңне алмас, киресенчә, җомга көннән үк: «Киләсе атнада шундый-шундый фән тикшереләчәк» – дип, белдерү язып куяр. Тыныч кына дәресеңә анализ ясар, йомшак итеп кенә тәкъдимнәрен әйтер. Мәгънәле, тактлы, зыялы, чын педагог-завуч нәкъ менә шундый булырга тиеш дип уйлыйм. Рәхмәт сезгә.



Иске Юраш мәктәбе коллективы. 1971 ел

Дмитрий Григорьевич Тарасов – Бөек Ватан сугышы ветераны, бер кулын фронтта өздергән инвалид булуга карамастан, сыңар кул белән тактада бик матур һәм тиз яза, балаларга математика серләрен төшендерә иде. Афәрин, ветеран укытучы!

Гаилә династияләреннән: Кадрия апа (башлангычта укытты) һәм Мирза абый Вәлиевлар (тарих, география укытучысы, директор да булган); Рәйсә апа (татар теле) һәм Вагыйз абый (хезмәт фәне) Сәлимовлар, Тимерхан абый (сугыш ветераны, тарих) һәм Рәвилә апа (рус теле),

Римма апа (татар теле) һәм Марсель Тимергалиевлар (тарих) укыттылар. Лина апа Әхмәтова (интернат тәрбиячесе, кызлары Алсу һәм Әлфия берничә ел Бәзәкә мәктәбендә укыттылар), Фәйрүзә апа (химия), тагын бер Фәйрүзә апа (аш пешерүче), квартирабыз хуҗасы Гайшәкәй апа – сезне дә онытмыйм мин. Сез безгә, яшьләргә, яхшы үрнәк, якты өлге булып тордыгыз. Чиксез рәхмәтләрем сезгә.

Яшьләрдән: Абалач кызы Наилә Муллахмәтова (математика) – минем тормышымда зур ярдәм, игелек эшләгән, гомеремне саклап калган кеше. Минем сәламәтлегемә янаган көчле авыруны берничек тә чигендереп булмаган бер мәлдә, ул, ике дә уйламыйча, үз иминлеген куркыныч астына куеп, миңа ярдәм кулы сузды, савыгырга җирлек, мөмкинлек бирде. Рәхмәт, рәхмәт, тагын бер кат рәхмәт, Наилә!

Әнәс Юнысов (физика), күрше Морт авылы кызлары Фәһимә һәм Әминә (рус теле), Сәкинә (рус теле), Хәлимә (башлангыч), Мәрьям (физкультура), Аркадий, Михаил Камашев, Фәгыйлә Зарипова (җыр-музыка укытучысы, мәктәпнең тәрбия чараларын, концерт-кичәләрен аның баянда сыздырып уйнавыннан башка күз алдына китереп тә булмый иде) – һәммәбез мәктәптә, авыл халкы алдында, күрше авылларда ду китереп концертлар куйдык, төрле тематик кичәләр оештырдык – яшь идек, матурлар, көчле, тәвәккәл, күтәренке рухлылар. Сезнең белән эшләү, яшәү, яшьлегебез таңнарын бергәләп аттыру дөнья рәхәте булган икән. Якты, кадерле хатирәләргә уралган елмаюлы рәхмәтем еллар аша сезләргә барып ирешсен, яшьлек дусларым, хезмәттәшләрем!



Мәктәпнең чыршы бәйрәмендә. сулдан беренче: Зарипова Фәгыйлә, өченче – Вәлиева Вәсилә

Тормыш сабаклары

Я





Әни мәктәбе

Баланың тәртипле, акыллы, игелекле булуы – һәрбер ата-ана өчен олы шатлык, зур сөеneч. Һәркем үз баласының сау-сәламәт, инсафлы, тәүфыйклы булып үсүен тели, киләчәктә үзенә һәм кешеләргә карата шәфкатьле-миһербанлы, ярдәмчел һәм хөрмәтле булуына өмет итә.

Дөньяны, тормышны танып белергә ярдәм иткән, укырга-язарга өйрәткән укытучыларым турында бәян иткәннән соң, тормышны ачып бирүче, үз үрнәгендә яшәргә өйрәтүче, тәрбия кылучы Әнием турында язмыйча, бер сүз дә әйтмичә китү зур гөнаһ булыр.

Кече яшемдә әни миңа үзе белгән берничә кыска дога өйрәтүдән ары китә алмады, чөнки үзе дә грамотасыз иде. Аңа 7 яшь булганда, революция башлана. Абыстайдан бераз өйрәнгән гарәпчә уку-язу күнекмәләреннән кириллицага күчергәннәр. Бераздан латин графикасын керткәннәр. Озакламый аны тагын сәвитчә уку алыштырган. Шулай итеп, берсен башлап, икенчесен ташлап белем биреп маташу әниләрне надан калдырган. Укымый калган кешенең бик күп кыенлык-каршылыкларга тарыганын үзендә татыган әни, ничек тә мине укытырга тырышып, гел кабатлый иде: «Миңа инде уку эләкмәде. Берүк син укырга тырыш, кызым».

Укымаган булуына карамастан, әни югалып калмаган, ул тормыш сабакларына таянган: яхшылардан үрнәк, яманнардан гыйбрәт алып, тырышлык һәм үҗәтлек белән үз тормышын-язмышын гади, тыйнак һәм матур итеп кора алган.

Ире вафатыннан соң (әти 46 яшьтә була), балаларын исән-имин үстерү, кеше итү өчен бөтен мөмкинлекләргә теше-тырнагы белән ябышкан. Билгеле инде, без дә читтә калмый идек: әни безне хуҗалыктагы һәр эшкә, шөгыльгә катнаштыра килде.

Әни миңа ниндидер эш куша калса, һәрчак иң элек: «Кызым, эшләгәнең кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен», – дия иде. Әгәр кушылган эшне, озаграк йоклап ки-

теп, үз вакытында эшләп өлгертә алмасаң, әни тагын ипләп кенә искәртеп куя: "Иртә торсаң ит пешә, соңга калсаң бит пешә". Әнинең тагын бер яраткан әйтеме бар иде: "Белгәннe, өйрәнгәнне күтәреп йөрисе юк. Ул бик җиңел була". Булдыра аламмы-юкмы, килеп чыгамы, әллә бозып куяммы – анысы аның өчен зур бәла түгел. Кәрҗин үргәндә, палас сукканда яки ипи пешергәндәме – минем катнашуым, өйрәнергә тырышуым, карап торуым булса да, ягъни хезмәткә өйрәнергә әзер булуым – менә нәрсә иң мөһиме иде әнигә.

Хәзерге заманда модага кереп киткән "толерантлык" дигән төшенчәне дә безнең әниләр инде күптән белгәннәр һәм, тәрбия чарасы буларак, балаларының аңнарына сеңдерә килгәннәр. "Таш белән атканга, аш белән ат", "Үзеңне зур күрмә, кешене хур күрмә", – дигән гыйбарәләр шул турыда сөйләми мени.

Әни еш куллана торган мәкаль-әйтемнәрнең эчтәлегенә ул вакытта бик төшенеп үк җитмәсәм дә, еллар узгач, инде үзем әни булгач, ныклап төшендем һәм аларның балаларга тәрбия бирүдә гап-гади, ә нинди тирән мәгънәгә ия булуларын аңладым. Әни үзенә хас бер укытучы, остаз булган икән бит. Халык педагогикасына таянып, безгә, балаларына, тормыш сабаклары биргән. Рәхмәт сиңа, Әни!

Быел әниемнең тууына 100 ел тула. Игелекле, мәрхәмәтле мөгаллимнәргә багышланган бу китап – иң тәүге сабак бирүче әниемнең дә якты истәлегенә нур, ә рухына шатлык өстәсен. Амин!

Калада уку

1960 ел, декабрь. Мин 7 нче сыйныфта укыйм. Абыем Әнвәр армиядән кайтып төште (Ул Тын океан флотында су асты көймәсендә биш ел хезмәт итте, шуннан соң гына демобилизацияләнеп кайтты). Тиздән абый мине киреләнеп маташуыма карамастан, үзе белән Чиләбе каласына алып та китте. «Әйдә, урысча өйрәнерсең», – диде. Килеп җиткәч, бер рус карчыгына квартирага урнаштырды. Мин

укыйсы мәктәп квартирадан ерак түгел. Үзе зур, дүрт катлы бу мәктәп 46 нчы номерлы булып, мәктәп каршында ук Зоя Космодемьянскаяга һәйкәл куелган, пионер дружинасы һәм комсомол оешмасы аның исемен йөртә икән.

Ярый, хуш. Мәктәпкә килдек, директор кабинетына уздык. Абый хәлне кыскача аңлатты, ә директор, аны бүлдермичә генә, минем документларымны, өлгереш табелемне караштырды. Ә аннары: "А разве она иностранный не изучала?" – дип сорап куйды. Абый-миңа, ә мин аңа карап, иңнәремне җыердым...

Әйе, ул чорда авыл мәктәпләрендә (һәрхәлдә бездә шулай иде) чит тел урта сыйныфларда укытылмый, тугызынчыда гына керә башлый иде. Ә шәһәрдә бу фән 5 нче сыйныфтан ук өйрәтелә икән.

Директор белән байтак кына сөйләшкәннән соң, шул мәгълүм булды: ике ел ярым (5 тә, 6 да, ярты ел 7 дә) чит тел укымаган өчен мине 5 нче сыйныфка алачаклар икән. Менә сиңа мә! Утырган урындыгымнан егылып төшә яздым. Чыраемның "матурлыгын" күрептер инде, директор мине тынычландыра башлады. Әгәр мин 5 нче сыйныфны "икеле"ләрсез бетерсәм, киләсе елда 7 нче сыйныфта укыячакмын икән, ягъни алтынчыны сикертеп үтеп. Елап-мышкылдап торуның да файдасы тимәде. Сөйләшү, аңлатулардан соң соңгы сүз әйтелде: мин 5 нче сыйныфта укырга тиеш, башка юл юк.

Бу шәһәрдә, мәктәптә укуым дәверендә аңымда, күңелемдә бары тик якты, җылы хисләр генә уелып калды. Биредә директордан башлап, безгә кергән һәр укытучы, сыйныфташларым беренче көннән үк ярдәм иттеләр, мине чит-ят итмичә, үз-якын күрделәр.

Шулай итеп, мин 5 нче "ж" сыйныфында укый башладым. Шаккатмалы хәл: бер бишенчеләр генә дә ничә параллель икән биредә: 5 "а", "б", "в", "г", "д", "е", "ж". Шулай булгач, бу мәктәптә балалар санының күпме икәнен чамалавы авыр түгел.

Директор абый бишенчеләрдә тарихтан керә икән. Беренче көнне сөйләшүдә үк миңа үз фәне буенча ярдәм тәкъдим итте. Менә мондыйрак: "Әгәр дәреслектә синең

өчен ниндидер авыр, аңлашылмаган сүзләр, әйтемнәр очрый икән, гади карандаш белән шул сүзләрнең асларына сызарсың. Мин сезгә керәсе көнне, дәресләргә кадәр бер 10 минут алдан килеп, кабинетыма керерсең. Мин аңлатырга тырышырмын". Әле дә истә, астына сызган беренче сүзләрем "трущоба", "жилище" булдылар. Укытучы аларның мәгънәсен миңа мисаллар аша, охшаш сүзләр белән бәйләп тәфсилләп аңлатты. Шулай бер айдан артык вакыт шөгыльләнде ул минем белән. Хәзер дә исем китә: ничек ул, меңнәрчә бала укыган мәктәп җитәкчесе, минем белән утырырга вакыт тапкан да, теләк тапкан, авылдан килгән бер татар кызына ярдәм итүне үзенең бурычы дип кабул иткән. Бүген шулай эшли алырлар иде микән директор булган әфәнделәр? Ай-һай...

Әле директор гынамы, безнең сыйныфта укыткан башка укытучылар да нәкъ шулай эшләделәр. Сыйныф җитәкчесе Галина Николаевна Босенко, гомумән, башаягы белән миңа бәйле мәшәкатьләргә чумды.

Беркөн шулай мине өенә алып кайтты. Иренең ак күлмәген кискәләп, миңа алъяпкыч, яка һәм манжетлар, үзенең итәгеннән форманың җиңнәре тиз тишелмәсен өчен ике пар җиңсә текте, көнозын диярлек минем белән мәш килде. Азактан кайндыр пионер галстугы табып чыгарды да, олы улымныкы, диде, аны тиз генә үтүкләп тә бирде. "Придется носить", диде, чөнки галстук тагу-такмау мәсьәләсендә дә матавык булып алган иде. Нинди дисезме? Болай булды ул.

Авылда вакытта ук мине октябрь аенда, комсомол туган көндә, комсомолга алганнар иде. Ноябрьдә 14 яшь тула чөнки. Биредә мин комсомол значогымны формама тагып килгәч, классташларның күзләре шакмак булды, класс җитәкчемнең дә гажәпләнүе чиктән ашкан иде. Минем белән сөйләшеп-аңлашканнан соң, ул мәктәп администрациясе белән дә киңәшләште бугай һәм, соңгы сүз итеп, миңа галстук бирде. Күңелем белән моңа ризалашмасам да, барыбер галстук тагарга мәҗбүр булдым. Әмма значогымны еракка алып куймадым, киресенчә, һаман тагып йөрдем. Тик... алъяпкыч канатының эчке ягында.



Сыйныфташлар белән дә дуслык бик тиз урнашты. Берничә кыз миңа гуманитар фәннәрдән (рус әдәбияты, тарих) тексттагы сүзләр өстенә басым (ударение) куярга булышты. Әйе, әйе, нәкъ басым. Чөнки татар баласына (башка милләтләр өчен дә шулайдыр ул), минем өчен дә текстны тиз дә, сәнгатьле дә укырга тиеш булган рус әдәбиятыннан иң кыены – сүзләрдә басымның күрсәтелмәве. Татар балалары өчен чыгарылган дәреслекләрдә бит (өлкән сыйныфлардан кала) һәр сүздә басым куела иде. Ә рус әдәбиятында ул юк. Менә шул кимчелек текстны укыганда безнең өчен кыенлыклар тудыра: төртеләсең, уйлап торасың, бер сүзне 2-3 тапкыр кабатлыйсың һәм – уку тизлегең кими, син авырдан гына, көч-хәл белән укыйсың кебек килеп чыга. Шушындый хәлдә, миңа ярдәм итүче кызлар, тәнәфесләрдә сүзләр өстенә гади каләм белән басым куеп бирәләр иде, рәхмәт төшкереләре...

Баштарак математикада да буталчык килеп чыкты: татарчада вакланма астан өскә укыла бит, мәсәлән: 5/7 (җидедән биш), 2/3 (өчтән ике) дип. Ә русларда ул киресенчә: өстән аска укыла икән. Менә шул киреле-кырлы, аслы-өсләрне бутапмы-бутадым. Әмма миңа бу авырлыкларны, кыен мәсьәлә-мисалларны җиңәргә Таня Борисенко дигән кыз ярдәм итте (ул да минем кебек каяндыр күченеп килгән хәрбиләр гаиләсеннән иде). Дәреслә р беткәч, тирә-ягы чәчәк-куакларга күмелгән һәйкәл янына чыгып чүгәлибез дә, Таня чыбык белән җиргә сыза-сыза, миңа өй эшләрен аңлата, төшендерә. Аңа да ихтирамым зур булды.

Ә иң якын, эчкерсез, ярдәмчел дустым – Галя Ткаченко (кара, әллә монда гел украиннар җыелган иде микән соң?) булды. Иң беренче көнне таныштырганда класс җитәкчебез: “У нас появилась новенькая девочка-татарочка. Она у себя на родине обучалàсь на татарском языке, и ей у нас на первых порах будет трудновато. Кто берется ей помогать?” – дип әйтүгә, беренчеләрдән булып шушы кыз “Я!” – дип, сикереп баскан иде. Шул көннән без бергә утыра башладык, нык дуслаштык. Кечерәк кенә буйлы,

ак чырайлы, бик мөлаем, ачык бу кыз миңа ниндидер бер җылылык, ихласлык белән кыен хәлләрдә ярдәм итәргә, авыр булганда булышырга, белмәгәндә аңлатырга, ялгышканда төзәтергә һәрчак әзер иде. Төзәтергә дигәннән, бер мәзәк хәлне әле дә онытмыйм.

Шулай бер көйгә укып йөрим. Беркөн, ниндидер дәрестә, Галя колакка әкрен генә нәрсәдер сөйләп алды. Мин, үз чиратымда, нишләптер аның белән килешмәдемме шунда, аңа шулай ук пышылдап кына: "Дурак!" дип куйдым бит. Мәгълүм ки, безнең татарда род юк бит инде (ягъни мужской, женскийлар). Галя аз гына дәшми торды да, кабат миңа иелеп: "В женском роде не так нужно говорить" – диде. Миңа шул җитә калды, имеш хатамны тиз төзәтәм, аңа тагын "Дура!" – дип, җавап кайтардым. Галям бер мәлгә тынып калды, аннары күзләрен челт-мелт итеп, бераз карап торды да, миңа бөтенләй яны белән борылып утырды. Шундук аңлап алдым: һаман миңа ярдәм итәргә тырышкан дустымны бер-бер артлы җүләргә чыгарып утырам түгелме соң мин, ахмак. Галяга эндәшеп карыйм, җавап бирми. Шунда тиз генә бер кәгазь кисәгенә: "Галя, пожалуйста, извини. Я ведь хотела только род исправить, а не тебя обидеть", – дип язу яздым да аның алдына куйдым. Ул язуга кагылмыйча гына укып чыкты да бер-ике минут дәшми торды. Аннары миңа борылып: "Ну ладно уж, прощаю", – диде һәм үзенең самими елмаюы белән мине тәмам тынычландырды.

Шулай, көн артыннан көн үтте, 1961 елга да аяк бастык. Мине хор түгәрәгенә алдылар. Биредә безне, тавышлар буенча группаларга бүлгәләп, дөрес итеп җырларга өйрәттеләр, концертлар да куя идек. Шул уңайдан бирелгән мактау кәгазьләрем әле бүген дә исән.

1961 ел, 12 апрель. Озын итеп кыңгырау яңгырады, безне урамда линейкага җыйдылар. Ишектән чыкканда ук кулларга шарлар, кечкенә флагчыклар тоттырдылар. Менә мәктәп директоры сүз алды. Бүген дөньяда моңарчы күрелмәгән, ишетелмәгән хәл булган икән: Юрий Гагарин дигән кеше (ул космонавт була икән) космик корабльдә космоска очкан. Бу сүзләр безнең колакка да, аңыбызга да



таныш түгел, чит-ят иделәр. Без югарыга, күккә карап, сөйләүчеләрне шаккатып тыңладык, һавага шарлар очырдык, флагчыкларны селки-селки, “Ура!” кычкырдык. Өйләргә таралышканда, без әле дә шул искитмәле яңалык тәэсирендә идек. Галя белән урамда туктап: “Ул космос дигәннәре кайсы төштәрәк икән соң аның?” – дип, зәңгәр күккә озаклап карап торганыбыз хәтердә.

Шулай итеп, бу мәктәптә көенечле-борчулы да, сөенечле-шатлыклы да хәлләр, вакыйгалар белән үрелеп барган бер ел сизелми дә үтеп китте. Беренче җәйге каникулымда ук авылга кайтырга атлыгып торсам да, абый каршы килде. “Русчаңны әле яңа яхшылап өйрәнеп киләсең, анда аны тагын онытырсың. Мин сиңа лагерьга ике (!) сменага путевка алдым, әйдә, шунда барасың. Июнь, август айларында лагерьда, июльдә – бабушкаңда ял итәрсең” – диде. Бетте-китте. Елап-елап та карадым, юк, абый кырт кисте. Шулай итеп, ул җәйне Бәзәкәмә, әни, дуслар янына кайтып рәхәт кичүләр миңа тәтемәде. Аның каравы “Полетаево” дигән лагерьда да начар булмады: бик әйбәт ял иттем, яңа дуслар таптым. Әле анда шәһәрдән һәм якын-тирә башкорт авылларыннан килеп эшләүче, җыештыручы, кер юучы, пешекче апайлар белән танышып, дуслашып өлгердем. Ә алар яннарына кергәләгән чакта мине татарча сөйләштерәләр (аларга тансык бит), җырларга сорыйлар. Мин җырлыйм үземчә, ә апалар, ни хикмәттер, мине тыңлаганда елап та алалар (әйтерсең, Фәридә Кудашева моңлана). Күңелләре нечкәргәндер инде. Соңыннан миңа пәрәмәч, я кабартма бирәләр.

Көзен тагын шул ук мәктәпкә, шул ук класска килдем. Ә ник 7 гә түгел? (“Икеле” түгел, “өчле”ләрем дә берничә генә чыкты. Шулай булгач, сөйләшү-килешү буенча мин 7 нче дә укырга тиеш бит). Үзем теләмәдем. Мин шушы “ж” классына ныклап ияләштем, кызлары-малайлары белән дуслаштым. Алардан аерыласым килмәде. Бу мәктәптә мин ике ел укыдым. Аннары туган авылыма кайттым һәм мәктәпне шунда тәмамладым.

Әмма күңелдә яраткан шәһәрем белән бәйле бер үкенеч калды.

Минем абый гомере буе мәдәният-сәнгать өлкәсендә эшләде дип әйткән идем инде. Ул эшли торган культура сараенда бик күп төрле түгәрәкләр дә бар. Беркөн шуларның берсенә, аккордеонда өйрәнү түгәрәгенә (баян түгәрәкләрендә урын калмаган булган) мине яздырып та кайткан абый.

Түгәрәк җитәкчесе, өстәлгә карандаш белән төрлечә суккалап, үзе артыннан миңа кабатларга кушып, минем "слух"ны тикшерде һәм түгәрәгенә язып та куйды.

Мин түгәрәккә йөри башладым: ноталар белән танышабыз, инде 1-2 җиңел көй дә өйрәнеп киләбез. Нәкъ шул вакытта, кирәк бит, абыйны Мәскәүгә ике айлык "100 танцев народов мира" дигән укуларга җибәрделәр. Ә мин, абый китүгә, 1-2 атна йөрдем микән, айлык акчаны түләдем дә, әллә нишләп, түгәрәккә бөтенләй йөрмәс булдым. Билгеле, кайткач хәлләрне белгән абый кирәкне бирде бирүен, тик эш узган иде инде. Менә шул җүләрлегем, уйлап бетерми кылган гамәлем өчен үземне гомерем буе кичерә алмадым. Чөнки мәктәптә, институтта укыганда, аннары 35 ел укытканда да (әле шуның 20 (!) елын җыр дәресләре укыттым бит!) берәр музыка коралында уйнарга өйрәнү ничек кирәк булды миңа. Үкендем, бик үкендем.... Әмма терсәк якын булса да, аны тешләп булмый икән шул.

Остазым Матрена әби

Квартира хуҗам – пенсия яшендәге урыс әбисе. Фатиры – ике бүлмәле, чиста-пөхтә, бик уңайлы. Әбиемнең исеме генә әйтү өчен миңа җайсызрак тоелды. Матрена Никифоровна. Минем кыеннан әйтеп маташуымны чамалаган әби: "Рая, (ул миңа русчалап шулай дәште) называй меня просто бабушкой", – диде. Бабушкам мине иртән уята, ашата, мәктәпкә озатып кала, ризык пешереп каршы ала. Ә иң мөһиме: мине русча сөйләштерергә тырыша (әллә аңа шулай эшләргә абый кушкан булдымы икән дип тә уйлый идем). Төрле сораулар бирә, мәктәп хәлләрен сораштыра, хәтта безнең милләткә генә хас булган гореф-



гадәтләр, йолалар турында сүз кузгата. Ягъни, аңа белү бик кызык икән: бездә ничек балага исем кушалар, ни рәвешле никах укыйлар, нинди бәйрәмнәребез бар, ашмәҗлесләрне ничегрәк уздырабыз һәм башкалар.

Ә мин, үз чиратымда, әбигә урысчалап сөйләгән, аңлаткан булам. Род, падеж, окончаниеларны исәпләмәгәндә, "ничава" гына килеп чыга бугай, чөнки әбием, аңлаганын белдереп, баш кагып утыра. Кайчак төшенеп җитмәгән булып, әле кабат-кабат сөйләтә дә.

Бу урында әйтеп китәргә кирәк, әби үзе дә тормышы, балалары, элек эшләгән эше, русларның тормыш-көнкүреше турында бик мавыктыргыч итеп сөйли. Үз-үзен тотышы, сөйләү алымнары, шаян фразалары, җор сүзләре нәкъ оста артистныкы инде менә! Аның җанлы да, гыйбрәтле дә тормыш дәресләре йөрәгемә сары май булып ята иде.

Менә бер кичне әби, мине рус теленең тагы да тирәнрәк катлауларына алып төшмәкче булыптыр инде, сорап куймасынмы: "А как у вас людей хоронят?" Әстәгъфирулла, тәүбә-тәүбә... Ишетмәсәң ишет. Кайлардан белим инде мин ул кадәресен? Әйтерсең лә мин, 14-15 яшьлек кыз бала, мәет озату эшләрендә катнашкан кеше. Алай да, сынатасы килми. Аннары, болар безнең милләткә кагылышлы гамәлләр, ничек "белмим", дип утырасың инде. Аллага тапшырдым, дип әниләрдән ишеткән-белгәннәрне тотындым сөйләргә. Урысчалап-татарчалап алай дим, болай дим, ык-мык итеп торганнарын әби үзе әйткәләп җибәрә. Ниһаять, күмү йоласының азагына – кабергә төшерүгә килеп җиттем һәм... төртелдем. Һич кенә дә әбигә ләхет сүзен урысча әйтә алмыйм бит. Ә әби сорауларын һаман яудыра.

– Ну, раз у вас хоронят без гроба, то землю прямо на покойника кидают что ли?.

– Нет, нет, там еще есть... Ну, яма другая.

– Какая яма? У вас что, две могилы получается?

– Ну, нет, бабушка, одна могила. Но рядом есть еще... ну, вот это... Ну, как же сказать по-русски?

– Ничего не пойму, – ди әбием һаман.

Шунда мин, башыма барып җитеп, тиз генә карават

астына сузылып кереп яттым.

– Вот так ложат, – дидем.

– А-а-а, вон как у вас. Значит, еще подкоп делают, да? – диде, ниһаять, төшенеп җиткән әби.

– Да, да - мин әйтәм, - подкоп, подкоп, бабушка. – Аллага шөкер, тәки аңлаттым бит, – дия-дия, җиңел сулап, бик канәгать булып карават астыннан чыктым.

Менә шулай әбием минем өйдәге укытучыма, остазыма әверелде.

Менә тагын бер очрак. Өйдә берүзем. Әбинең оныгы Женя килеп керде.

– Здравствуйте. Бабушка дома?.

– Нет. Куда-то ушла.

– Давно?

– Нет, не давно' (басымга игътибар ит).

– Неда'вно, да? – дип кабатлады малай.

– Да, неда'вно, – дип жавапладым мин, хатамны аңлап.

Күрәсезме, хәтта үсмер малай да хатамны игътибарсыз калдырмады. Юк, дөрес әйтмәдең, димәде, ә уңай гына, ипләп кенә ничек дөрес әйтергә кирәклекне кисәтте, төзәтте.

Гомумән, урыс әбием дә, аның оныклары, якыннары, башкалар да – һәркем үзенчә, үз алымнарын кулланып, миңа рус телен өйрәтүдә гаять зур ярдәм иттеләр, минем сөйләм телемне хәйран гына чарладылар. Рәхмәт, чиксез рәхмәт аларга!

Туганнарым шунда яшәү сәбәпле, үз гомеремдә Чиләбе каласына бик күп мәртәбәләр барырга туры килде миңа. Һәр баруымда мәктәбем, яшәгән йортым яныннан тыныч күңел белән үтеп китә алмый идем. Күңелемне ниндидер якты бер моңсулык биләп ала да, хәтер дәфтәремнең битләрен ачам да, ерак үткәннәремә кайтам: нәрсәдер эзлим, сагынам, юксынам... Яхшылык җирдә ятмый, диләр. Шулай икән. Бу шәһәрдә яшәп укыган гомерем вакыт бизмәнендә бик кыска бер мизгел. Шушы кыска гына мизгелдә дә миңа карата күрсәтелгән яхшылык, игелекләр инде 50 елдан артык хәтердә сакланалар, аңымны-җанымны җылыталар һәм искәртеп торалар кебек: бер-беребезгә мәрхәмәтле, игелекле булсак икән.


Барыбыз да җирдә кунак кына бит...

Стоп! Красныйга кермәскә!

Тормышта кешегә кайчак көтмәгәндә-уйламаганда сайлаган һөнәрен, яраткан эшен алыштырырга, белмәгән-күрмәгән өр-яңа урында хезмәт куярга, үзен сынарга, күрсәтергә туры килә. Минем белән дә берара шулай булды.

Әйбәт кенә укытып йөргән җиремнән мине авыл Советы рәисе итеп сайлап куйдылар. Менә сиңа мә! Әле кичә генә минем янәшәмдә кара такта, кулымда акбур, каршымда йотлыгып дәрес тыңлаучы укучылар иде, ә бүген – берүземә бер бүлмә, кулда "гербовой" пичәт, алда өстәл тулы кәгазь, кәгазь, кәгазь... Я, Хода, ничек эшлисе булыр?!

Ә бит эшләнелде. Өч елга якын без, авыл Советы коллективына кергән алты хатын-кыз (рәис, секретарь, бухгалтер, хисапчы, бухгалтер ярдәмчесе, җыештыручы), бер йодрык, күмәк көч булып эшләдек, яшәдек. Яңа эш кызыклы да, авыр да иде. Безнең авыл Советына биш торак пункт керә. Һәрберсенә барырга, кешеләр белән очрашырга, гозерләрен тыңларга, проблемаларны ничек тә уңай хәл итәргә һәм тиешле ярдәм күрсәтергә кирәк. Бу эштә миңа авыл Советы апалары зур ярдәм күрсәтте.



Беренче көнне үк секретарь Нәкыя апа Шакирова документация белән таныштырды: нәрсә ул сессия, исполком, төрле комиссияләр, аларның эш планнары, протоколлар, керүче-чыгучы документлар, телдән һәм язмача жалобалар һәм башкалар. Ой-һай, биредә кәгазь боткасының боткасы икән!

Менә шуларны аңларга, төзергә, язарга, карарлар чыгарырга, аларның үтәлешләрен тикшерергә, депутатлар, ветераннар белән ничек эшләргә – һәммәсен белергә, аңларга үтә ипле, сабыр, җайлы кеше – Нәкыя апа өйрәтте, төшендерде.



Ә Шәргыя апа – баш бухгалтер. Нәкыя апаның капма-каршысы: җор телле, туры сүзле, үтә җитез, әкрен исә белми торган җил-давыл кебек апа. Ул мине бухгалтерия, ягъни исәп-хисап өлкәсендәге нечкәлекләр белән таныштырды. Аның һәм хисапчы кыз Рәүфә Хөрмәтуллина ярдәме белән гомеремдә беренче тапкыр "Смета" дигән нәрсәне төзергә өйрәндем. Алар бюджет акчаларын бик төгәл һәм тиешенчә генә файдаланырга кирәклекне, бер статьяның акчасын икенчесенә тотарга ярамаганлыкны миңа гел искәртеп тордылар. Бер учрежденеңең тотылып бетмәгән акчасын икенче учреждениегә тотарга уйласаң, яки икенче яртыеллыкның акчасын быел файдаланырга теләсәң, Шәргыя апа шунда ук: "Стоп! Красныйга кермәскә!" – дип кисәтә иде.

Бухгалтерия составы – Шәргыя апа, Рәүфә, Илсөяр Нуретдинова һәм техничка Венера Хуҗиәхмәтова белән күрше авылларга налог, самообложение акчаларын җыярга бара идек. Җәяүләп тә, ат белән, юл уңаенда колхоз машинасы белән дә – ничек туры килә, шулай йөрдек (хәзергә кебек выжлап кына йөрергә үзенең машинасы юк иде ул вакытта авыл Советының). Шулай булуга карамастан, бик еш бардык без ул авылларга. Кешеләре белән клубта яки кибет янында очрашулар оештырдык, халыкның җыелган ah-зарларын тыңлап, бездән торган һәм булдыра алган кадәр ярдәм күрсәттек.

Авыл Советында эшләүнең иң кыены дип мин халык белән шәхси эшне атар идем. Ягъни: берәү баш ташлап эчә, гаиләсенә көн күрсәтми, икенчесе күршеләре белән тынышмый, кемдер урлаша яки җәмәгать урынында тәртип боза һәм башкалар. Менә шуларны тикшерергә, һәр якны тыңлап, дөрес нәтиҗәгә килергә, каршы якларны килештерергә, үгетләргә, оялтырга һәм кайчак милиция



дә чакырырга туры килә иде, Һәм, һәрвакыттагыча, тәҗрибәле өлкән апаларым ярдәме белән без бик күп четерекле ситуацияләрне уңай хәл итә идек. Арысак, талчыксак, Шәргыя апа: "Әйдәгез әле, кызлар, бераз ял итеп алыйк", – дия иде дә, матур итеп җырлап җибәрә яки, берәр кызык хәл турында сөйләп, бар арыганлыкларны онытыра иде.

Авыл Советында рәислек иткән елларым Горбачевның «Коры закон»ы чорына туры килде. Кибеттә аракы саттырмаганым өчен үземне усал, каты, икенче Маргарэт Тэтчер дип атадылар, ЛТПга (лечебно-трудовой профилакторий) исерекләрне җибәрмәгәнем өчен, ничә мәртәбәләр «коверга» басарга туры килде.

Мин авыл Советы рәисе булып озак эшләмәдем, өч елдан соң кире үз эшемә кайттым. Әмма шушы вакыт эчендә дә мин, халык тормышы белән бер казанда кайнап, шуны аңладым: син әллә нинди оста җитәкче булсаң да, иң элек халыкка якын бул, һәркемне тыңлый һәм аңлый бел, йөз чөермә, киресенчә, кеше хәленә кер, зыян салма, ярдәмеңнән мәхрүм итмә.

Әйе, мин дә холкым белән бүләк түгел. Әмма дөреслек, гаделлек өчен чәчрәп чыгам, кемнедер кимсетү, түбәнсетү кебек күренешләргә каршы күтәреләм. Күпләр хәтерлидер, балалар мәнфәгатен яклап, бер август киңәшмәсендә меңгә якын укытучылар алдында сәхнәдән торып район башлыгына каршы чыктым. Моны коллегалар хәтәр адым дип бәяләделәр. Ләкин мин башкача булдыра алмыйм. Шунлыктан тормышымда күп кыенлыклар «ашарга» туры килсә дә, намусым ничек куша, шулай эшлим... Сүтеп кире җыйсалар да, мин шундый булып калачакмын.

85-87 нче елларда бергәләп эшләгән Бәзәкә авыл Советы коллективы миңа эшемдә ярдәм итте, теләктәшлек белдерде, киңәшләр, үзенчәлекле тормыш сабаклары бирде.

Ихлас күңелдән рәхмәт сезгә, апалар, кызлар!

Үзем турында сүзем

Укытучылар, остазлар, ягъни тормыш сабакларын бирүчеләр турында язмамны төгәлләп килгәндә, үзем турында да бераз әйтеп китим.

Ни әйтсәң дә, мин дә бит шушы авылда, шушы мәктәптә 35 еллап мөгаллимә булдым, балаларга аң-белем, тәрбия бирдем.

Мәктәпкә килә-килешкә үк башлангычта Зәйтүнә апа укыткан 5 нче сыйныфны җитәкләүне миңа тапшырдылар. 9-10 нчы сыйныфларда (Рәфиснур Шакиров, Нуриәхмәт Гыймадиев, Фәрит Бәшәров, Мөнирә Бәхтегәрәевалар укыган сыйныфлар иде ул) рус теле һәм әдәбияты, башка сыйныфларда татар теле укыттым. Үзеңне укыткан педагоглар белән эшләве авыр диләр, әмма мин ничектер, алай кыенлыклар сизмәдем: җиң сызганып, тырышлык-



“Яшьтәш” дружина советы. 2003 ел



ны, белем һәм фантазияне, ихтыяр көчемне бергә туплап, туган мәктәбемдә зур теләк белән эшләп киттем. Кайту белән диярлек миңа профсоюз оешмасының мәдәният комиссиясен җитәкләүне йөкләделәр, соңнан, ун еллап, шушы оешманың рәисе булып эшләдем.

Мәктәптә хезмәт куйган еллар дәвамында никадәр дәрес бирелде, күпме дәфтәр-көндәлекләр тикшерелде, ничә җыелыш үткәрелде икән дә, ничәмә-ничә укучыны олы тормыш юлына чыгардык икән – билгесез!

1980 елда өлкән вожатый Әдия апа Ибраева лаеклы ялга киткән чакта мине үз урынына тәкъдим итеп, болай диде: “30 еллап шушы эшемне яратып башкардым, бары сине генә үз урыныма лаеклы алмаш дип саныйм, эстафетаны тыныч күңел белән сиңа тапшырам”.

Һәм шул көннән мин дә, лаеклы ялга киткәнче, гомуми 35 еллык педагогик стажымның 25 елын балалар оешмасына багышладым (эшем укыту белән бергә параллель алып барылды). Үз эшемне яратып, җаным-тәнем белән бирелеп, аның нечкәлекләрен аңлап, белеп һәм теләп башкардым, йөзләгән балаларны үз артымнан ияртә алдым. Балаларның һәр эшкә җитди карап, һәр чарага зур тырышлык куеп, иҗади якын килә белүләрен булдырырга тырыштым. Һәр балада тумыштан нинди дә булса бер сәләт була. Менә шул кечкенә генә сәләтне нәкъ вакытында күрә белергә, үстерергә, баланың үзендә булдыра алуына ышаныч тудырырга кирәк! Мин нәкъ шулай эшләдем дә. Шунлыктан, өчлегә генә укучылар да оешмада бөтенләй икенче яклары белән ачылып киттеләр.

Ул елларда балалар белән нинди генә эшләр башкарылмады: ялкынлы пионер сборлары, дружина советы утырышлары, һәр елны җәйге лагерь оештыру, учаклар ягу, смотр концертлары, строй һәм җыр конкурслары, тематик кичәләр, спорт ярышлары, тимурчылык эше, кәгазь һәм металл ватыкларын җыю, ветераннар белән очрашулар, фермаларда, кыр станнарында чыгышлар ясау, слет-фестивальләр, экскурсияләр, туган як тарихын өйрәнү, район һәм республика иҗади бәйгеләрендә катна-

шу һәм башкалар. Боларны санап бетерү мөмкин түгел. Һәр уңышка ирешү өчен күпме көч, энергия, түземлек, эзләнүләр, вакыт сарыф ителгән, һәр җиңү борчу-мәшәкатьләр, йокысыз төннәр, хәтта сәламәтлек бәрабәренә яуланган. Әмма мин эшемнән беркайчан да зарланмадым, авыр, дип уфтанмадым. Киресенчә, балалар белән бергәләп ирешкән уңышлар, яулаган җиңүләр тәэсирендә кичергән сөенеч-шатлыклар белән эшләвемә һәм яшәвемә әле бүген дә куанып бетә алмыйм.

Мин эшли башлаган елларда мәктәбебездә балалар күп иде: 500-600 укучы укыган чаклар булды. Икешәр смена укыттык. Өченчесенә кичке сәг. 7 дә килә идек. Монысы инде төрле әзерлекләр, репетицияләр, консультацияләр. Алны-ялны белми эшләүнең нәтиҗәләре дә күркәм булды. 1984 елда миңа "Вожатый-инструктор", 1990 елда Министрлыкның "Өлкән вожатый-методист" исемнәре бирелде. 1995 елда, укытучыларның һөнәри бәйгесендә җиңеп, "Ел укытучысы" булдым.



Рәмзия Мөхетдинова – Ел укытучысы. 1995 ел

Башка елларда берничә мәртәбә "Ел вожатые", "Елның өстәмә белем бирү педагогы" исемнәрен яуладым. 2002 елда, балалар хәрәкәтенең 80 еллыгы уңаеннан, республикабызда беренче булып, Татарстан Республикасы варислары берлегенең "Балаларга тугрылык өчен" дигән Александр Денежкин исемендәге премия лауреаты булдым. Бүгенге көндә дә шушы исемдәге Шәфкатьлелек Ордены (Орден Милосердия) белән хәбәрләшеп торам.



2004 елда мәгариф системасында күрсәткән фидакарь хезмәтләрем өчен “Россия Федерациясенең гомумбелем бирү өлкәсендәге шәрәфле (почетлы) хезмәткәре” дигән күкрәк билгесе белән бүләкләндем.

90 нчы елларда, пионер, комсомол оешмалары бетерелгәч, мәктәптә оешманы саклап кала алдым. Балалар өчен “Мәктәбем – туган йортым”, “Без тарихта эзлебез” дигән эзләнү-өйрәнүгә корылган юнәлештәге экспедицияләрне башлап җибәрдем. Балалар белән туган ягыбызның, авылыбызның тарихын, аның танылган, зыялы кешеләре, аларның һөнәрләре, йолалар, бәетләр, чигү-бәйләү күнекмәләре, авылыбызга хас йорт, капка, тәрәзә йөзлекләре белән таныштык, өйрәндек, белдек. Тырыш, хезмәт сөюче халкыбызга сокландык, горурлык хисләре кичердек.

Авылдашыбыз Марсель Гыймазетдиновның якты истәлегенә багышлап 1994 елда, ягъни вафатына нәкъ бер ел тулуга, үземнең 10 нчы сыйныфым белән (Фәридә Бәхтегәрәева, Айгөл Мөхетдинова, Әнисә Идаева һәм башкалар) әдәби бүлмә булдырдык. Аның күп экспонатын, язма, фото, шәхси әйберләрен бөртекләп җыйдык. (Бүлмәне ремонтлау, агарту, чистарту эшләрен бер каршылыксыз техничкаларыбыз Сания Гатауллина һәм Нәсимә Мөхәмәтдинова тиз арада башкарып чыктылар. Зур рәхмәт аларга). 1999 елда Мәгариф министрлыгы комиссиясе бу бүлмәгә 306 нчы номер астында “Татарстанның мәктәп музее” дигән статус бирде, 10 елга якын вакыт эчендә биредә бик күп чаралар үткәрдем: әдәби кичәләр, шигырь бәйгеләре, шагыйрьнең туган һәм вафаты көннәренә багышланган чаралар, очрашулар. Шагыйрь музеенда йөзләгән тамашачы булды. Шулар арасында Татарстанның Дәүләт Думасы депутаты, драматург Туфан Миңнуллин, язучы Нәбирә Гыйматдинова, юморист язучы Нәҗип Мадьяров, шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин, Фазыл Шәех, министрлык вәкилләре, районның “Ядкарь” әдәби-музыкаль берләшмәсе әгъзалары һәм башкалар.

Ә бүген музей-бүлмә юк инде. Мәктәп җитәкчелегенең битарафлыгы, кирәксенмәве нәтиҗәсендә юкка чыкты ул.

Алдынгы, җиңүче укучы-пионерларны Казанга, Ту-



Т.Миңнуллин, Н.Гыйматдинова, мин – язучының “улы” Кәрлә образында. 1999 ел

кай-Кырлайга (1994 ел), Болгарга (1997, 2003 елларда), Иж-Бубый мәктәп музеена алып бардык. Бабаларыбызның изге Ватаны Болгарда үзем ижат иткән “Манаралар ауды бәгырьгә”... дигән композиция белән чыгыш ясап, 1 нче урынны яуладык һәм кыйммәтле бүләккә ия булдык. Җирле материалларга нигезләнгән бу чыгышыбызны милләтпәрвәрләр: язучы Фәүзия Бәйрәмова һәм бертуган Рәфис һәм Нәфис Кашаповлар югары бәяләделәр, рәхмәтләр җиткерделәр.



Бертуган Кашаповлар һәм Бәзәкә укучылары Болгарда. 1997 ел

2000-2005 елларда иң актив варисларым белән республикада җиңү артыннан җиңү яуладык, лауреатлар булдык. Шуның нәтиҗәсе буларак, Айгөл Садриева, Раил Сиражетдинов, Илмира Вахитовалар Кара диңгез буена, Анапа шәһәренә путевка белән бүләкләнделәр, ял итеп кайттылар. Казанның 1000 еллыгына багышланган иҗади бәйгеләрдә Марат Гыймадиев, Ландыш Хикмәтовалар республика буенча I һәм II урыннарны яуладылар, министрлыкның Мактау грамоталарына лаек булдылар.

Үзем җитәкләгән сыйныф кызларыннан (Ләйсән Галимова, Айназ Мөхетдинова, Айгөл Минишәехова, Гүзәл Хаҗиева) "Кызыл розалар" исемле вокаль ансамбль оештырган идем. Шушы ансамбль кызлары матур костюмнары, оста чыгышлары белән мәктәп коллективының, авыл һәм район халкының игътибарын һәм күңелен яуладылар. Җыр бәйгеләренең берсендә жюри рәисе, якташыбыз Вафирә Гыйззәтуллина, лауреат исеменә ия булган кызларыбызны кайнар котлап, киләчәктә дә татар халык җырларын пропагандалауда уңышлар теләгән иде.



"Кызыл розалар" ансамбле чыгышы

Бу кызлар бик оста биючеләр дә булдылар. Алар һәр бәйрәмгә җыр гына түгел, әле заманча бию дә әзерлиләр иде. Ул биюгә тиешле костюмнарын үзләре тектеләр, бизәделәр.

Аларны яшьләр "Бизякинский "Todos" дип атадылар, көчле кул чабулар белән каршы алдылар.



Кызлар заманча бию башкаралар

Шушы ук сыйныф белән Татарстан Варислары берлеге игълан иткән "Туган як серләре" экспедициясендә катнашып, "Сәйтәк үре – җенле урын" дигән темадагы ижади эшебез белән республикада беренче урынны алдык, ул турыда "Сабантуй" газетасы да язып чыкты.

2003 елда "Республикам Татарстан – бабамнар җире" исемендәге республика бәйгесендә лауреатлар булдык. Мәгариф министрлыгының приказлар җыентыгында эшебезне "ижади, оригиналь якын киленгән" дип, югары бәяләгәннәр иде.

Мәгариф системасында эшләгән чорда шәхсән үземә дә күп мәртәбәләр конкурс-бәйгеләрдә катнашырга, җитәкчеләр, коллегалар алдында тәжрибәм, эш алымнарым белән уртаклашырга, сәхнәләрдә, халык алдында "артист" булырга да туры килде.

Әйе, гомеремнең бер яртысы мәктәптә, икенче яртысы сәхнәдә, халык, тамашачы алдында узды диярлек. Иң әүвәл мине сәхнәгә балалар бакчасы тәрбиячесе Минямал апа Зиннәтуллина (инде мәрхүмә, урыны оҗмахта булсын) "Ун бәбкә" исемле шигырь сөйләргә менгергән иде, шул көннән башлап сәхнәдән төшмәдем дә бугай. Укыган, укыткан



Марсель Гыймазетдиновка багышланган “Якташлар-сәнгатьтәшләр” кичәсе. 1998 ел

елларда нинди генә тамаша, концерт-спектакльләр, тематик кичәләр оештырырга туры килмәде?! Күбесенең сценарий, композицияләрен үзем яздым, үзем әзерләп сәхнәгә куйдым. Кечкенәдән үк тавышым көчле, аһәңле иде. Шигъри әсәрләрне сәнгатьле сөйли белү сәләтен, әсәрнең иң нечкә, хисле урыннары аша тыңлаучының күңеленә ничек тәэсир итәргә кирәклекне тоемлау бар иде үземдә. Менә шушындый сәләт-халәт, халыкка рухи азык бирү теләге мине һәм сәнгать сөюче хезмәттәшләремне яшь буынны тәрбияләүдә матур да, отышлы, мәгънәле, файдалы да әсәрләрне сәхнәдән халык игътибарына җиткерергә гел өндәп, чакырып тордылар. Чыгышларыбыз һәрчак “аншлаг” белән узды (нәкъ өлкән буын укытучыларыбызныкы кебек). Без юмор-сатирага корылган җиңел әсәрләр түгел, ә заманның актуаль проблемаларын күтәрүче Т.Миңнуллин, А.Гыйләҗев, Ә.Атнабаев, Р.Батулла әсәрләрен “яуладык”. Җиңүләребезнең, уңышларыбызның башында театр белгече, режиссер апабыз Лариса Сәйфуллина торды (бүгенге көндә мәрхүмә, урыны җәннәттә булсын). Колхоз рәисе, үзе дә сәхнә сөюче кеше Ибраһим Галимов аны безнең өчен махсус Казаннан чакырта иде. Апабыз безгә үз роленә ничек керергә, сәхнәдә үзеңне ничек тотарга, ни рәвешле сөйләргә, еларга кирәклекне өйрәтте, төшендерде. "Ышанмыйм!" дип, кат-кат бездән дөрес уйнауны таләп итте. Мин беркайчан да вакыт тарлыгын, эшнең күплеген сылтау итеп, “юк, катнашмыйм, булдыра алмыйм”, димәдем, кире-

сенчә, төп рольләргә алынып, аларны оста итеп башкарырга тырыштым.

Хәзер уйлап куям, ничек барысына да җитешкәнмен соң мин: мәктәп эше, өйдә ирем, өч бала, өлкән яшьтәге әни, мал-туар, ул чорда су, утынны кулдан ташыйсы. Шуның өстенә – сәхнә. Ничек моңа гаиләм риза булды икән? Хәер, риза булмыйча, иремне һәм балаларымны да үз артымнан сәхнәгә тарттым ич мин: гаилә ансамбле булып та, концерт-спектакльләрдә дә бергәләп катнаштык (3 балам да мәктәптә яхшы укыдылар, җәмәгать эшләрендә актив катнаштылар, өчесе дә югары белем алдылар).



Мөхетдиновлар гаиләсе – районда Тукай юбилеенда чыгыш ясый. 1986 ел

Бер елны без, авыл үзешчәннәре, театр коллективларының II Бөтенроссия смотры кысаларында үткәрелгән бәйгедә катнашып, Мамадыш каласында Казаннан килгән мәртәбәле жюри алдында чыгыш ясадык. Спектаклебез бетүгә, сәхнәгә бер ир-ат менде.

– Мин – режиссер Празат Исәнбәт. Чыгышыгыз миңа шулкадәр ошады, сезне зур уңышыгыз белән шәхсән үзем котларга булдым. Образга керә белеп уйнавыгыз, сайлаган көйләрегез, бизәлеш-декорацияләрегез дә искиткеч матурлар (рәссамыбыз – авылдашыбыз Фәрахи абый Хуҗиәхмәтов иде). Ә бер спектакльдә бер гаиләдән өч кеше уйнау – бик күркәм һәм сирәк күренеш (бу әсәрдә ирем, үзем, 5 нче сыйныфта укучы кызыбыз Айгөл уйнаган идек). Рәхмәт сезгә, сезне Казанда көтәбез.

Тик Казанда чыгыш ясау насыйп булмады, чөнки районда, ниндидер максатлардан чыгып, безне җибәрмәскә булганнар.

Лариса апа вафатыннан соң да халык алдында чыгышларыбызны туктатмадык, ел саен зур-зур әсәрләрне сәхнәдә



куя тордык. Боларында инде режиссерлыкка үзем алындым. Чыгышларыбызны халык яратты, шулай ук алкышларга күмде. Ә без, мәктәп "артистлары", халыкка гүзәллек, матурлык бүләк итүебезгә сөенеп, шатлыклы минутлар кичердек, бөтен ару-талуларыбызны да шундук оныта идек.

Шаулап-гөрләп үткән мәктәп елларыма әйләнеп карыйм да – җиңел сулап куям. Әйе, гомер юлым туры, намуслы булды, тырыш хезмәт, балалар тормышы белән бергә үрелеп, алар язмышын хәстәрләп, матур, мәгънәле һәм лаеклы үтте дип әйтә алам. Чөнки үзем белем биргән укучыларымның рәхмәтен һәм хөрмәтен көн саен дияр-лек ишетеп, күреп, тоеп яшим. Менә бер-ике мисал.

Юраш мәктәбендә үк укыткан укучым Әлфия Садыйкова (хәзер ул Җиһангәрәева, Песәй мәктәбендә укыта, алдынгы педагог) һәр елны диярлек мине Укытучылар көне белән котлый, чәчәк-бүләкләрен күтәреп өемә килеп җитә, район газетасында мактап мәкалә-котлаулар яза. Укытучы өчен бу бәхет түгелмени?! Рәхмәт сиңа, тәүге укучым.

Шушы ук мәктәптә эшләүче укучым Наил Тимербаев та (Наил районда билгеле кеше: эзләнүчән, тырыш, укымышлы зат, авылдашлары турында берничә китап чыгарган автор) нәкъ шулай эшли: котлый, рәхмәтләрен җиткерә, очрашкан саен хәл-әхвәлләрне, сәламәтлекне сораштыра "И-и, Апа, инде миңа 50 яшь тулды, ә сез һаман яшь, безне укыткандагы кебек", – ди ул. Зур рәхмәт яусын сиңа, Наил, шундый тәмле телең, җылы сүзең белән мине "яшәрткәнең" өчен.

Менә тагын бер очрашу. Декабрь. Тышта 30^0 салкын. Кайдандыр өемә кайтып киләм. Каршыма, кулларын сузып, елмаеп, бер ир-егет килә.

– Исәнмесез, Апа. Мине таныйсызмы? Сез безне укыткан идегез. Мәктәп бетергәнгә, Сезне күрмәгәнгә нәкъ 33 ел гомер узды. Сезне гел күрәсем килеп йөрдем, берничә мәртәбә сугылганым да булды, тик Сез авылда юк чакка туры килдем. Ниһаять, менә бүген очраштык. Апа, рәхмәтләремне җиткерим дип килдем яныгызга. Менә сезгә Мәскәү күчтәнәче алып килдем, мин башкалада яшим бит.

– Әйе, танырмын, 9-10 "В" сыйныфларында укыттым

мин сине, Илфат Мөхәммәтгалиев, син Әтәс авылыннан бит. Тәрәзә янында беренче партада утырган кечкенә генә буйлы, җор телле, бик җитез малай идең үзең.

– Апа, хәтерлисезме, бервакыт без, сыйныф малайлары, сезгә дәрес алып барырга комачау итәргә булдык, имеш, сез яшь укытучы, нишләрсез икән... Сез бераз түзеп тордыгыз да, чыгып, тиз генә Гаян апаны алып кердегез. Ә Гаян апа безнең өчен – ут, яшен! Әй, "пешерде" дә соң безне өлкән укытучыбыз. Барыбыз аягүрә бастык, башларны идек, тирләдек-пештек... Сездән гафу үтендереп, Гаян апа чыгып китте. Ә сез дәресне өзмәдегез, дәвам иттегез. Ул вакытта классыбыз белән гафу үтенсәк тә, барыбер сездән оялу, кыенсыну хисе күңелемдә бик озакка калды. Шәхсән үзем инде ничә еллар сездән гафу үтенәсем килеп йөрдем. Менә бүген, алдыгызда баш иеп, шул кылган җүләрлегебез, ялгышыбыз өчен үзем һәм сыйныфташларым исеменнән гафу итүегезне сорыйм. Кичерегез безне, апа...

– Илфат, укытучы укучыларын һәрчак кичерә ул. Алга таба дәресләрдә тәртипле булдыгыз бит, димәк хата-ялгышларыгызны аңлагансыз, мин дә күптән кичергәнмен инде сезне. Ә шуклык-шаярулар була инде ул мәктәп тормышында. Иң мөһиме – тормышыгызда хәтәр, куркыныч ялгышулар була күрмәсен.

Менә шулай матур гына сөйләштек, гәпләштек без укучым белән, ул миңа адресын, телефон номерларын биреп саубуллаштык. Чиксез рәхмәт, уңышлар үзеңә, Илфат.

Бәзәкәдән бик актив пионерым, тырыш, алдынгы укучым Рәхилә Мөхәммәтханова да (хәзер Мирзаянова, район газетасы редакциясендә эшли, уңган-булган зат, оста журналист) җай чыккан саен, шәхсән мине һәм үзен укыткан укытучыларны ихлас күңелдән тәбрикли, котлый, истәлекләр яза, хезмәтебезне олылап, матур, күңелләргә хуш килердәй сүзләр таба. Мең рәхмәт, уңышлар сиңа, укучым. Язачак мәкаләләреңә, алачак интервьюларың кызыклы, мавыктыргыч, мәгънәле һәм игътибарга лаек булсыннар.

Ә хәзер язылачак очрашу, гомумән, хикмәтле дә, күңел кылларын тибрәндерерлек тәэсирле дә иде. Чөнки ул җирдә түгел, ә ...күктә булды.



... 90 нчы еллар башы. Без – ягъни мин, ирем, кече кызым Айназ, Чиләбе каласыннан Чаллыга самолетта очабыз. Пассажирлар утырышкан, салонда тынлык урнашкан. Бары стюардесса кыз, бер-ике мәртәбә яннан узып китте, һәм бер очучы ир-егет самолетның бер башыннан икенче башына барып килде. Үзе, ничектер, безнең якка да күз төшереп ала сыман тоелды. Менә ул кабат экипаж бүлмәсеннән чыкты һәм нәкъ безнең янга килеп туктады.

– Исәнмесез, Рәмзия апа, Рафис абый!

Без, ис-акылыбыз китеп, аңа күтәрелеп карадык. Ничек, безне күктә дә беләләрме?!

– Гафу итегез, сез безгә исем белән дәштегез дә, ә без сезне белмибез бит.

– Мин Юраштан. Рифнур Фазлыйәхмәтов булам. Рафис абый белән без күрше авыл егетләре ич. Ә сез безне укыткан идегез, апа. Белмәвегез дә бик мөмкин. Сез бит бездә кыска гына вакыт эшләдегез. Шулай да, мин сезне онытмадым, һаман да хәтерлим. Сез бик кыю, җитез, көчле тавышлы идегез. Ничә йөз баланы тыя, тыңлата ала идегез. Безгә бик матур кичәләр оештырдыгыз. Сездән ниндидер энергия бөркелә иде, менә шундый булып күңелгә, хәтергә уелып кереп калдыгыз.

– Җылы сүзләрегез өчен рәхмәт.

– Мин хәзер чыгам, – дип, егет кабат кабиналарына кереп китте һәм бераздан тагын безнең янга килде.

– Әйдәгез, безнең кабинага керәбез. Сезгә анда яхшырак булыр.

Без, ни дип әйтергә дә белмичә, кыяр-кыямас кына аның артыннан иярдек. Ишекне ачып торучы Рифнур безне эчкә әйдәде һәм, кулы белән дугасыман ишарә ясап, мине телсез-өнсез калдырды:

– Апа, алыгыз, мин сезгә зәңгәр Күкне бүләк итәм...

Я, Аллам, мондый бүләк тә була микәнни?! Ә мондагы илаһи зәңгәрлек, аклык-яктылык, иркенлек-киңлек!.. Без, баскан урыныбызда катып, таң калдык. Тагын бер генә адым алга атласак та, иксез-чиксез Галәмнең үзенә үк чыгып китәрбез кебек тоелды. Ике очучы егет безгә

елмаеп баш актылар. Ә Рифнур урыннар тәкъдим итте.

Менә шушындый сихри манзараны бүләк иткән очучы егетебез белән юл буе сөйләшеп-гөрләшеп оча торгач, вакыт үткәнен дә, Бегишево аэропортына кайтып җиткәнне дә сизми калганбыз.

Рифнур безне җиргә кадәр озата төште, исәнлек-саулык, уңышлар, бәхет теләп калды.

Укучым! Ни әйтим дә, синең шундый бүләгеңә каршы ни бүләк итим? Үзең теләп, яратып сайлаган биеклекләр, очкан-кочкан зәңгәр күкләр кадәр рәхмәтләр яусын сиңа. Җылы кояш, якты ай, аяз күкләр һәм уңай җилләр генә юлдаш булып, һәрчак имин очышлар язсын үзеңә!

Менә шушындый кадерле, онытылмас очрашу-күрешүләрдән алган тәэсирле-ләззәтле хисләр, бәхетле минутлар кичерү, ихлас күңелдән җиткерелгән рәхмәт-хөрмәтләр ишетү, укучыларым күңелендә минем өчен дә урын барлыгын тоеп-белеп яшәү – болар һәммәсе дә фидакарь хезмәтемне, куйган тырышлыкларымны югары һәм лаеклы бәяләү дип исәплим. Укытучы өчен укучыларыннан иң зур бүләк шушыдыр, мөгаен. Һәм бу бүләкне мин түрәләрдән сирәк-мирәк бирелгән 5-6 сүзле стандарт котлауларга һич кенә дә алыштырмыйм. Рәхмәт сезгә укучылар, инде без укытканнар...

“Үзем турында сүзем”не шушы урында тәмамлыйм һәм, кулымны йөрәгемә куеп, танылган педагог Сухомлинскийның канатлы сүзләренә кушылып, мин дә ышаныч белән әйтә алам: “Йөрәгемне балаларга бирдем”.

Салкын Себердән кайнар сәлам

Китап инде чыгарга әзерләнеп беткәндә, миңа заказлы хат килеп төште. Әле кайдан дигез? Ерак Себердән. Бу хатка мин чиксез сөендем, чөнки анда миңа бик кирәкле фотосурәт бар иде. Фото дигәннән, укытучылар турындагы китап өчен миңа бик күп кешеләрне күрергә, сорашырга, белешергә туры килде. Шундыйларның берсе – Фәния апа Латыйпова (Кәримова)



булды. Бәзәкә кызы бүгенге көндә Красноярск краеның Железногорск каласында яши. Анда мәктәбебезнең кырыгынчы еллар азагында төшерелгән сурәте барлыгын ишеткән идем. Мин фото хуҗасы белән элемтәгә кердем. Озакламый ул миңа фотоны җибәрде (фото китапта беренче) һәм бик җылы, сагыну-саргаю хисләре белән тулы хат та язды. “Салкын Себердән кайнар сәлам“, дип башлана ул хат.

“...Сеңлем, Рәмзия. Син сораган фотоны җибәрәм. Берүк югалта күрмә, сакла. Ул бердәнбер, башка кешедә юк. Әнә күр, Вагыйз абыйлар тавыннан башлап, укытучылар һәм укучылар көн дә үтә торган юл аралыгы ничек оста итеп төшереп алынган анда: күперчек тә, мәктәп участогы, спортзал, Олы әби йорты, тауга менүче озын баскыч, без утырткан яшь каеннар – барысы да уч төбендә генә кебекләр. Күңелгә бик якын, тансыклар... Бу бит безнең мәктәбебез, без аң-белем, сабак алган, мөгаллимнәребез хәер-фатыйха биргән мәктәбебез.

Мәктәп дип сүз башлауга, укытучым Гаян апа Әюпова күз алдыма килеп баса. Минем иң яраткан, хөрмәт иткән укытучым булды ул. Миңа, сугыш ятимәсенә, җанын бирергә әзер кебек тоела иде. Югыйсә, барыбызга да шундый булган бит инде ул. Апабызга багышлап кайчандыр шигырь дә язган идем, 20 еллап элек. Укып кара әле

Соңарган рәхмәт

Сугыштан соң авыр еллар...
40 бала кабул иттегез.
Дәрестән соң өйләребезгә
Безне көн дә озата идегез.

Жыелышка килгән әнкәйләр
Чирек йомгакларын тыңлады.
*Ә соңыннан сезнең патефон**
“Әллүки” көйләрен уйнады.

Бик күбебез ятим идек,
Ач-ялангач йөрдек мәктәпкә.
Кайгы-хәсрәт баштан ашса да
Наз өрдегез безнең йөрәккә.

Ул көннәрдән күпме гомер узган,
Тиздән илле яшьне тутырам.*
Ә һаман да мәктәп елларын
Хәтеремдә барлап утырам.

Хат автор искәрмәсе: *16 тапкыр әйләндерә торган патефон иде ул
*Бу хат язылган вакытта авторга инде 70 яшь тулган

Әле дә булса күз алдымда:
Ярдәм итеп "лоскут" бирдегез.
Яңа бишмәт тегеп, киеп килгәч
Котлап миңа перо бирдегез.

Олыгайгач искә төшә икән,
Бала чакта гына аңламадык.
Сезнең биргән асыл киңәшләрне
Күңел биреп тыңламадык.

Рәхмәт, Гаян апа, Укытучым,
Чын йөрәктән белем бирдегез.
Барысы өчен сезгә телимен:
Шат, бәхетле, таза булыгыз.

Шөкер, бу шигъри рәхмәтемне Гаян апа укырга өлгерде.

Безне укытып чыгарган укытучыларның һәммәсенә зур рәхмәт юллыйм.

...Сиңа җибәргән карточканы мин зурайтып, баш очыма элеп куйдым. Аңа карамаган, сөйләшмәгән көнем юк. Чөнки фотода балачак һәм яшьлегем мизгелләре ярылып ята: бу сукмаклардан мәктәпкә йөрдек, каеннар шавы астында җырладык-биедек, тауларыннан җиләк җыйдык, тау астында гына булган Олы чишмә суларын эчтек, инешендә су кердек, керләр чайкадык...

Беләсеңме, сеңлем, туган җирне, авылны сагыну хисе кешегә шулкадәр көчле тәэсир итә, хәтта урамнарга чыгып китәсең, кешеләр белән очрашу, аралашулар эзлисең. Мин дә шулай, күргән-белгән танышлар, милләттәшләр белән очрашып-сөйләшеп, ансамбль төзедем һәм, үзебезнең инешебезне күз алдында тотып, аңа "Инеш" дигән исем бирдем. Бу ансамбль белән без кайларда гына булмадык та, Себернең нинди генә татар авылларында чыгышлар ясамадык! Үз телендә сөйләшергә зар булган, җыр-моңын бер ишетергә сусаган татар кешесенең хәленхаләтен күрсәң икән син. Аягүрә кул чабалар, чәчәкләрен сузып сәхнә янына киләләр, сүзсез генә үксиләр.. Мондый тетрәндергеч күренешне күргәнегез бармы сезнең, Татарстанда яшәүчеләр? Юктыр, юктыр шул... "

Укытуҫыларга рәхмәтем

Үзен укыткан укытучыларга чиксез рәхмәтләрен җиткерергә теләгә барлыгын миңа тагын бер кеше белдерде. Мин аның үтенечен кире кага алмадым. Сезгә аның да язмасын тәкъдим итәм.

– Мине, Нәҗметдинова (Бәхтегәрәева) Мөнирә-Әхмәтзәки кызын,1957 елның 2 февралендә әнием үз өебездә тапкан. Әтием, Бәхтегәрәев Әхмәтзәки Исмәгыйль улы, әнием, Бәхтегәрәева Нәгыймә Галимәхәммәт кызы, кечкенәдән үк аз сөйләп күп эшләргә өйрәттеләр. Шуңадыр ахрысы, мәктәптә укый башлагач та, бар нәрсәне дә тиз башкарырга тырыша идем.

1964 елда мәктәпкә Мәхмүтова Нажия апа сыйныфына килдем. Нажия апада бертуган апам Әлфинә дә укыган иде. Беренче укытучыма рәхмәтләрем зур. Аның турында кайда гына, кайчан гына булмасын, мактап сөйлим. Нажия апа башлангыч сыйныфларда укытыла торган барлык фәннәрдән дә нык белем бирде. Хәзер чагыштырып карыйм: Нажия апа чыгарган сыйныф укучылары "башкисәрләр" иде. Бу бары тик яхшы мәгънәдә, чөнки аның укучылары, Нажия апаның үзе кебек, җитез, актив, чая, тиз сөйләшә торган "тиктормаслар" иде.

Бишенче класста, ике сыйныф укучыларын бер итеп, безне Зиннур абый Гыйльфанов үз канаты астына алды. Яшь укытучы 42 бала утырган класска ничек килеп кергәндер, ничек итеп сыйныф җитәкчесе булгандыр – аңлата алмыйм. Бөтен авырлыгын үзе генә белгәндер. Зиннур абый "А" классының җитәкчесе, ә аннан соң мәктәп директоры булды , безне зур тормышка озатты. Хәтердә калган нәрсәләр бик күп, язып бетererлек түгел. Зиннур абый безнең өчен һәр яктан "камил кеше" иде: ул кием-салымы, йөреше, үз-үзен тотышы дисеңме, дәфтәрләре, журналлары, сөйләме, укучылар белән аралашканда тактлыгы һ.б. Зиннур абый мине аеруча ярата сыман тоела иде.

1974 елда, мәктәпне бетергәндә, алман теле укытучысы Фәйзелхак абый Хөснетдинов: "Мөнирә, тел өйрәнер-

гә һәвәслегең бар, әллә чит телләр факультетына барасыңмы?” – диде.

Шулай итеп, мин документларымны Алабуга дәүләт педагогия институтының чит телләр факультетына тапшырдым. Укытучымның акыллы киңәшенә һәм үз фәненнән төпле белем бирүенә бүген дә рәхмәтлемен. Бу факультетта уку дәверендә мин үземне бер башка гына түгел, өч башка югарыга күтәрелүемне сиздем, чөнки чит телләр өйрәнү белән бергә кеше башка илләрнең дә культурасын, тарихын, әдәбиятын өйрәнә, бөек кешеләре турында мәгълүмат җыя.

Бүгенге көндә, бөтен җирдә эштән кыскартылу чорында да, безнең өчен эш арта гына бара.Чөнки чит телләр өйрәнү бүген аеруча актуаль.

1979 елда Алабугада 69 нчы профессиональ-техник училищеда хезмәт юлымны башладым, алман һәм инглиз телләрен укыттым. Соңрак әйтеләсе сүзләремнең берсенә тукталасы килә. Училищеда 3 ел дәвамында химия укытыла иде. Бервакыт химия укытучысы белән кер юу порошоклары турында әңгәмә корып утырганда, ул минем химиядән шәп кенә чамалавымны ачыклады. Шулай итеп, мин дәүләт имтиханы комиссиясе члены булдым. Имтихан вакытында чит тел укытучысының химиядән сораулар яудырып, мәсьәләләрнең чишелешен тикшереп утырганына укучылар бик гаҗәпләнделәр. Фирая апа хезмәте бу!

Училищеда укыту дәверендә институтка еш кына эшкә чакырдылар. Кемдер чирләп китә, кемдер декрет отпускысына, кемнеңдер артыгын эшлисе килми.

1984 елда Алабуга дәүләт педагогика институтына күчтем. Югары уку йортында эшләү фән белән шөгельләнүне таләп итә. Бик ашкынып тормасам да, аспирантура бетереп, диссертация якларга туры килде. Фәнни җитәкчем, академик Кирсанов Анатолий Александрович (Казан) берничә чыгышында авылым укытучыларын мактап искә алды. Без аның белән бер ел эчендә зур эш башкарган идек. Мине мисалга китереп, укытучыларның барлык фәннәрдән дә төпле, нигезле белем бирә алулары-



на ышандырды ул. Чөнки фәндә тел дә, логика, уй-фикер йөртә белү тизлеге, анализлау осталыгы, математик чагыштырулар да бик кирәк.

1995 елдан Алабуга дәүләт педагогия институтында чит телләр кафедрасын җитәкләдем. Фән кешеләре арасында мөдир булып эшләү җиңел түгел. Институтыбызның ул вакыттагы ректоры Нәиб Хәбибнажар улы Ләисов мине дүртенче тапкыр үз янына чакыртып алгач, болай диде: "Мөнирә, син бит Бәзәкә кызы.Кайчандыр мин практикамны сезнең мәктәптә үттем. Бәзәкәлеләр бик җитезләр, кыюлар, бик белемлеләр бит. Шулай инде, эшли алырдай кешеләр карьера ясарга ашыкмыйлар, ә эшли белмәгәннәре ашкынып торалар. Ә ректор кеше өчен кафедра һәм факультетларны көчле, төпле белемле кешеләр җитәкләве бик мөһим." Минем мәктәбем турында шундый югары фикердә булган өлкән укытучының үтенечен кире кага алмадым.

Нәиб ага Бәзәкәдән бик күпләрне белә иде. Марсель Гыймазетдинов, Рәмзия апа Гыймазетдинова, Сәлахетдин Таҗиев, Мөхәммәтнур Сабитов, Рафаил Сабитов (Турай егете), Фәридә Бәхтегәрәева институтның йолдызлары булдылар. Алар да үзләренә белем биргән укытучыларына мең рәхмәтле.

...Гомерләр уза, уллар үсә. Фатир алу мәсъәләсе бик четерекле. Чаллы педагогика институтында чит телләр факультеты ачылды. Ректор Зиннур Шәрәфетдинов (инде мәрхүм) 2000 елда мине эшкә чакырды. Факультетның яңа аякка басып килгән чагы иде ул. Монда да күп эшләр башкарырга туры килде. Әйтәләр бит: "Эшләгәнгә эш язган". Биредә дә мин җитәкчемнең ышанычын акларга тырыштым, алны-ялны белми эшләдем.

2007 елда Германиядә стажировка үтү өчен конкурста катнаштым. Мәскәү комиссиясе алдында 3 имтихан тотарга туры килде. 2008 елда Берлинда Гумбольдт университеты каршында оештырылган институтта стажировка үтеп кайттым. Дәресләрнең берсендә бер укытучыбыз, Россиядәге белем бирү методикасын мактагач, Швейца-

риядән килгән коллегабыз миңа ачык дәрес бирергә тәкъдим итте. Күрәсең, тикшереп карарга булгандыр. Шулай итеп, Берлинның үзендә мин бөтен дөньядан килгән коллегалар алдында ачык дәрес бирдем – модаль фигыльләрне аңлаттым. Шаккаттылар. Күпме акча алуыбыз белән кызыксындылар һәм ... кычкырып көлделәр.

Инде экстерн рәвештә бөтендөнья сертификатының С2 пунктына (сертификат кешегә бик күп мөмкинлекләр ача) имтихан тотканда сорап куйгач, мин укытучым Фәйзелхак абыйның исемен атадым. Аның белән кызыксындылар, башларын чайкадылар. Чит илгә чыкмыйча гына телне шулай өйрәнү һәм өйрәтү - аларның башына сыймый. Сыйныфларны ике группага бүлмичә, һәрбер класста 30 дан артык балага белем биргән кешенең ни дәрәҗәдә хезмәт иткәнен инде үзем, олыгаеп барганда тагын бер кат аңладым.

Менә шулай итеп, мин бүгенге көндә дә укытучыларым биргән ныклы белем нәтиҗәсендә рәхәтләнеп яшим, күп эшлим, акча табам. Нажия апа Мәхмүтова нигез салган, Мәсгудә апа Мөхәмәтдинова дәрес саен мөстәкыйль эш эшләтеп, дәфтәрләрне һәрдаим тикшереп,татар теленнән безнең белемебезне тирәнәйткән. Ана телен яхшы белсәң – башкалары җиңел бирелә.

Башка төбәкләрдән килеп укыган студентлар безнең рус телен бик яхшы белүебезгә гаҗәпләнәләр иде. Рәшит абый Бәшәров Һәм Шәмсия апа Ибәтуллина хезмәтләре бу.

Фоат абый Көләчев дәресләрен методик яктан анализлый башласаң, ул гел проблемалы итеп укыткан икән. Мирза Исмәгыйлов проблемалы укыту теориясе белән бөтен дөньяда данлыклы галим. Бу теориянең эчтәлеге "Эшләп ашагыз әле", дигәнне аңлата. Ә Фоат абый безне чынлап та "эшләп ашарга" өйрәтте. Класс җитәкчесе буларак та аның тактлылыгы, һәрвакыт оптимистик карашы безне һәрнәрсәгә канатландыра иде. Мең рәхмәт, Фоат абый!

Гаян апа Әюпова дәресләренең ничек узганы һәрчак хәтердә. Тезислар формасында, пунктлап бирә иде ул информацияне. Ә тарихтан бик күп мәгълүмат белергә кирәк бит! Ул тезислар бүген дә хәтердә.



Чаңгы ярышыннан чабып килгән кызларга Кәүсәр Гыйльфанов белән Рифкать абый Тимеркәев кесәләреннән кәнфит алып бирәләр иде.

10 нчы класста укыганда, Зиннур абый диплом якларга киткәч, укытучыбызны Хәй абый Гыйльфанов алыштырды. Геометриядән 5 дәрес рәттән мине такта янына мәсьәлә чишәргә чакырды. Сыйныфташым Рифкать Гайнуллин түзмәде, болай диде: "Абый, Сез Мөнирәне 5 дәрес рәттән такта янына чакырасыз, ни өчен? Мөнирәне шулай нык яратасызмени?" Дәрес беткәч, Хәй абый мине чакырып алды да: "Мөнирә, чирек бетеп килә. Миңа билге чыгарасы бар. Мин Сезне тикшереп карарга булдым, ачуланмагыз!" – диде. Бу ысулны мин үземнең практикамда еш кулланам. Нинди тәрбияви ысул!

Мәүлидә апага – гербарийлар ясатып, мәктәп тәҗрибә участогында эшләткәне, Гәбделхәй абый Җиһаншинга – трактордан курыкмаска, (машинага права алырга җайлы булды), Зәйнак абый Әһлиевка – автоматны 30 секундта сүтеп-җыярга өйрәткәннәре, Шәрифҗан абый Ахуновка – гимнастик күнегүләре, Әхәт абый Төхвәтуллинга дәреслә рдә әйтеп куйган кызыклы "афоризмнар"ы өчен мең рәхмәтләр яусын.

Авыл баласының өйдә дә эше күп: мал–туар карарга, печән чабарга, утын кисәргә, көтү көтәргә, су ташырга, мичкә ягарга, гомумән, ир-ат һәм хатын-кыз эшен эшләргә кирәк. Дәреслекләр белән күмелеп утырган булмады. Язмача эшне генә өй эше дип кабул иттек. Анысын да я тәнәфес арасында, я эш аралай гына эшләп ата идек. Әмма укытучыларыбыз биргән белем безгә лаеклы яшәргә, аягыбызда нык басып торырга ярдәм итә.

Исәннәргә иминлек, саулык, озын шатлыклы гомер телим, фани дөньяга киткәннәрнең урыннары оҗмахта булсын.

Яр Чаллы педагогик институтының роман һәм алман телләре кафедрасы доценты Мөнирә Нәҗметдинова (Бәхтегәрәева).

Йомгаклау

Менә, соңгы җөмләне төгәлләп, нокта куяр вакыт та җитте.

Кадерле кешеләрем – укытучылар турындагы истәлекхатирәләр бәян итеп бетерелде. Китапны укып чыкканнан соң, кемдер минем уй-фикерләрем белән бәлки килешмәс тә. “Артык мактаган, укытучыларны күккә чөйгән”, дияр. Чөнки кайберәүләр баласы яхшы укыса, үз тырышлыгы белән укыды, начар укыса, укытучы балама үчекте, юньле белем бирмәде, дияргә ярата. Дөрес, һәр һөнәр иясе арасында яхшылары да, яманнары да җитәрлек. Ә менә мөгаллимнәрнең иң начар дигәне дә баланы кеше итәргә тырыша, югыйсә.

Әйе, мактап яздым. Чөнки алар моңа бик-бик лаеклы. Укытучы да гап-гади кеше бит. Аның да эче тулы ут янган, җаны кыйналган чагы була, ә ул һаман сабыр гына укыта, дәрес бирә, тәрбия кыла, үз баласына бирәсе мәхәббәтне күпме нарасыйга бүлә...

Кояшта да таплар була... Шуны онытмыйк һәм укытучы-тәрбиячеләребезгә мактау сүзләрен кызганмыйк. Чөнки изге хәдисләрдә дә әйтелгән бит: “Мәктәпләр һәм мөгаллимнәр – Аллаһының бер бүләгедер”, “Остазларның хакы ата-ана хакыннан ким булмас”.

Һәр сүзегез, дәресегез белән
Өйрәттегез дөнья танырга.
Ходай безне үзе бүләкләгән:
Сезнең кулда белем алырга.

Минем бу китабым безне укыткан, бүгенге көндә әле исән-сау булган мөгаллимнәребезгә олы рәхмәтем, чиксез хөрмәтем, инде арабыздан киткәннәрнең, мәңгелеккә күчкәннәрнең якты Рухына һәм Җанына изге дога булып ирешсен.

Амин!

Фото-ядкарьлэр



Укытучыларның төрле елларда төрле сыйныфлар белән төшкән фотолары



Укытучы Нурулла һәм Фәйзелхак абыйлар өлкән сыйныф укучылары белән. 1956 ел



Язгы имтиханнар алдыннан. 1958 ел



Өлкән сыйныф укучылары, укытучы Тажетдинова Мәүлия һәм практикантлар. 1958 ел



Укытучы Әминә апа һәм вожатый Флүрә Шакирова 4 сыйныф укучылары белән. 1960 ел



**Башлангыч укытучыларының киңәшмәсе.
Сулдан: Кәлимуллина Роза, Гатауллина Мәэлүфә,
Мәхмүтова Нажия, Бәдертдинова Әминә, Көләчева Мәрьям,
Гайнуллина Гөлсем. 1964 ел**



Фәйзелхак абый, Әдия апа һәм 1965 елгы чыгарылыш



Мәктәпнең ир-егет укытучылары: Җиһаншин Габделхәй, Ахунов Шәрифҗан, Насыйфуллин Фәрит, Көләчев Фоат, Тимеркәев Рифкат. 1973 ел



Зәйтүнә апа үзенең 4 сыйныфын бишенчегә озата. 1973 ел



Чыгарылыш 10 б сыйныфы укытучылары белән истәлеккә фотога төшәләр. 1974 ел



1975 елның май ае



Яшь һәм өлкән буын педагогларының истәлеккә төшкән фотосурәте. 1989 ел



Укытучылар коллективы. 1993 ел



1993/94 уку елының 1 сентябрь иртәсе



1955 елда мәктәпне бетергән укучыларның 45 елдан соң укытучылары белән очрашу тантанасы. 2000 ел



1965, 1966 елларда Бәзәкә мәктәбен тәмамлаган укучыларның 40 елдан соң очрашу бәйрәме. 2006 ел



1976 елгы чыгарылышның 30 елдан соң очрашу иртәсе. 2006 ел

Тәгәри гомер йомгагым...



Балачак мизгелләре... Бәзәкә балалар бакчасы. Мин – икенче рәттә, уңнан беренче. 1954 ел



Безне тәрбияләгән балалар бакчасы коллективы. Сулдан: Ш.Гөмәрова, О.Сабирова, Ш.Ибәтуллина, М.Зиннәтуллина, М.Җиһаншина. 1948 ел

Чиләбе каласында яшәгән вакыт



Дус кыз күршем Аля. 1961 ел, җәй



Апамда кунакта. Мин һәм дус кызым Нурания (Турайдан). 1965 елның җәе

Туган мәктәбемдә укыган чор



8 нче сыйныф



Гаугалы “чүмәлә”. 10 нчы сыйныф



Немец кызы җибәргән бүләкләрдән төзелгән стенд. 1965 ел



Мәктәптә алтынчы сыйныфта укыган чак. 1959 ел



11 нче сыйныф. 1966 ел

Студент еллары



“Миңа 20 яшь” дигән кичә. 1967 ел



1970 ел, 4 нче курс



1971 ел, 5 нче курс

Гаиләм



Тормыш иптәшем Рафис белән без инде 40 елга якын бергә



Улым Айдар һәм киленебез Ландыш



Кызым Айгөл ире Валерий һәм кызы Аделина белән



Кече кызым Айназ

Мәктәптә үткән гомер...



5 нче сыйныфым белән беренче үткәргән чарадан соң. 1974 ел



Казанда экскурсиядә. 1974 ел



Дружина советы әгъзалары. 1980 ел



Туган якны өйрәнүче “Мирас” түгәрәге әгъзалары. 1993 ел



Драма түгәрәге әгъзаләре чираттагы спектакльдән соң. 1993 ел



Республиканың зона смотрында беренче урын алган “Серле сандык” тамашасы. 1999 ел



Мәктәптән чыгарган соңгы сыйныфым. 2003 ел (сигез укучының алтысы югары уку йортларына керделәр).



Шушы сыйныфымның чыгарылыш кичәсе. Сулда: беренче укытучылары Лилия Ефимова, уртада – рус теле укытучысы Равилә Кәлимуллина. 2003 ел

Эчтәлек

Автордан..... 4

Мәктәп

Мәктәп..... 6

Мөгаллим

Илаһи зат – Мөгаллим 14
Көләчевлар династиясе 23
Укытучым минем. Иң беренчем... 23
Көләчева Мәрьям – ветеран укытучы 27
Таҗетдинова-Көләчева Мәүлия 29
Күңеле дөрес аның.....32
Олы йөрәкле кечкенә мөгаллимә.....37
“Апа-а-а, без Сезне көтә-ә-б-е-е-з” 39
Мәгърифәт нуры өләшүче 43
Балалары сынатмый.....45
Мөгаллимә Роза Кәлимуллина 48
Көчле математик 49
Ак хыяллар иясе.....53
Гомер юлы якты.....57
Фидакарь шәхес.....61
Аккоштай сылу зат.....66
Гомер язлары ел да кабатлана... 69
Балаларга багышланган гомер.....72
Иҗади эшләүче педагог.....77
Һәрчак хәрбиләрчә.....79
Өлкән буын укытучысы 83
Шатлык өләшүче Әдия.....86
Балалар һәм табигать дусты.....90
Бала җанлы мөгаллим.....94
Династия дәвамчысы 97
Уйный баян, уйный үзәкләрне өзеп... 99
Бала дөрес юл сайласын.....102
Тормышта кирәк булачак 106
Әйбәт апа 107
Яраткан мөгаллимебез.....110



Күбәләктәй саф күңел....114
Балалар бакчасы тәрбиячеләре....116
Тынгысыз эшсөярләр....117
Кадерле мөгаллимнәр, тәрбиячеләр....120
Алмаш буын....123

Югары бүләк ияләре

Атказанган укытучылар....126
Мәгариф алдынгылары....126
“Иң-иң”нәр....126
Галимнәребез....127
Атказанган исемендәгеләр....128
Погонлы якташлар....129
Сәхнә осталары....130
Рәссам кулында – бар җиһан....132
Укытучы күршеләр....134
Укытучы Тимеркәевләр династиясе....136
Сәләтле укытучы....138
Мари Тәкәше остазы....139
Чөмән буе укытучылары....140

Вуз еллары (1966-1971)

Институт....144
Тәүге адымнар....149

Тормыш сабаклары

Әни мәктәбе....153
Калада уку....154
Остазым Матрена әби....160
Стоп! Красныйга кермәскә!....163
Үзем турында сүзем....166
Салкын Себердән кайнар сәлам....178
Укытучыларыма рәхмәтем....181
Йомгаклау....186

Фото-ядкарьләр

Укытучыларның төрле елларда сыйныфлары белән төшкән фотолары....188
Тәгәри гомер йомгагым....196

Рәмзия Мөхетдинова

Укытучым, кадерлем...

Материалларны компьютерда җыючы **З.Д.Бәдретдинова**
Корректор **Р.К.Мирзаянова**
Калыпка салучы, фотоларны эшкәртүче **Г.М.Гыйләҗетдинова**
Тышлыкны бизәүче **А.В.Филиппов**
Фотомонтаж **А.П.Черняев**

Гарнитура Times New Roman PS MT

“Бумеранг” ҖЧҖ